КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№ 20
1 декабрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Геннадий ПАУШКИН.* Менә хәзер, торгынлык елларында рәхәтрәк иде, дип сөйлиләр. Бер-бер артлы тезелеп, тагын бөтенебезгә бертөрле «аш» ашыйсы килә башладымыни инде?

4 *Роза ГАФУРОВА.* Таякка таянган һәр кеше сезнең ярдәмгә мохтаҗ, аңа шәфкать-миһербан күрсәтү савaплы да, гражданлык һәм кешелек бурычы да.

8 *Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.* Кемнәрдер тагын үзгәрәләр, көне-сәгатькә кулай битлекләр киеп алалар, андыйларның запас битлекләре бер чакта да үзләреннән калмый, мәгәр бернәрсә ап-ачык — акыллы адәмнәрнең байтагы Ельциннан һич канәгать түгел!

17 *Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.* Бүгенге көндә татар әдәбияты, татар китабы чыннан да һәлакәт алдында тора.

Төрле илләр, төрле кыйтгаларга Нинди җилләр безгә тараткан?..

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Компартия җимерелгәндә озын куллы җитәкчеләрне сүктек: оятсызлар, урлашучы дәүләт югарылыгына күтәрелделәр... Үз кесәңне дәүләтнеке белән бутаулар, өстенлекләр инде бетәр дип уйладык. И бездәге беркатлылык! Хәзер эш башындагы байтак түрәләр, партократлардан да уздырып, «болганчык су»да зуррак балык эләктерергә, нәсел-нәсәбенә ташпулатлар салдырып калырга ашыгалар, шул рәвешле, хәрәм мал үзләштереп, вакытында алынмаган хезмәт хакына гына яшәүче ватандашлары, карт-коры, балаларның хәләл өлешенә керәләр. Әллә инде бу илдән оят бөтенләйгә качтымы?!.

Мансуров

Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ



Геннадий ПАУШКИН

Әйбәт тормыш кайчан килер?!

— Кайчан әйбәт тормыш булыр икән? — дип әрмән радиосыннан сораганнар, ди.

— Әйбәт тормыш кичердек бит инде, — дип әйткәннәр әрмән радиосыннан.

Ә кайчан соң әле әйбәт тормыш булды? НЭП чорындамы? Соң бит НЭП ул күптән булган инде.

Әллә ипине кәртечкәгә алгандамы? Анда һәркемгә дә бертигез бирәләр иде түгелме соң?

Бик «бәхетле» бер көнем искә төшә. Берсөнне иртән күрше карчыгы керә дә:

— Нишләп ятасыз сез, кызыл йортта «джем» саталар, кеше килеп тулганчы барып алыгыз, — ди.

Мин бидонны алып шунда чаптым. Кичә монда гөрәнкә сатканнар иде. Пешереп ашадык, ярыйсы гына төмле булды. Тик, соң аны «джем» белән — «алма джемы» белән чагыштырып буламыни?

«Джем» — мичкәдә. Мин — чиратта. Чүмеч тыккан саен мичкәдә «джем» кими бара. «Миңа гына җитсен иде», — димен.

Шушы кызыл кирпеч кибеттә кәртечкә белән ипи дә бирәләр иде. Тау битендәге бу йорт янына таң белән халык чиратка килеп басар иде дә, сатучы бер-ике минутка кичегә калса, талканы корырак «җегетләр» ишеккә тибә башларлар иде. Ишек ачылгач, әлбәттә инде, беренче булып алар кереп тулалар иде. Ипине кәртечкә белән бирсәләр дә, барыбер, җитми каладырые ул. Төтемәгән кеше төштән соң ор-яңадан чиратка баса. Шулай итеп, көне буе кибет төбендә халык торырые..

«Бирәләр», «чыгарганнар» дигән сүзләр шул чаклардан телгә кереп калды бугай ул. Бу сүзләрне башка бер телдә дә очрата алмассыз.

Хрущев вакытындагы азрак «тын алу» вакытында да җыйналашып Мәскәүгә «кеше» җибәрә идек без. Җибәрә идек тә, иттер, колбасадыр, май-кәнфиттер ише нәрсәләр тояп кайтып килүче иптәшебезне вокзалда ике куллап каршы ала идек. Ә үзебезнең Казан кибетләрендә коньяк белән краб консервларыннан башка бер нәрсә дә табып булмый иде.

Базарда бар иде анысы, әлбәттә, тик анда да төшкә чаклы гына иде, аннары киштәләрдә чыпчыклар белән күгәрченнәр генә хуҗа булып кала иде...

Менә хәзер, торгынлык елларында рәхәтрәк иде, дип сөйлиләр. Колбасасына да, аракысына да хәл җитәрлек иде, диләр. Аннары, промтовар кибетләрендә костюмы дисеңме, пальтосымы — бөтенесе дә эленеп тора иде, диләр. Ләкин бит бер хезмәт хакы костюм да, пальто да алырга җитми иде ләбаса. Эшләгән кешенең эшенә башка бер генә илдәге кебек тә түләмиләр иде. «Жалунья» бар иде анысы, ягъни эшкә чыккан кешене дәүләт «жаловать» итә иде. Инде дә берәр җитезрәге, куелган норманы узып китә башласа, аңа «түшәм» бар иде: тиешеннән артыгын ул барыбер ала алмый иде. Ул чактагы каргышларның берсе искә төшә: «Шул бер зарплатаңа гына тор, каһәр суккыры», диярләр иде.

Ул чакны колхоз-совхоз төзелешләрендә бик күп шабаш бригадаларын күреп булыр иде. Анда иртә таңнан кичкә караңгыга чаклы фән кандидатлары, ассистентлар, журналистлар, яшь язучылар кирпеч ташый, абзар чистарта, измә изә һ.б. эшләр башкарыр иде.

Бу — ял вакытында, отпускыда эшләнә. Нишләмәк кирәк, тамак тәмугка кертер, диләр бит. Андый авыр эштән «акмаса да, бераз тама» иде шул инде.

Ул «алтын заманнар»да номенклатура гына арурак яшәде бугай. Аларның «үз» кибетләре, «үз» ашханәләре, «үз» сауналары («үз» коньяклары белән) бар иде. Кекин йортының астында ниләр генә юк иде икән?! Өйләренә китергәне генә җитмәгән, түрә хатыннары, анда төшеп, җаны теләгәнне тагын машинага тояп алып китә ала иде. Ә гади кешегә чумара эшләргә, шабашкага китәргә, «навар» табарга кала иде. Бу сүзләрнең мәгънәсен сез бер сүзлектән дә таба алмассыз. Ләкин алар халыкның «гомер — тормыш» сүзлегенә уеп-уеп язылган.

Ул «торгынлык» елларын хәтерләүчеләр исәндер әле. «Табынлык» еллары дисәң дә булыр иде аларны. Нигә? Табын мул иде, шәраб җитәрлек, эчмәгән кеше сирәк: партия-хөкүмәт җитәкчеләреннән алып халыкның иң тирән «масса»ларына чаклы эчәргә мәҗбүр булды анда. Эчми генә кара! Бер генә партия-комсомол конференциясе дә банкет-мәҗлессез тәмамланмый иде! «Өч борын»га керү дә шул еллардан башланып китте шикелле...

Булды инде, булды: эчтек тә, типтердек тә, яшерен-батырын түгел. Бер дигән девон нефтебезне «Дуслык» нефтеүткәргече аша «социалистик» илләргә, андагы тоталитар режимны саклау хакына агыздык, илнең алтын запасы да шунда таба шуышты. Әллә кай илләрдәге тугры «дусларыбыз»га алмазлар бүләк иттек. «Икенче Ильич»ыбыз киң күңелле иде, мәрхүм: һәр ялтыраган нәрсә хакына бер амбар хәзинә бирергә әзер иде, хәтта «кораллар пулаты»ннан да. Ни әйтәсең инде: орден-медаль тагу өчен генә дә аерым бер кәчтүм тектергән булган бит абзыебыз. Тезгә җитә торганын...

Шушыларның бөтенесен дә онытабызмыни инде? Колбасадан башка кайгы калмадымыни? Бер-бер артлы тезелеп, тагын бөтенебезгә бер төрле «аш» ашыйсы килә башладымыни инде?

«Ирек ул зыялыларга гына кирәк, гади халыкка син ипи бир дә, чыгарып күрсәт», диләр миңа еш кына. Моңа нәрсә дисең инде... Башы, кулы, көче булган кеше тамагын туйдырырлык кына эшли ала бугай бүген дә... Фәкыйрьлекнең аръягына тәгәрибез, дип лаф орулар да туйдырып бара шикелле...

Мәктәп юлында әниләре җитәкләгән сабыйларга карыйм да сөенеп туя алмыйм: карасана, нинди чибәрләр, бигрәк матур киенгәннәр инде, дим... Андый киемнәр безнең төшкә дә кереп чыкмый иде бит. Минем әтием, мәрхүм, мәктәпне тәмамлавыма миңа бер костюм юнәтә алды, ә ул чактагы пальтомны әле сугышлардан әйләнеп кайткачтын да шактый вакыт киеп йөрергә туры килде...

Бүгенге көнебез бик болгавыр да, бик чуалчык та, әлбәттә. Нишлисең бит, «үсәбез»дер инде. «Күчеш» чорында үзебезгә дә күзәбезне, кесәбезгә керә торган «нечкә» бармакларга ныграк текәргә кирәктер. Аннан килеп, хезмәтебезгә тиешенчә түләүләрен кем таләп итәргә тиеш соң әле? Буага җыелган чүп-чарны көчләп агызып җибәрмәсәң, аның суы сасый башлый бит. Әйдәгез, берга-берга чистартыйк суларыбызны!

Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар 5 6 7 1 2 3 4

Ерактагы кояш җылыракмы?

Инде билгеле булганча, Татарстан Республикасы Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге делегация рәсми визит белән Австралиядә булып кайтты. Үткән сишәмбедә делегация җитәкчесе сәфәр йомгакларына багышланган матбугат конференциясе үткәрде.

Визит барышында Татарстан Республикасы һәм Көньяк Австралия штаты арасында өч телдә язылган (татар, урыс, инглиз) дустанә мөнәсәбәт һәм аны үстерү, сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни бәйләнешләр турындагы Килешүгә имза салынган. Визитның беренче көнендә исә, 20 ноябрьдә кичен Аделаида шәһәрендә Татарстанның сәүдә-икътисади вәкиллеген тантаналы төстә ачу булган. Бу тантанада Көньяк Австралия штаты Премьер-министры Дин Браун чыгыш ясаган. Шулай итеп хәзер Аделаиданың үзәгендә Татарстан флагы җилферди.

Күпсанлы сөйләшүләр барышында ике якның нинди товарларга һәм технологияләргә ихтыяҗ булуы ачыкланган. Безнекеләрне йон эшкәртү, тире иләү, азык-төлек җитештерү, селекция эше, шулай ук җиңел автомобильләр җыю («отвертка технологиясе») кызыксындырса, экватор артында яшәүчеләрнең игътибарын безнең махсус вертолетлар, «КамАЗ»лар, оптика җәлеп иткән. Австралия белән Татарстан арасында тышкы сәүдә әйләнеше әллә ни зур түгел — быелның тугыз аенда ул 1,88 млн. доллар тәшкил иткән. Шуның 96 проценты импортка туры килә. Билгеле булганча, Австралиядә терлекчелек алга киткән. Бу илдән сарык ите сатып алу турында беренче сөйләшүләр күрсәткәнчә, әлеге продукциянең бәясе (Казанга кайтаруны исәпкә алып) безне канәгатьләндерерлек, диде хөкүмәт җитәкчесе. Шушы уңайдан сорау да туа: мондый итне Австралиядән алганчы, Азнакайдан сатып алсаң, ул тагы да арзангарак төшмәс микән? Әллә Австралия сарыкларының ите тәмлерәкме?

Журналистларны делегациянең җитәкчесе Минтимер Шәймиев булып та, аның Австралиягә бармавы кызыксындырды. Табиблар Президентыбызга грипп белән чирләгәннән соң булган катлауланулар аркасында сәфәргә чыгарга тәкъдим итмәгәннәр. Күрәсең, Президент табибларының күрәзәлек сыйфатлары бар — Австралиядән кайту юлы безнең делегация әгъзаларының нервларын киеренкелектә тоткан — Кытай күгендә



очканда Тянь-Шань таулары өстендә 10 мең метр биеклектә самолет тормозының сыекчасы агып чыга һәм экипаж яңә очып киткән аэродромга — Нью-Делига кайтырга мәҗбүр була. Алар Алма-Атага да кайта алган булырлар иде, тик анда аэродромның төшү-очу юлы кыскарак — 3 чакрым гына. Нью-Делида безнең самолетны янгын сүндерү, «Ашыгыч ярдәм» машиналары каршы ала. Тормозлары булмагач, самолет тиз генә туктый алмый. Ахырда, пилотларның осталыгы нәтиҗәсендә барысы да уңышлы тәгәлләнә.

Австралиядәге татар диаспорасы турында матбугат конференциясендә делегация әгъзасы академик Мирkasыйм Госманов сөйләде. Милләттәшләребез даирәсе чагыштырмача яшь, 70-80 нче елларда формалаша башлаган, бүген ул 400-450 кешене үз эченә ала. Күбрәге Кытайдан, Төркиядән килгәннәр, берничә кеше Татарстаннан күчеп яши башлаган. Делегация әгъзалары аларга татарча кассеталар, китаплар тапшырганнар.

Наил ФӘЙЗЕТДИН.

● 1 нче биттә Татарстан делегациясен Австралиядә менә шушы мәчеттән чыккан вакытта Наил Курамшин төшергән сурәт.

«Культура»- тәрбия дигән сүз

Үткән дүшәмбедә Камал театрында Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният академиясен тәкъдир итү кичәсе булды.

Тарихы Ленинград югары уку йортының филиалы буларак башланган, хәзерге көндә БДБ һәм Русиянең 32 өлкә-республикасы студентлары белем ала торган академиянең кыскача тәрҗемәи хәле турында ректор Рәис Беляев сөйләде. Кичәдә Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев, вице-премьерлар Равил Моратов, Фатыйх Сибагатуллин, Илгиз Хәйруллин, Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаков, башкаладагы югары уку йортлары ректорлары катнашты. Шулай ук Чувашия һәм Мордовиядән кунаклар килгән иде. Рәис Беляевка картина бүләк иткәндә Василий Лихачев:

— «Культура» сүзе латинчадан «тәрбия» дигәнне аңлата, — диде.

Әйе, әлеге уку йортында укыган белгечләр үз-үзләрен тотышлары, шөгыль-һөнәрләре белән дә халыкны тәрбияләргә бурычлы. Шулай булганда гына сәнгать һәм мәдәният академиясе үзенең исемен һәм дәрәҗәсен аклый алыр.

Котлыйбыз!

Кунакка безне кем дәште?

Әйе, безне кунакка дәштеләр. Безне дәшкәннәр икән, димәк, безнең якын дусларны да — укучыларыбызны да чакырганнар. Шуңа күрә, без дуслар исеменнән дә котлыйбыз! Ә кемне котлыйбыз, кем безне кунакка дәште? «Татарстан» журналы! Ул безнең бердәнбер иҗтимагый-сәяси-теоретик журналыбыз. Уйлы-фикерле хисле-акыллы, дәртле-дәрманлы кардәшебез.

«Татарстан» журналы 1920 елның 1 декабрендә яңа төзелгән Татарстан Республикасының беренче журналы буларак чыга башлый. Беренчел исеме — «ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты хәбәрчесе». Урысча исеме — «Вестник татарского областного комитета ВКП(б)»

1991 елның гыйнварында исә журнал үз исемен, үз җисемен яңартты. «Татарстан» журналы булып, халкыбыз күңеленә кайтты.

«Татарстан» журналы — татар халкының сәяси-иҗтимагый аңы. Без аны 75 яше белән котлыйбыз! Кеше язмышында ни булмас та, журнал язмышында ни булмас?! Әмма үз халкына тугры хезмәт иткәннәрнең изге эше онытылмас!

Ихластан котлыйбыз, ихластан тәбриклибез, яратып укыйбыз. яратып олылыйбыз!

«МӘДӘНИ ҖОМГА».

«Деловые люди» һәм абруйлы җитәкчеләр

Дөньяның биш кыйтгасы өчен чыгарыла торган «Деловые люди» бәйсез журналының яңа 60 нчы саны кулыбызга килеп иреште. Анда Дмитрий Ольшанскийның ноябрь аена прогнозы — Русия төбәкләрендәге 20 лидерның «рейтинг ярышы» мәгълүматлары бәян ителгән. Беренче бишлеккә түбәндәге сәясәтчеләр кертелгән: Юрий Лужков, Җәүһәр Дудаев, Эдуард Россель, Борис Немцов, Минтимер Шәймиев. Күрше җөмһүрияттән Мортаза Рәхимов исә уналтынчы урында тора. Журналда Татарстан Президенты сүзләре дә китерелгән. Анда мондый юллар бар: «... Федераль властьларга без торган саен азрак мөрәҗәгать итә алабыз... Чөнки бүген федераль власть органнары күп кенә сорауларга нәтиҗәле йогынты ясарга барыбер сәләтле түгелләр. Һәм монда бернинди ихтыяҗ да юк».

P.S. «Деловые люди» журналы үткәргән әлеге бәйгедә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачевка соңгы 20 нче урын бирелгән. Спикерыбызның мондый «обойма»ларга керүе күңелле һәм уйландыра торган фал.

Калыр, китмәс, яшәр

«Сөт калыр, Ватан китәр!» дип язган Дәрдмәнд. ***Иншалла, сөт тә калыр, Ватан да китмәс, «Мәдәни җомга» да яшәр!***

Хөрмәтле укучыларыбыз! Көндәлек матбугатка язылу төгәлләнеп килә. «Мәдәни җомга»лы булып калырга ашыгыгыз. Язылу бәясе. ***1 елга — 36 мең сум, 6 айга — 18 мең сум, редакциягә килеп алучылар өчен — 25 мең 392 сум (бер елга).***

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә ***Татарстан Республикасының Мактау грамотасы*** *белән бүләкләнделәр:*

Әнвәр Бәдретдин улы БАҺАУЕТДИНОВ *— Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы,*

Казан автотранспорт техникумы коллективы;

Сергей Алексеевич ЖАРОВ *һәм* ***Анатолий Георгиевич СТРИЖКОВ*** *— Казан автотранспорт техникумы укытучылары,*

Матбугат өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен «Татарстан» журналы редакциясенең компьютерда җыю операторы ***Луизия Шәрәфетдин кызы ӘЮПОВА.***

Мәдәният өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре *исеменә лаек булдылар. Азнакай районы һәм Азнакай шәһәре хакимиятенең мәдәният идарәсе башлыгы* ***Азат Гарәфетдин улы ГАЛИМОВ.*** *Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел. әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре* ***Ленар Шәйхи улы ҖАМАЛЕТДИНОВ;*** *Казан дәүләт технология университеты гуманитар белем кафедрасының өлкән укытучысы* ***Валентин Васильевич ЛОБОВ.*** *Азнакай үзәкләштерелгән китапханә системасының директор урынбасары* ***Зөмзәмия Мәхәсим кызы МӘҖИТОВА,*** *«Татарстан» журналы редакциясенең техник редактор-корректоры* ***Клара Әмир кызы МИҢНУЛЛИНА,*** *Апас районы хакимиятенең мәдәният бүлегендәге автомобильләр клубы мөдире* ***Резеда Әмир кызы МОСТАФИНА,*** *Лаеш районы Никольское авылының мәдәният йорты директоры* ***Сергей Алексеевич ТРУСОВ;*** *Татарстан Республикасы Мәгариф хезмәткәрләре йорты каршындагы «Прометей» урыс халык театры режиссеры* ***Галина Михайловна БАКУНИНА,*** *Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы хакимиятенең мәдәният бүлеге мөдире* ***Лия Тимофеевна ЮРКИНА.***

«Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы» *дигән мактаулы исемгә лаек булдылар.*

Диләә Шамил кызы ГЫЙМАДИЕВА, Владимир Глебович ПЛЕХАНОВ, Светлана Георгиевна СТРИЖКОВА *— Казан автотранспорт техникумы укытучылары.*

Татарның һәм башкортның яраткан җырчысы ***Айдар ГАЛИМОВка «Башкортстан Республикасының атказанган артисты»*** *дигән мактаулы исем бирелде.*

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Казанда «Время и деньги» (элеккеге «Известия Татарстана») газетасының тәүге саны дөнья күрде.

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Мамадышта район Советы сессиясендә катнашып, бу районның хакимият башлыгы итеп Әгъзам Гобәйдуллинны билгеләү турындагы Указын игълан итте

«Азатлык» татар яшьләр оешмасы 17 декабрьдә Русия Дәүләт Думасына булачак сайлауларда катнашмаска чакыра.

«Казан» милли мәдәният музее экспозициясе, Русия белгечләре әйтүенчә. Эрмитаж экспонатларының да иң дәрәҗәлеләренә тиң торырлык көмеш савытлар белән тулыландырылды

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, прозаик, драматург, шагыйрь Фәнис Яруллинның иҗат кичәсе булды.

Мамадыш районының Шәдчә авылында Америкада яшәүче милләттәшебез Илһан Айдагөлнең матди ярдәме белән мәчет салынды

Поезд билетларының бәясе тагын 15 процентка артты.

Чаллыда «Татарстанның мәдәнияте һәм сәнгате. Тарих. Традицияләр. Заман» дигән фәнни-гамәли конференция булды.

Нижгар өлкәсендә Русиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бигичев белән Татарстанның халык артисткасы Зөһрә Сәхәбиева концертлары зур уңыш белән бара.

Татар китабы яклауга мохтаҗ

Кичә Татарстан китап нәшриятының редакцион совет утырышы булды. Анда катнашучылар 1996 елда дөнья күрәсе китаплар, гомумән алганда, китап чыгаруны камилләштерү буенча нәшрият эшчәнлеген яхшырту турында фикер алыштылар. Татарстан халык язучылары Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, мәдәният министры Марсель Таишев, Дәүләт Советының милли һәм мәдәният мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе шагыйрь Роберт Миңнуллин, Министрлар Кабинетының бүлек мөдире Габделхак Шәмсетдинов, Татарстан китап нәшрияты директоры Харис Әшрәфҗанов һ.б. татар китабының бүгенге хәле турында борчылып сөйләделәр, аның буенча дәүләт кайгыртуын көчәйтү зарурлыгын басым ясап әйттеләр.

Утырышта Татарстан мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов катнашты һәм чыгыш ясады

Көткән Дума хәзер туар, ләкин Думага кем тулар?

Бәхәсләрне тыныч юл белән хәл итик

Роберт САДЫЙКОВ

Русия Федерациясенең Дәүләт Думасына 25 нче Түбән Кама сайлау округыннан «Коммунисты — «Трудовая Россия» — за Советский Союз» блогы кандидаты. Ул 1941 елның 3 июлендә туган. Сабый һәм үсмер чаклары Зәй районының Бигеш һәм Кадер авылларында узган Урта мәктәпне Зәйдә тәмамлаган. 33 ел совет армиясендә хезмәт иткән. Алтын медаль белән югары хәрби училище һәм хәрби-сәяси академия тәмамлаган Офицер хезмәтен взвод командирыннан башлап, армия сәясәт бүлеге начальнигы урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Бер ел Казан танк училищесында укыткан. 1991 елда полковник дәрәҗәсендә запаска чыккан. Шул вакыттан бирле Казан дәүләт педагогия университетының кадрлар бүлеге мөдире булып эшли. Хатыны — медицина хезмәткәре. Ике бала тәрбияләнә.

Татарстанда коммунистлар партиясен торгызуда актив катнаша. Партиянең республика комитеты бюросы әгъзасы һәм идеология секретаре. Коммунистик партияләр союзының (СКП — КПСС) XXX съездында союзның контроль-ревизия комитеты әгъзасы итеп сайлана.

Үзен кандидат итеп күрсәткән блокның сайлау алды платформасын тулысынча үтәү өчен көрәшә.

Роберт Гариф улы Русиядә халыкка каршы булган бүгенге сәясәтне тамырдан үзгәртү, тормышыбызны совет власте, социалистик строй һәм яңартылган Советлар Союзы нигезендә торгызу ягында тора.

«Әл-зәкат» миһербанлы булырга өнди

Менә инде өч айдан артык Татарстан очучылары Әфганстанда әсирлектә. Аларны коткару буенча рәсми даирәләрнең тырышлыгы әлегә берникнди дә нәтиҗә бирмәде, диело Казан шәһәрендә берләштерелгән «Әл-зәкат» фондының БМО Генераль секретаре Бутрос Гали, Әфганстан Президенты Борһанетдин Роббани һәм «Талибан» җитәкчеләренә юллаган мөрәҗәгатендә. Әлеге документ күптән түгел «Мәдәни җомга» редакциясенә дә килеп иреште. Без, хөрмәтле Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең абруе, аның Пакистанның Русиядәге илчесе Тәнвун Әхмәт Хан белән очрашуы әсир очучыларны коткаруга этәргеч булыр дип уйлыйбыз, диелә анда.

Сәяси карашларның төрлелеге, халыкара хәлнең катлаулылыгын аңлаган хәлдә без Сезнең игътибарыгызны Коръәнгә юнәлтәсебез килә. Изге китап кешелеклелеккә, инсаннарга ярдәм итәргә, ялгышканнарга туры юлга басарга булышырга өнди. Аллаһы Тәгалә, Коръәндә әйтелгәнчә, шәфкатьле, мәрхәмәтлеләрне яратыр, диелгән. Без сезне Ислам диненә җаны-тәне белән бирелгән, Коръән һәм Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсынып яшәүче халык дип беләбез һәм ватандашларыбызга да шәфкатьле-мәрхәмәтле булырсыз, диген өметтә калабыз. Әлеге документка «Әл-зәкат» фонды рәисе Рүзәл Габитов, фонд каршындагы иҗади студия җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев һәм тагын 13 кеше имза салган.

Голәма шурасы гаепли

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасына бәйле хәлләр уңаеннан 10 ноябрьдә булган утырышында Голәма шурасы белдерү белән чыкты. Анда, Диния нәзарәтенең әйдәүче эшлекләләре арасында әледән-әле килеп чыккан гаугалар мәчет әһелләрен дә, мөселман җәмәгатьчелеген дә тирән борчуга салды, диелә. Күптән түгел «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасын коч кулланып тартып алу максатында хөкүмәт белән кискен каршылыкка керү һәм шәһәр җәмәгатьчелеге алдында берничә көнгә сузылган җәнҗаллы тартыш мөфти хәзрәтнең абруен шактый төшерде. Тирә-юньдә, бөтен дөньяда тотрыклы, тыныч тәртипләре белән танылган җөмһүриятебезгә тап төшерә торган гамәлләрнең башында Диния нәзарәте җитәкчеләре торырга тиеш түгел иде. Киресенчә, Ислам җәмәгатьчелеген тыныч, иҗади эшчәнлеккә, татулыкка туплап, җөмһүрияттәге бердәмлеккә булышу — аның намус эше, — ди Голәма шурасы.



Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры
Атналык программа
(Декабрь)

1. Җомга	Мансур Гыйләҗев **КАЗАН ЕГЕТЛӘРЕ** Музыкаль комедия	
2. Шимбә	Александр Островский **ҖИМЕРЕЛГӘН БӘХЕТ** Драма	
3. Якшәмбе (Көндез һәм кич)	Туфан Миңнуллин **ҖАНКИСӘККӘЕМ** Музыкаль комедия	
5. Сишәмбе	Зөлфәт Хәким **КИШЕР БАСУЫ** Комедия	
6. Чәршәмбе	Гаяз Исхакый **АЛДЫМ-БИРДЕМ**	
7. Пәнҗешәмбе	Туфан Миңнуллин **ГӨРГӨРИ КИЯҮЛӘРЕ** Комедия	
8. Җомга	Лопе де Вега **БИЮЧЕ** Комедия.	

Мәскәүдән Казан яхшырак күренә

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов «Балет» журналының быелгы лауреаты булган. Моңа ул театр белән иҗади рәвештә җитәкчелек иткәне өчен ирешкән икән. Ләкин шунысын да онытмыйк: М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры сәхнәсендә инде берничә ел дәвамында татар авторларының әсәрләре бөтенләй куелмый диярлек, чит илләргә гастрольләргә дә театр урыс һәм Аурупа авторлары әсәрләрен генә алып чыга.

Хәер, бу хакта, урыс әйтмешли, не нам судить, татар театрының иҗади уңышлары Мәскәүдән яхшырак күренәдер, мөгаен.

Кайсыгызның кулы җылы

Безне дә онытмагыз!

3 декабрь — халыкара инвалидлар көне буларак, XIX гасыр ахырларыннан ук билгеләп үтелә Безнең илдә исә бу көн хакында ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышып, проблемаларны читләтеп үтү гадәткә кергән иде Шөкер, соңгы вакытта республикабызда әлеге мәсьәләгә караш уңай якка үзгәрә бара

Әйтик, бүген бездә сукырлар җәмгыятенең катлаулы проблемаларын чишү уңышлы алып барыла Җәмгыятьнең матди базасы да шактый ныгытылды Күрмәүчеләр җәмгыяте быел үзенең 70 еллыгын билгеләп үтте

Бүген җәмгыятьнең иң мөһим бурычы хезмәт урыннарын саклау һәм яңаларын булдырудан гыйбарәт Хезмәт итү — сукырлар өчен акча табу тормышны тәэмин итү генә түгел, ә бәлки коллективта, кеше арасында булу аралашу дигән сүз дә

Торак мәсьәләсенең дә көн тәртибеннән төшкәне юк Безнең инвалидларның күпчелеге авыр шартларда, уңайлыклары булмаган яисә әлешчә генә булган фатирларда яшиләр 1990 елда «Электроконтакт» берләшмәсе җәмгыять өчен торак йорт төзү эшен башлап җибәргән иде, ләкин төзү эшләре бүген инвалид оешмалары җәмгыятьләре ассоциациясе кулына күчте һәм шуннан торакка мохтаҗ булган инвалидларга яшәү шартларын яхшыртa алмау куркынычы килеп туды Район советы башкарма комитетларында фатирга чират торучылар да фатир алуга өметләрен җуя баралар

Күрмәүчеләр өчен фатир, электр энергиясе, телефон һ.б өчен түләүдә ташламалар ясау турында Русия Федерациясенең 1993 елгы фәрманы бар иде, ләкин безнең республикада бу ташламаларны онытканнар, ахры, бигрәк тә Казан шәһәрендә. Телефон куйдыру, фатирларга түләүсез ремонт ясау, шәһәр транспортында инвалидны һәм аны озатучыны йөртү, көнкүреш техникасын ремонтлау, өйләрне җылыту өчен ягулык табу, китертү мәсьәләләре дә инвалидларны нык борчый. Республика күләмендә боларны хәл итү бик мөһим. Гомумән, инвалидлар турында закон кабул ителсен иде Без аны 1990 елдан бирле көтәбез Бу закон инвалидларны социаль яклау буенча җәмгыятебезнең зур адымы булыр иде.

Республикабыздагы һәр кешегә әйтәсе сүзебез дә бар Таякка таянган һәр кеше сезнең ярдәмгә мохтаҗ. Аңа шәфкать-миһербан күрсәтү саваплы да, гражданлык һәм кешелек бурычы да.

Казанда 1-10 декабрьдә инде өченче тапкыр инвалидлар декадасы үткәрелә. Декаданың максаты — халыкара инвалидлар көненең республикада дәрәҗәсен күтәрү, аерата ярдәмгә мохтаҗ инвалидларга ярдәм күрсәтү һәм, гомумән, аларны яклау буенча өстәмә чаралар үткәреп, инвалидларга игътибарны арттыру

Роза ГАФУРОВА,
Казан шәһәренең 1 нче сукырлар җәмгыяте рәисе

Шахмат уены чистарырмы?

Халыкара шахмат федерациясенең Парижда үткәрелгән Конгрессында Калмык Республикасы Президенты Кирсан Илюмжинов күпчелек тавыш белән ФИДЕ президенты булып сайланды. Аңлашылган сәбәпләр буенча, Русия шахмат федерациясе президенты А.Макаров, атаклы шахматчы Г.Каспаров делегатларның мондый карарга килүенә теш-тырнаклары белән каршы тордылар. Әмма сайлаулар барыбер үзенекен эшләде.

Шахмат дөньясындагы бүленүләргә, Профессиональ шахмат ассоциациясенең (ПША) үзенә диктатлык вазифасын алуына, табигать тарафыннан бирелгән олы талантка ия булучы шахмат осталарының әзәрлекләнүенә, шахмат уенының елдан-ел пычрана баруына кайчан чик куелыр? Анатолий Карпов белән Гата Камский арасында дөнья беренчелеге өчен матч таләп ителгән уңай шартларда үтәрме? Һәм, ниһаять, әлеге ике Президентлык кәнәфиендә утыручы Кирсан Илюмжиновның мондый мәсьәләләрне хәл итәргә гайрәте җитәрме? Сораулар байтак. Аларга нинди җавап табыласын вакыт күрсәтер Хәер, ФИДЕнең яңа хуҗасы беренче матбугат конференциясендә шахмат дөньясындагы «балаган»ны туктатырга вәгъдә бирде

ҖИРЕ БАЙНЫҢ ИЛЕ БАЙ

Фарсил-Сәхәби ЗЫЯТДИН,
язучы, икътисад фәннәре кандидаты

ТУФРАККА КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫН БИРӘБЕЗМЕ?

(Дәвамы. Башы 18 нче санда).

Технологик сәбәпләрдән җирләрне ял иттерү, ягъни чиста пар җирләрә калдыруны гына алыйк. Кәгазьдә чиста пар җирләре һәр хуҗалыкта 10-12 процент калдырылса да, чынбарлыкта алай булмады. Әлеге җирләргә, ял иттерәсе урында, нәрсә булса да чәчелде. «Коммунизм төзү» елларында формалашкан «показуха» чиренең бер чагылышы иде бу. Чиста пар калдырылмагач, җир яңартылмады, ашланмады, чүп үләннәре ишәйде, туфракның гумусы кимеде. Нәтиҗәдә, күп хуҗалыкларда сабан ашлыгы культуралары чүп басты, уңыш кимеде, димәк, җирдән нәтиҗәсез файдаланылды.

Шунысы аяныч, белгечләр уңыш өчен җаваплылык тоюны акрынлап оныттылар, туфрак эшкәртү, органик һәм минераль ашламалар куллануда гомумән тәртипсезлек артты. Ашлама еш кына кирәк җиргә түгел, ә кайда җаечыкты шунда кертелде. Күп очракта җир, хуҗалык файда күрәсе урынында зыян күрде. Болар барысы да битарафлыктан, белгечләрнең үз эшләренә җавапсыз каравыннан килде. Бу — хуҗасызлык бәласе иде. Димәк, җирнең төп хуҗасы булмый торып, әлеге кимчелекләргә чик куелуы икеле.

Ә никадәр җирләр эрозиядән зыян күрә. һәр язны һәм көчле яңгырлардан соң йөзләрчә мең тонна уңдырышлы туфрак юыла. Татарстанда барлыгы 4434,7 мең гектар авыл хуҗалыгы җирләре булып, шуның 3627,9 мең гектарын бүген сөрүлек җирләр тәшкил итә. Менә шул җирләрнең яртысы диярлек эрозиядән зур зыян күрә. Шулай булуга да карамастан, эрозиягә каршы көрәш юнәлешендә, бердән хуҗалыкны исәпләмәгәндә, кыл да кыймылдатмыйбыз, дисәк хата булмас. Бу эш җитәкчегә дә, белгечкә дә кирәкми, механизатор да бу хакта уйламый. Чөнки моңарчы җирнең чын хуҗасы булмады. Җирнең бәрәкәте кимүдән турыдан-туры белгечнең дә, механизаторның да кесәсенә зыян килмәде, алар хезмәт хакын акчалата ала килделәр. Ә менә соңгы 3-4 елда хезмәт хакының шактый өлешен уңышка карап натуралата биргән хуҗалыкларда җирнең уңдырышын күтәрүгә битарафлык бик кимеде. Гомумән, базар мөнәсәбәтләренә күчү чорында колхоз һәм совхозлар өлешчә генә булса да, диктаттан ычкына башлагач, аз гына булса да мөстәкыйльлек алгач, хуҗалык итүнең яңа формалары — кооперативлар, пай предприятиеләре, фермер хуҗалыклары, акционерлык җәмгыятьләре барлыкка килә башлагач, җирдә эшләүче үзе җитештергән продукциянең язмышын өлешчә булса да үзе хәл итә башлагач, кырларның уңышы күзгә күренеп арта башлады. 1992 елда бөртеклеләрнең һәр гектарыннан — 22,7, 1993 елда — 23,0, 1994 елда — 27 центнер уңыш җыеп алынды. Өч ел рәттән тотрыклы. Татарстан тарихында күрелмәгән уңыш үстерелде. Хәтта 1921 елдагыга тиң дәрәҗәдә корылык килгән 1995 елда да канәгатьләнерлек күләмдә бөртек җыеп ала алдык. Бу — иң беренче чиратта игенченең үзен тәүге тапкыр җирнең хуҗасы итеп тоя башлау нәтиҗәсе.

Дөрес, әле һаман да җирнең уңдырышын, бәрәкәтен күтәрү юнәлешендә файдаланылмаган резервлар күп. Бары гик эрозиягә каршы көрәш чараларын гиешенчә үткәрү өчен туфраклы җирләрне известьлау исәбенә дә өстәмә рәвештә 600-670 мең тонна ашлык җыеп алу мөмкинлеге бар.

Игенчелектә торгынлыктан арыну, билгеле, терлекчелек продукцияларын җитештерүне арттыру мөмкинлеген дә тудыра. Шунысы игътибарга лаек, Русиядә 1994 елда авыл хуҗалыгы продукциясы җитештерү 1985 ел белән чагыштырганда, ике тапкырдан кимегән бер вакытта, Татарстанда моңа юл куелмады. Әгәр дә 1985 елда 369,2 мең тонна (тере үлчәүдә) ит җитештерелгән булса, 1992 елда — 376,9, 1993 елда — 378,9, 1994 елда 378,5 мең тонна тәшкил итте. Сөт җитештерүдә дә шундый ук уңай хәл күзәтелә. 1985 елда ул барлык категория хуҗалыкларда 1439,9 мең тонна җитештерелгән булса, 1992 елда 1619,1, 1993 елда — 1721,5, 1994 елда 1689,4 мең тоннага җитте. Йомырка җитештерү бер ук дәрәҗәдә калды. һәм 1992-1994 елларда уртача 1 млрд 196,4 млн булды.

Шулай итеп, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү тотрыклы калды. Әгәр дә 1991 елда авыл хуҗалыгының тулай продукциясе 1983 елгы бәяләрдә 2950 млн сум булса, 1994 елда ул 3005,6 млн сум тәшкил итте, ә игенчелектә 1141,2 млн сумнан 1273,9 млн сумга күтәрелде.

Сәбәп нәрсәдә? Русия итсез сөтсез йомыркасыз калган вакытта, Татарстан терлекчелек продуктлары җитештерүнең күләмен саклап кына калмыйча, арттыруга ирешүе. Моның төп сәбәбе — күчеш чорында дөрес икътисади сәясәт алып баруда. Монда республикабызның һәм башкаручыларның һәм һичшиксез Президентыбыз М.Ш.Шәймиевнең икътисадчылар сүзенә колак салып, акыл белән эш итүе зур роль уйнады. Русиядә исә турыдан-туры Б.Н.Ельцинның өйтүе буенча колхоз-совхозларны тараттылар, фермерлаштыру ягъни хосусыйлаштыру коллективлаштыру елларындагыдан да кызурак темплар белән башкарылды. Җитештерү средстволары терлек фермерларга бүлеп бирелде. Шуннан нәрсә килеп чыкты? «Коммунизм төзү» елларында өстән күрсәтмә буенча гына эшләргә күнеккән колхозчылар, хәзер исә яңа фермерлар бер яктан эш оештырырга сәләтсез булсалар, икенчедән, аларга хуҗалык итү өчен берниндн шартлар да тудырылмаган иде. Фермер хуҗалыкларына эш башкарырга яраклы техника юк, сатып алыйм дисәң, акча, кредит бирелми. Биргән очракта да, ул инфляция нәтиҗәсендә бик тиз юкка чыга. Фермерлар эшләү түгел, уйларга да өлгерә алмый кала. Нәтиҗәдә бүленгән терлекләр суеп сатылды, терлекләрнең баш саны кискен кимеде. Продукция җитештерү дә бермә-бер кыскарды, миллионнарча гектар җирләр чәчелми калды. Авыл хуҗалыгы чын мәгънәсендә гирән кризиска чумды.

Русиядән әрмалы булярак, Татарстанда колхоз һәм совхозлар акрынлап кына күмәк хуҗалыклар итеп үзгәртелде. Бары гик үз теләкләре булган колхозчы һәм совхоз эшчеләре генә фермер хуҗалыклары оештырып җибәрделәр. Әлегә аларның саны күп түгел — сигез йөз чамасы гына. Күп булмагач аларга ярдәм итү мөмкинлеге дә бар. Аннары шунысы әһәмиятле, бүген күмәк хуҗалыкларда эшләүчеләрнең үз пае, үз мөлкәте өлешенә тигән җире мәгълүм. Әгәр дә гели икән, ул үз паен алып күмәк хуҗалыктан аерылып үзенең фермер хуҗалыгын оештыра ала. Крестиянгә менә шундый ирек, мөстәкыйльлек бирү анда чын хуҗа булу хисе уятты, ул ничектер бирелеп эшли башлады. Татарстанда авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүдә тотрыклылыкны саклап калу минемчә менә шуның белән аңлатыла.

Гомумән, Татарстан халкы тырыш эшчән намуслы. Торгынлык елларында да ул чагыштырмача гырышып эшләде. СССР таркалган 1991 елны Татарстанда һәр йөз гектар авыл хуҗалыгы җиренә 369 центнер сөт, 60,2 центнер ит җитештерелде. Азмы бу, күпме? Моны күз алдына гулырак китерү өчен Русия һәм аның якын тирәдәге өлкәләре белән чагыштырып карау да җитә. Русиядә сөт җитештерүдә бу күрсәткеч 256 центнер, ягъни 113 центнерга кимрәк булса, ә күршеләребез — Идел буендагы өлкәләрдә 182 центнердан артмады, ягъни бездәгедән бермә-бер кимрәк булды.

Ит җитештерүдә дә шундый ук хәл күзгә ташлана. Татарстанда һәр йөз гектар авыл хуҗалыгы җиренә 60,2 центнер ит җитештерелсә, Русиядә ул — 46,2, ә Идел буе экономик регионында 36 центнер гына, ягъни 1,7 тапкыр кимрәк булды. Хәзер исә сөт-ит җитештерүдәге аерма тагын да арта төште. Чөнки Русиядә ит һәм сөт җитештерү өйткәнемчә 1992-1994 елларда гына тагын ике тапкыр кимеде.

Мин монда СССР таркалгач, елны ирешкән саннарны китердем. Ни өченме? Менә нәрсә өчен. Әгәр дә СССРның барлык регионнарында, республикаларында да (ә аларда терлекчелек өчен уртача шартлар бездәгедән әйбәтрәк) авыл хуҗалыгы җирләренең һәр йөз гектарына ит һәм сөт Татарстандагы кадәр генә җитештерелсә дә, бүгенге БДБга кергән илләрдә азык-төлек проблемасы хәл ителгән булыр иде, ягъни 36 млн тонна ит һәм 223 млн тонна сөт җитештерелгән булыр иде.

Әйе, эшләгәнне талап, эшләмәгәнне туендыру тоталитар системага хас һәм закончалыклы күренеш иде. Екатеринбург, Чиләбе, Вологда өлкәләренә ит һәм май талап итеп, ул елларда Татарстанның җилкәсен аз кимердәләрмени? Бу планлаштырудагы бер мәгънәсезлек иде. Фикерем ышандырырлык булсын өчен тагын бер сан китерәм. БДБ илләрендә җан башына уртача 2,1 гектар авыл хуҗалыгы җирләре туры килсә, Татарстанда ул нибары 1,2 гектар гына, ягъни ике тапкыр диярлек кимрәк. Шулай булгач, ит-сөт продуктларын кем-кемгә, нинди регион кайсысына бирергә тиеш булган дигән мәсьәлә чишелә кебек. Бу — күрәләтә галау иде. Мәсьәләгә кешеләрчә килгәндә, сөт-ит продуктлары белән кирпсенчә бәзнең республикага ярдәм итәлергә тиеш идә. Әйе, җире аз булса да Татарстаннан һәрчак күбрәк каеру, талау ягын карадылар. Ни өчен дисәң, Русиядә җир мул, тик нәтиҗәсе юк, анда бирелеп эшләүчеләр аз.

Әлекке система менә шулай барысын тигезләп килде. Эшләгәннән тырышканнан һаман ала килделәр. Шулай булгач, кем тырышсын, кем җирдән нәтиҗәле файдаланырга омтылсын? Сер түгел, акрынлап безнең халык та җирдән бизә башлаган иде инде. Эшләгәнне эшеннән биздерә, эшләмәгәнне азындыра торган закончалык иде шулай «нык үскән социализм» төзү елларында ук формалашты.

Татарстанда җан башына туры килә торган җир күләме елдан-ел кими бара. Соңгы 40-50 елда Союз һәм Русиягә караган министрлык һәм ведомстволар җирләрне бездән сорап тормыйча, вәхшиләрчә файдаланды. Нәтиҗәдә Татарстан җан башына иң аз авыл хуҗалыгы җирләре туры килә торган регионга әверелде. Әйе, хаталар гафу ителмәслек күп булды. Җирне кемгә күпме кирәк, шулкадәр тараттык. Автономиялә Татарстан республикасының территориясен билгеләгәндә үк сәясн күзлектән ягъни халкыбызның нисбәтен кимету максатыннан чыгып, татарлар яши торган иң яхшы кара гуфраклы җирләр Татарстаннан читтә калдырылды. Аннан соңгы елларда да өйткәнемчә җирне күп тараттык. Хәзер герлек йөрту өчен көтүлек һәм болынлыклар юк дәрәҗәсендә — барысы 728,7 мең гектар көтүлек һәм 72,1 мең гектар болынлыклар исәпләнә (1995 елның 1 гыйнварына. Сәбәбе мәгълүм: республиканың үзендә һәм Русиянең безгә якын-тирә регионнарында отышсыз гидростанцияләр төзү, яңа завод-фабрикалар яңа калалар салу нәтиҗәсендә гаять күп җирләрне югалттык. Сугыштан соңгы елларда барысы 700 мең гектардан артык болынлык һәм уңдырышлы сөрү җирләре гамәлдән чыкты. Бу җирләрдә өстәмә рәвештә кимендә 420 мең центнер ит, 2 млн 860 мең центнер сөт һәм башка күп төрле продуктлар җитештерергә мөмкин булыр иде. Бу талаулар өчен Татарстан халкы берни дә алмады. 700 мең гектар. Ул да җитмәде. Төрте тыксан да үсә торган кара туфраклы, уңдырышлы җирләребезне беркемнән дә сорап тормыйча КамАЗ нефтехимия төзелешләренә бүлеп алдылар; нефтьчеләр яңадан-яңа җирләрне пычратып га мәлдән чыгара торды. Һаман да җитмәде.

(Ахыры 6 нчы биттә).

Фарсил-Сәхәби ЗЫЯТДИН,
язучы, икътисад фәннәре кандидаты

ТУФРАККА КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫН БИРӘБЕЗМЕ?

(Ахыры. Башы 5 нче битте).

Алабугада трактор заводы төзи башладылар. Дөресрәге, башлап ташладылар. Күпме җирләр бер файдасызга ничә еллар әрәм булып ята. Аннары ике мең гектар җирне, халыкка әйтеп тә тормыйча, атом электр станциясе төзүгә тартып алдылар һәм проектсыз-нисез төзи дә башладылар. Әмма халык бу яман эшне ахырына кадәр җиткерергә ирек куймады. Ничә еллар инде бу җирләр икмәк тә бирми, һәм анда башка төр продукция дә җитештерелми. Ә бит цивилизацияле бер генә илдә дә мондый хәл юк. Киресенчә, аларда һәр квадрат метр җир байлык, табыш китерә.

Тәрбиясезлек, җиргә, табигатькә вәхшиләрчә карау нефть районнарында аеруча күзгә ташлана. Нефть агып гамәлдән чыккан никадәр җирләр... Пычранган елга һәм инешләр, тозлы һәм майлы чишмәләр... Шулай да, кайсы кадерлерәк соң? Җирме, нефтьме? Комсызлар күзлегеннән, унитар дәүләт күзлегеннән караганда, билгеле, нефть кирәк иде. Нефть торгынлык елларында төп байлык чыганагына, яшәү чыганагына әверелде. Җөмһүриятебез җиреннән ел саен йөзәр миллион тонна нефть чыгарылган чорда валюта күп килде, бөек ленинчы Леонид Ильич тарафдарлары, бөтен Союз чиновниклары типтереп яшәделәр. Ә безгә, татарстанлыларга, тозлы чишмәләр, гамәлдән чыккан, икмәк тә, терлек азыгы да үстерә алмаслык, рекультивация үткәрү өчен миллиардларча сум чыгым таләп итә торган җирләр калды. Ә рекультивация үткәрү өчен Союз вакытында да, Русия тарафыннан да акча бүленмәде, чаралар күрелмәде. Ә бит хәтта колонизаторлар да җирле халык белән күпмедер исәпләшкән, саклык чарасын күргән, җирле бюджетка өлеш чыгарган. Ә Русиянең комсызлыгы барысын да уздырды. Хәзер инде нефть районнарында 70 мең гектардан артык авыл хуҗалыгы өчен яраксыз, рекультивация таләп итә торган җирләр исәпләнә. Димәк, бу җирләрне җөмһүриятебез бюджеты исәбенә үзебезгә яңартырга, анда рекультивацияне үзебезгә үткәрергә туры киләчәк.

Үз җирләребезгә чын мәгънәсендә үзебез хуҗа булсак, аны саклап, кадерләп тотсак, җирнең бәрәкәте артыр, республикабызда яшәүче 3 миллион 755 мең кешене генә түгел, 7 миллионны да туендырыр, киендерер. Нефтьне хәзер чамалап, аз-азлап кына чыгарып, җир-суларны зирәкләрчә файдаланып, киләчәк буынга сакларга кирәк. Татарстанның бөтен байлыгы — аның халкының байлыгы. Аңа Русиянең дә, бер генә колонизаторның да кул сузарга хакы юк. Болар 1990 елның 30 августында кабул ителгән мөстәкыйльлек турындагы Декларация белән беркетелә.

Татарстан үз халкын һичшиксез үзе туендыра ала. Моның өчен булган җиребездән нәтиҗәле файдаланырга, гамәлдән чыкканнарын яңартырга, сафка бастырырга кирәк. Болар өстенә, калган колхоз һәм совхозларны да акрынлап чын мәгънәсендә күмәк хуҗалыклар итеп үзгәртеп корырга, фермерларга киң мөмкинлекләр тудырырга кирәк. Иң мөһиме: авыл хуҗалыгы — игенче, терлекче, механизатор диктаттан азат булырга тиеш. Менә шушы өч шартны тормышка ашырганда, җир хуҗалары өчен тагын да киңрәк мөмкинлекләр ачыла.

Ничәмә-ничә еллар буе без бары тик колхозларга гына өмет багладык. Бары тик эре, көчле хуҗалыклар гына җирдән нәтиҗәле файдаланырга мөмкинлек бирә, совет халкын туендыра ала дип лаф ордык. Әмма барып чыкмады. Инде шул хәлгә килеп җиттек ки, табигать шартлары уңай килгән елларда да ачлык яный башлады. Колхозлар төзелгәннән бирле алтмыш ел вакыт үтсә дә, муллык килмәде, һаман продукция кытлыгы булды. Аның каравы, талоннар, купоннар мул иде.

Мондый хәлнең төп сәбәбе — әлегә дә баягы, хуҗасызлык, билгеле. Мин монда колхозларны гаепләргә җыенмыйм. Колхоз — күмәк хуҗалык. Әмма ул әүвәлге мәгънәсен җуйды, җисемен югалтты, бары тик исеме генә калды. Менә шул җисемә беткән колхозлар өстеннән диктаторлар — эреле-ваклы чиновниклар хакимлек итте, хуҗа булды. Игенчене күпме кирәк изделәр, күпчелек хәлләрдә ул колдан да начаррак хәлдә яшәде. Колны көнгә өч тапкыр ашаталар, ә колхозчы айлар, еллар буе хезмәт көненә — бер таякка эшләде. Соңрак елларда хезмәтенә түли башласалар да, ул чак җан сакларга гына җитәрлек иде. Ә мөстәкыйльлек дигәндә, колхоз һәм колхозчы якты киләчәккә алып баручы чиновникларның әмереннән башка кыл да кыймылдата алмады. Тырмага кайчан төшәргә, нәрсә чәчәргә, кайчан утарга, кайчан уракка төшәргә — барысы да тоталитар режимның түрәләре кушуы буенча эшләнде, хәтта ул чиновник авыл хуҗалыгында бернәрсә дә аңламаса да. Колхозларны менә шулар харап итте дә инде. Хәзер исә аларны чын мәгънәсендә ирекле күмәк хуҗалыклар, акционерлык җәмгыятьләре, фермер хуҗалыклары итеп үзгәртеп кору үзенең әйбәт нәтиҗәләрен бирә башлады. Тик бар очракта да түгел. Республика һәм районнарның диктатка күнеккән җитәкчеләре әле һаман да яман гадәтләреннән арына алмыйлар, күмәк хуҗалыкларны кулларыннан ычкындырырга, хакимлек итүне югалтырга теләмиләр. Күп кенә колхозлар һәм совхозларны формаль рәвештә генә үзгәртеп кору иске идарә системасының саклануына китерә. Һаман да өстән боерык бирү, җитештергән продукциясен кайда сату турында күрсәтмә җибәрү, куркыту дәвам итә.

Базар икътисады шартларында хуҗалык итүнең үз принциплары бар. Шуларның иң мөһиме — тулы ирек, мөстәкыйльлек. Яңа үзгәртеп корылган күмәк хуҗалыкларның, акционерлык җәмгыятьләренең, фермер хуҗалыкларының эшчәнлегенә бер генә чиновник та (кануннарны бозмаган очракта) тыкшынырга тиеш түгел, хәтта Президент үзе дә. Бу принцип үтәлгәндә республикадагы чиновникларның катлы-катлы идарә итү системасын камилләштерергә, йөзләрчә файдасыз, дәүләт бюджетын кимерүче чиновникларны кыскартып, аларның эшләп ашый торган тармакларга китүенә ирешергә кирәк. Чынлап та, әйтик, республикабыздагы сөт, ит эшкәртү акционерлык җәмгыятьләренә «Татарстан сөте», «Татмясопром» кебек холдинг компанияләре нигә кирәк? Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, район авыл хуҗалыгы идарәсенә нигә шул кадәр штат? Боларны яңына әле тагын бөтенләй кирәксез корпорация төзеп, аңа штат җыеп яталар. Югыйсә, болай да бер крестиян җилкәсендә ничә чиновник утыра!..

Шуны да онытмаска кирәк: бүген авыл хуҗалыгын барысы да бәләм дип саный, аңа барысы да тыгыла. Алай гына да түгел, күмәк хуҗалыкларны һаман да элеккечә колхозлар итеп кузаллап, ягъни «хуҗасыз милек» дип санап, аның милкен үзенә каеру ягын карый. Имеш, авыл хуҗалыгына һаман да зур күләмдә дотация бирәләр һәм шул сылтау белән аларның эшләренә тыгылалар. 1992-1994 елларда авыл хуҗалыгы зур дотация алды дип әйтү дөреслеккә туры килми. Без кечкенә чакта Гыйльмекамал түтәй балаларны көне буе эшләтә иде дә, менә монысы эшегез өчен дип, бер тәңкә бирә иде, аннары, китәр алдыннан, менә монысы яхшы эшләгәнегез өчен, дип, бер кишер тоттыра иде. Хәзерге колхозларга бирелә торган дотация дә шул кишерне хәтерләтә. 1993 елда хәзерләүчеләр хуҗалыклардан икмәкнең һәр центнерын 5786 сумга сатып алдылар да, кибетләрдә аны уртача 30000 сумга икмәк итеп саттылар. 1994 елда 15200 сумга сатып алдылар да, ел әйләнәсендә уртача 90000 сумга саттылар. Быел исә һәр центнерын 8 долларга, ягъни 36000 сумга сатып алып, хәзер үк инде кибетләрдә аны уртача 150 мең сумга сатарга керештеләр. Яңа уңышка кадәр әле ул, прогноз буенча, 2-3 тапкыр артачак. Барлык төр авыл хуҗалыгы продуктларын да шулай исәпләп чыксак, хуҗалыкларга бирелә торган дотация сатып алу бәяләре белән ваклап сату бәяләре арасындагы аерманың бары тик бер өлешен генә тәшкил итә.

Моның шулай икәнен колхозлар, күмәк хуҗалыкларның бүгенге аяныч хәле дә ачык күрсәтә. Төп фондлар искергәннән-искерә, техника яңартылмый, ашлама куллану кими, авылларда һәр төр төзелеш туктатылды диярлек. Ә бит тирәннәнрәк уйлап карасаң, бу елларда бездә ит һәм сөт җитештерү тотрыклы калды, тарихта булмаган икмәк үстерелде. Җитештерелгән продукциягә да сорау бар, продукция сатылмыйча ятмый. Димәк, күмәк хуҗалыкларның иң мантып китәр чагы, югыйсә. Әмма промышленность товарларына бәяләрнең ирекле, ә авыл хуҗалыгы продукциясенә көйләүле булуы зур зыян китерә. Хәзер трактор һәм комбайннарны, туфрак эшкәртү машиналарын, ашлама, төзелеш материалларын сатып алу кискен кимеде. 1994 елда тракторлар сатып алу, 1985 ел белән чагыштырганда, 6 тапкыр кимеде һәм нибары 865 трактор гына алынды. Узган ел 1181 авыл хуҗалыгы предприятиесе нибары 386 комбайн, 292 сабан, 296 чәчкеч, 58 ашлык чистарту машинасы сатып алган. Икенче төрле әйткәндә, комбайннарны сатып алу 9 тапкыр, йөк автомашиналарын — 3 тапкыр, экскаватор һәм башка төр машиналар алу 20 тапкыр кимеде. Кырларда эшләүче тракторларның саны бер ел эчендә 1 меңгә кимеде. Һәр гектар сөрүлек җиргә нибары 1,3 центнер гына минераль ашламалар кулланылды. Авыл хуҗалыгында капитал салымнар үзләштерү 1990 ел белән чагыштырганда ун тапкыр диярлек кимеде; шул исәптән мөгезле эре терлек тораклары төзү 2,6 тапкыр, дуңгыз торaклары — 15, сарык торaклары төзү 17 тапкыр кыскарды. Болар барысы да төп җитештерү средстволарының кискен кимүе турында сөйли һәм бу, үз чиратында, алдагы елларда тулай продукция җитештерүнең аска тәгәрәвенә китерәчәк. Моның яңа кризиска этәрүе дә ихтимал.

Күзәтүләрдән чыгып әйткәндә, авыл хуҗалыгына дотация бирелә дип сөйләнгәнче, чынлап та аны эшләргә кирәк. Җитештерүчеләргә ирек, җиргә кадер булса, җитештерелгән продукциягә, промышленность товарларының бәяләрен истә тотып, эквивалентлы сатып алу бәяләре яисә ирекле бәяләр кулланылса, республиканың авыл хуҗалыгы кооперативлары, күмәк хуҗалыклар, фермерлар яңа шартларда киләчәктә дә сынатмаслар. Билгеле, корылык, бәла-каза килгәндә, югалтуларны капларда һәр цивилизацияле илдә булышалар. Мондый хәл туганда Татарстан хөкүмәте генә читтә калмас дип ышанасы килә.

Әнә шулай җөмһүриятебез авыл хуҗалыгы үтә катлаулы, каршылыклы юллар аша үтеп, базар икътисады шартларына җайлаша бара. Әлегә продукция җитештерү бераз кимесә дә, тотрыклы кала. Җирле шартлардан чыгып, хезмәт кешесенең теләгенә карап, колхоз һәм совхозлар урынына хуҗалык итүнең төрле формалары барлыкка килә, хосусыйлаштыру дәвам итә. Булсын, төрлесе булсын. Тик аларның һәркайсына тигез шартлар, мөмкинлекләр тудырылсын. Әгәр дә алар җирне кадерләсәләр, аннан тагын да нәтиҗәлерәк файдалансалар, халкыбызга файдадан башка зыян килмәс. Иң мөһиме, әйткәнемчә, игенчегә, крестиянгә ирек, мөстәкыйльлек, ә төп байлыгыбыз булган җиргә кадер булсын.

Әнгам АТНАБАЕВ

Төш

(Шаяру)

Мин бер көнне кинәт үлеп киттем —
Шундый рәхәт, шундый күңелле!
Үлә гөүдәм тере чәчәкләргә,
Мактауларга, данга күмелде.

Дошман дигәннәрем дус булдылар —
Керфекләре яшькә чыланды,
Газеталар кара кайгы белән
Сурәтемне басып чыгарды.

Исемемне алла исемедәй
Кабатлыйлар яхшы сыйфаттан,
Иң кадерле изге бер йөк сыман
Күтәрәләр мине чиратлап.

Эшләпәсен салган министрлар,
Завлар, замнар җөяү атлыйлар,
Көн аралаш сүккән төнкыйтьчеләр
Баш очыма басып мактыйлар.

Гомер буе мин язганмын, имеш,
Почти гениальный әсәрләр,
Мин үлгәч тә, шушы әсәрләрем
Миңа һәйкәл булып яшәрләр.

Хәтта хатын мактый: эчмәгәнмен,
Гулять итмәгәнмен, уңганмын,
Алтын кебек кеше булганмын бит,
Үлеп кенә харап булганмын...

Әй мактыйлар мине, әй данлыйлар —
Портретлар тыңлап көнләшә.
Кеше үзенең бөек икәнлеген
Каян белер иде үлмәсә?!

Таныш булмаган этке

Аптырарсың!
Нинди гадәт, нинди холыктыр ул —
Бу дөньяда эткә эндәшмәгән
Аның белән сөйләшмәгән
Шагыйрь бармы икән? — юктыр ул.

Мин дә
Синең белән сөйләшергә булдым.
Сорамыймын затың, атыңны.
Тәшеп калган эттән түгелсеңдер,
Күз карашың болай акыллы.

Хуҗаң каршысында сырпаланып,
Ураласың аяк астында;
Койрыкны да матур болгалыйсың
Һәм болгыйсың кирәк вакытында.

Ризык бирсә, кулын яларга да
Оялмыйсың рәхмәт йөзеннән.
Сөяк белен тукмап озатса да,
Гаеп эзлисең тик үзеңнән.

Ул елмайган чакта — елмаясың,
Ул елаган чакта — елыйсың,
Ни кыланса — шуны кыланасың,
Ни уйласа — шуны уйлыйсың.

Синең бурычың шул, чонки син эт,
Этлек эшләсәң дә килешә...
Шунысы начар: бөгезе дус-ишләр бар,
Кыланалар нәкъ тә синеңчә.

Хәтта уздырып та җибәрәләр,
(Алар кеше — алдан күрәләр!)
Шәп чагында койрык болгыйлар да,
Хәрт чагында хурлап өрәләр.

Хәсрәтеңнән биеп шатланалар,
Шатлыгыңнан — көеп кайгыра,
Башларыңа бәла төшкән мәлдә
Тәртәләрен читкә каера.

Бер карасаң — алар калай әтәч,
Бер карасаң — куркак ялагай...
Кемлегеңне, сәләтеңә түгел,
Дәрәҗәңә карап бәялай.
Син аларга, әнем, җите алмыйсың:
Ә шулай да әйтәм турысын
Эт булсаң да, безгә караганда,
Тугрылыкта ныграк тугрысың.

Чабата

«Татар баеса, чабатасын түргә элә»
Халык сүзе

Үзәк Уфа базарында
Ниндидер Гаптелгата
Безнең яшьлек чабатасын
Сувенир итеп сата.

Туфли алырлык хак биреп,
Алдым да чабатасын,
Элеп куйдым түр башына..
... Уйласаң — шаккатасың!

Ничә йөз елларда түгел,
Тик безнең мәлдә генә
Чабатаны да җиткердек
Сувенир хәлләренә.

... Җидедән үргән чабата
Аякка җайлы ята...
Юеш борын кайтып килә
Пычракка бата-бата.

Борыны юеш булса да,
Булса да чабаталы,
Югары очның зәңгәр күзен
Озатып кайткан чагы.

Күзләрендә — сөйгәненең
Исерткеч зәңгәрлеге,
Киндер күлмәгенә сыймый
Егетлек зәһәрлеге!

Еллары кара булса да,
Яшьлекне тыеп кара!
Төн озыны кыз озатып,
Иртән эшенә бара.

Чабата киеп күтәрдек
Заманның күпме йөген?!
Менә шушы чабатаны
Түремә элдем бүген.

Ләкин, зинһар, уйламагыз
Бу татар баеган, дип,
Уйласагыз, уйлагыз тик
Яшьлеген сагынган, дип.

Аракыга дан җыры

(Шаяру катыш)

Кече яшьтән таныш ап-ак башың,
Мәңге сүнмәс кайнар йөрәгең,
Йөрәгеңнең сүнмәс кайнарлыгын
Йөз граммлап эчеп өйрәндем.

Шатлыкны да сиңа салып юдым,
Кайгымны да синдә тараттым,
Мин бит сине кырык градуслы
Саф мәхәббәт белән яраттым.

Яратышкан, имеш, дип сөйлиләр
Таһир белән Зөһрә турында,
Синең белән минем мәхәббәткә
Караганда алар ерунда!

Аякларым атлый алмаса да,
Күңел һаман сиңа гартыла,
Синең алда мин кечкенә сыман,
Бөтен гомерем тормый яртыңа!

И аракым, җаным, синнән башка
Көнем кара, төнем күңелсез,
Шунсы жәлке бер чак мин үләрмен,
Син калырсың — син бит үлемсез!

Газаплы сорау

Күп гасырлы бөек тарихында
Күп сыналды татар баласы...
Сугыш елларында әсирлектә —
Төрмәләрдә
фашист палачы
Башын кискәндә дә үзебезчә
Җырлап үлде татар уллары,

Җырлап үлгән татар улларының
Бүген яшәп яткан уллары,
Телегезне кемнәр алыштырды,
Җырыгызны кемнәр урлады?

Кәчләп чукындырган заманда да
Чукынмаган иде телебез,
Хәзер нинди шайтан котырта соң? —
Теләп чукынабыз үзебез.

Күкрәк сөтедәй саф ана телен
Әйләндердек мама теленә
Ни урысча, ни татарча белмәс
Имгәтелгән буын тиләрә.

Алар белми телнең матурлыгын,
Алар белми милләт кадерен,
Алар белми мирас-варислыкны,
Ата-бабаларның каберен
Һәм алардан калган васыятьнә

Укый белми бахыр балалар —
Тарихыннан язган чи надаңнар
Һәм сукырлар
Кая баралар?

Һаман шулай дәвам итәр микән,
Әллә булыр микән азагы?
Йөрәгемне шундый сорау теләә,
Тынгы бирми шуның газабы.

Милли «дус»ка

Татар-башкорт мәсьәләсе
Каяндыр килә һаман —
Бетми торган чир шикелле
Теңкәгә тия һаман.

«Ник татарча һөйләшәһең,
Башкортса һөйләш, имеш,
Был һөйләшең менән һиңә
Казанга китеү тейеш!»

Нишләп Казанга китим ди,
Шушында туып-үскәч?
Яфрак ярып, чәчкә атып,
Җимешле булып пешкәч?

Нишләп Казанга китим ди?
Шушында атым-затым —
Минем сөйләшне аңлаучы
Миллионнан артык халкым.

Нишләп Казанга китим ди?
Шушында минем Уфам,
Казанда яшәп Уфаны
Сагына иде Туфан...

Моннан ары «һин татар» дип,
Җаныма тимә, давай
Җанга тиеп, җан ачуын
Чыгара күрмә, малай!

Син ашыктың, без соңладык

Ринат Хәйринең якты истәлегенә

Алтмыш яшьлек чал башымны иеп
Кайгы табынында утырам,
Бокалыма шигырь моңнарыңны
Күз яшемә кушып тутырам.

Һәм күтәрәм синең истәлеккә,
Бигрәк үкенечле үлем, дип,
Акыл ышанса да күңел белән
Ышанырга мөмкин түгел, дип

Һәм заманга үпкә белдерәмен,
Рәхимсез усал заман, дип,
Йомшакларга бигрәк каты куллы,
Яхшыларга бигрәк яман, дип.

Ваемсызлык үзәкләргә үтә
Һәм гамьсезлек үрли төрләргә,
Шагыйрь халкы өчен бөтен шартлар
Тудырылган тизрәк үләргә.

Кайда барып бәрелергә белми
Чәбәләнә алар дөньяда,
Яшәүләре гел тәмугтан торгач,
Оҗмахларын эзләп югала...

Син ашыктың, без соңладык бугай.
Заман белми шагыйрь кадерен...
... Бер як читтә үзең кебек тыйнак,
Моңсуланып ята каберең.
Заман белми шагыйрь кадерен.

Менә шулай!

Көн дә иртән «Великая Русь» дип,
Уяталар урыс чаңнары...
Менә тагын урыс кышы җитте,
Күрәп ява урыс карлары.

Тәрәзәмнән миңа карап тора
Миллионлаган урыс каены,
Һәр каенда урыс ботагы бар,
Һәр ботагы урыс кайрылы.

Ишегемне ачып тышка чыгам,
Җәелеп ята урыс кинлеге,
Урыс киңлегендә мул урожай
Бирде быел урыс киндере.

Урыс киңлекләре төмамлангач,
Каршы ала урыс урманы,
Һәрбер төбен берәр поллитрга
Сатып эчә урыс Иваны.

Урманнарны урап өйгә кайтам,
Урыс мунчаларын ягылган,
Урыс тастымалын сыга-сыга
Урыс чәен эчәм табында.

Урыс мәе белән кәефләнәм,
Радиодан урыс акыра,
Телевизор аша митрополит
Урыс чиркәвенә чакыра.

Хатыным да оныклары белән
Сука сөрә урыс теленә..
Менә шулай яшәп яткан булам
Мин — чи татар башкорт илендә

Күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче, озак еллар әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебезнең җаваплы эшләрен үтәгән Фәрваз Миңнуллин татарның асыл егете иде. Серләребез уртак иде безнең, гамәлләребез бер-берсенә яраша иде. Без вакытыбызны һич жәлләмичә бер-беребезгә багышлый килдек. Аның: «Балта явызлар кулында» исемле иң соңгы мәкаләсе дә миңа җавап иде. Унберенче декабрьдә аның үлеменә бер ел тула. Соңгы елларда өзлексез языла торган көндәлекләремдә аның исеме еш очрый. Шул дәфтәрдән аерып, бер өзекне укучыларга тәкъдим итәм — аны сагынуымның билгесе булсын.

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ,
Татарстанның халык язучысы

«Сирәгәеп калды

17 октябрь, 1993 ел,
Переделкино, иртә.

Иҗат йортына 15 endә килеп төштем. 107 нче бүлмәгә җайлы гына урнаштым Мин үзгәрәм, күзәнәкләр ашыга-ашыга алмашыналар. дөнья да тик тормый чайкала. болгана, тоташтан бурый Аста. топтә ятканнар, күбеккә әверелеп, өскә калкалар. күзне сукырайталар Ак йортны тупка тотканнан соң андагы ялкын-уттан барчабызга тавык күзе булды, көндезләрен дә эңгер-меңгер иңгән сыман. акны карадан һич аерып булмый Исе бар мәгәр дөньяның, исе килә, борыннары тыгылганнар да сизә: кан исе Русиядә!

Килеп төшүгә мине Н каршы алды, рәхмәт инде, машинкамны, шактый авыр чемоданнарны сөйрәп, Казан вокзалыннан Киев станциясенә кадәр җир аслай үтү җиңел булмас иде. Болай да пешеп-янып, манма су булып, гыжылдап, тырык-тырык барып җиттек. Мәшһүр мәркәзебез кул арбасына күчкән икән, шаклар катарсың! Сәүдәгәрләр, капчыклар, тонган күзләр...

Таң белән, яктырганчы ук ез-мәз эшкә кузгатып карадым. Ашыкмый өлә уйлаган эшем, тәгәрмәчләре дүртесе дүрт төрле кабык арбага җигелгән колхоз алашасы сыман теркелди. Өйдә чакта уйлап бетермәгәнмен, тагын төрмә темасына ябышканмын икән!

Н. да «Мәскәү водовороты»на — Ак йорт тирәсе чуалышларына эләккән, аның да суырып йота торган уртасына тап булган, сугыш байтактан тынса да секунд та тик тора алмый, сөйли, үгетли, сүзен куәтләмәсәң, үпкәли. Ельцинны адәм тәганәсенә чыгарып каһәрли, демократларның тетмәсен тетә, яһүдләрне сүгә «Шулар җитте Рәсәй башына», ди. Иң гаҗәбе, ике сүзенең берендә Хасбулатовны мактый Аныңча, Руслан Имранович чат фәрештә булган икән! Ул «акыллы», «өзерлекле», «белемле», «үз юлында нык торучы шәхес», ул «сөйкемле», «әнкәсе белән бергә төшкән фотосын күрдем, булса да булыр икән сылу ир!», «Лидер, эрудит!» Коммунистик режимны үлеп сагына Н. Дәлиле бер: «Менә әйтеп кара, ничә тапкыр вәгъдәләр бирде Ельцин, халыкны ышандырды, әйткән бер-бер сүзен үтәдеме?!» Җылымса сүзләре белән генә мине үз ягына дүндәрә алмагач, акчасын җәлләми, кочагы-кочагы белән гәзитләр күтәреп керә.

Көн саен, ашавын, эшен онытып, Мәскәүгә чаба икән Н. Кемнәрдер аны минут саен телефонга чакырып торалар. Фикердәшләреме? Гәзитләрне дә шулар биреп җибәрми микән әле? Иҗат йортында аның тоткан юлын, мәсләген беләләр, хуҗалык эшендәге маржалар, язучылардан урыс-улак аңа еш кына мөрәҗәгать итә, Н. белән янәшә күреп, мине дә аның теләктәше дип уйлыйлар Егерме-егерме биш ел авызыннан сүзе чыкмаган ишек төбен саклаучы Лида да мине әгъвәли: «Яһүдләр генә гаепле Рәсәйне шулар сата! Өченче-дүртенче октябрьләрдә, фетнә көннәрендә аларны күзәтеп тору кызык иде! Йорттан читтә, аулакта җыелырга сүз берләшәләр, унар-унбишәр кеше түгәрәк булып басалар да шыпырт кына киңәшәләр. «Нишләргә? Качаргамы, калыргамы?»! диләр бугай... Переделкино иҗат йортын да үзләре өчен салдырды ич яһүдләр.. Бушлай киләләр, бушка карт-корыларын, бала-чагаларын китерәләр. Алар өчен оҗмах инде бу! Кызганыч, койрыкларына баса алмадылар».

Сәясәттән бөтенләй читтә торганнарны да талаш-ызгыш мәйданнары уртасына өерләп кертте бу октябрь ае. Бөтен халык эшен ташлап, кешелек бурычларын онытып, белер-белмес көйгә кая баруы билгесез сәясәт арбасына җигелеп чаба башлый икән — революция әнә шул инде ул.

Гәзитләр кыю. Яңа Октябрь вакыйгаларына капма-каршы бәяләр биреп, дөреслекне йон-йомгак эченә яшерәләр Йомгакның җеп очын эзләп таба алсаң да кайчан сүтеп бетерәсең әле аны!.. Станислав Говорухинның сугышчан отрядлар җыйнап. ашыгыч рәвештә Ельцин тарафдарларына каршы көрәшкә өндәвен бер яклырак кабул итеп аңлаган кебек идем Элек тә коммунистик режимга ачыктан-ачык каршы төшкән. шул какшамас якты иманнары өчен мин яратып өлгергән кайбер затлар да бу чуалыш сәгатьләрендә Ельцинның гамәлләрен гафу ителмәслек явызлык дип бәяләделәр.

Станислав Говорухин исә бу дәһшәтле көннәрне «Русияне атып үтерү» дип бәяли «Русиядә каһәрле көннәр башланды». дип тәмамлый ул «Известия» гәзитендәге мәкаләсен.

Әйе, без — Сталин чоры балалары, Руцкой-Хасбулатовларны «атып үтереп кенә илне коткарып була!» дип санаганда, аларга әҗәл-үлем теләп, кесәдәге йодрыкларны йомарлаганда кешеләр тирәннәнрәк тә уйлаганнар икән! Синявский, Максимовлар да бер сүздә булып Ельцин гамәлләрен «ирекне буу!» дип бәяләделәр Бу очракта мин тагын да беркатлылык күрсәттемме? Кабат ялгыштыммы? Ельцин кай ягы белән «алдырды» соң?.. Беренче нәүбәттә ул коммунистлар партиясеннән чыкты Икенчедән, ул җаһилләр партиясен таратты Дөрес, таратуы ахырына кадәр үк барып җитмәде, алай да, үз вакытында бу карар, тарату нияте миңа рух өстәгән иде

Дөрес, гәзитләрдә бара торган тартышлар, ызгышлар, телдән телгә җиңел күчеп йөргән уйдырмалар уемнан кайтара алмадылар, мәгәр Мәскәү мохитенә барып кереп, йөк-йөк хәбәрләр тоялгән гәзитләрне күзәткәннән соң, җанымда нидер кителде Адәм җаннарын кыймыйча гына фашистик оппозициядән котылып булмас идемени?. Әллә ленинизм идеяләренең йогышыннан кан коюю белән генә котылып буламы?

Быелгы 3-4 октябрьдән соң кемнәрдер тагын үзгәрәләр, көнгә-сәгатькә кулай битлекләр киеп алалар, андыйларның запас битлекләре бер чакта да үзләреннән калмый, өзер тора, мәгәр бер нәрсә ап-ачык — акыллы адәмнәрнең байтагы Ельциннан һич канәгать түгел!

Авыр яшьлек елларын иленнән читкә сөрелгән, кыйналган гаиләдә үткәргән, нужаның иң өчесен татыган Н. фикерләрендә дә хаклык бармы әллә? Ул егет үз иманында кала килә түгелме?

Мондый шик-шөбһәләр көннән-көн арта. җәмгыять кап урталайга ярыла... Моменттан файдаланып, ил башына Геннадий Зюганов, Саҗи Умалатова, Аман Тулеев яраннары менеп атланмасмы? Әйе. әйе, акыл дилбегәсен кулдан ычкындырырга да. җебеп калырга да ярамый! Руслан Хасбулатов булдымы Ил башы? Татарстан суверенлыгы җәһәтеннән. әйткән бәяләмәләрен татарлар мәңге онытырга тиеш түгел! Ничә айлар безнең өскә салкын, үтергеч сүзләр койган буш бугаз! Күз алдыбызда сансыз-исәпсез мәртәбә бездән — гади кешеләрдән мәсхәрәләп көлгән җирбит! Брежнев комсызга атап салынган 500 кв. метрлы зиннәтле әкияти сарайга бөгрәеп кереп утырды. Туксан проценты илне имеп, күзләрен кан баскан коммунистлардан укмашкан парламентны тәмам котыртып җиткерде чечен-бандит!.. Бүтәннәрне аермачык белмим, мәгәр Татарстаннан Югары Советта бер генә акыллы. халык кайгысын үзенеке итә алган шәхес юк иде Бер генә дә! Бөек фикер иясе. мөхтәрәм Андрей Дмитриевич Сахаровны: «Долой!!!» дип. югары мөнбәрдән куып төшерүчеләр дә Татарстан депутатлары иде бит...

Мин былтыр монда «Йәгез, бер дога!» белән җенләнеп ята идем Быел роман журналда басылып чыгып килә Куен дәфтәремә «1 ноябрь, 1991 ел. Переделкинога килеп урнаштым, 114 нче бүлмәгә «Йәгез, бер дога»ны язарга исәп. Озаккарак сузылды», дип теркәп куйганмын. Аңа кадәр үк яза, материаллар туплый башлаган идем, 91 дә исә, бүтән эшләремне читкә куеп, «дога» укырга керештем. «Коръән» белән генә ярты ел утырдым!.. Тәңремә рәхмәт, ниһаять, быел ул эштән котылдым Моның кадәр дә газапланганым, бәргәләнгәнем, җан талатканым шушы чаклы интектергән, җан талаган әсәрем юк иде шикелле. Авыр язылды. инде алдагы бүлекләр тәмам дип исәпләгәндә дә романның азаккы өлеше юк иде әле Азак хәзер дә канәгатьләндерми. Ни эзләнеп, ни төпченеп казынып, ахыргы фикерләремне югары. көчле тавыш белән күк күкрәтеп әйтеп бирә алмадым.

Быелгы ел да җиңеллә́рдән түгел иде... Тәвәккәлләп Переделкинога чыгып китәрлек ихтыяр көчем дә калмады Нәкыя кыстап, үгетләп җибәрмәсә өненнән көнгә чыгарга өнәмәгән карт аю хәлендә караватта аунап ятасы идем. Юлга чыгар алдыннан җентекләп карыйм мүкләнә башлаганмын, валлаһи! Моңарчы яшәешемдә гел бер тәртип булды өзгәләнеп-хурланып Казанда яшим-яшим дә, дөнья боҗрасы тынымны кысып буа башлагач, чыгып таям. дөньяның шушы бәрәкәтле, юмарт почмагына килеп егылам. Октябрь айларында гел монда булам диярлек.

Переделкино яфракларының коелганын карарга яратам мин!

Гайрәт белән агачларны аралап килеп җиткән көзге җилләрен сагынып киләм бу төбәкнең! Тәрәз пыялаларының рәхәт салкынлыгына пелешләнә башлаган кайнар маңгаемны терәп, өермә булып тузгыган сары буран ташкынына озак-озак карап торам. Көнне камаган давыл белән күкрәктәге ярсу хисләр бер-берсен эзләп табалар да мине өерләп җиңеләйтеп күккә ашыралар. Кайный-кайный яфрак бураннарын тузгыта көзге урман!

Быел соңгарак калганмын, урманнар тоташ шәрәләнгән, сукмакларга калын-калын быелгы юрганнар түшәлгән. Яфраксыз калган шыр урман тавышларны төрле якларга тигез тарата. Быел, октябрь орышларыннан соң тирә-яктагы тавышлар да үзгә, бүтенчә яңгырый Ике-өч кешә гөр-гөр килеп ашханә верандасының түбәсен ямыйлар — кешә тавышлары пулемет тырылдагандай була Берәвесе төчкерсә — янда гына мина ярылгандай яңгырый. Борын сеңгерсәләр — бомба төштеме әллә, дип куркып торасың. Дөнья алмашынганда тавышлар да тиз-тиз үзгәрә.

Кичә-бүген ихата эчендәге борма сукмаклардан җил-җил йөрим, тынычлыкка зарыккан күңел киңәя, куана, инде ниятләп килгән эшне дә беркадәр алга җибәрә алсам...

Шушы төштә язуымнан туктап, озак кына уйланып, баш ватып утырдым Килеп керүгә чытырдап эшкә ябыша торган идем, быел күңелдә иләс-миләслек, сүрән төшенкелек. Язучы үзенең иң яхшы әсәрләрен яшәгән төбәгеннән читкәрәк киткәндә яза. Өйдә, Казанда чакта өзмәс быкырдыйсың, вак-төяк тигәнәкләр, кормавыклар итәгеңә, балагыңа ябыша, чүп-чар урала. Переделкино минем өчен калку урындагы сәхнә дә ул. Сизәм, быел хәлләр бүтәнчәрәк Әле Мәскәү өстендә Ак йорт янган минутларның кап-кара сөреме йөзеп йөри. Дөнья моны оныттырмый, тиз генә оныттырмас та... Башка илләрдә сәфәргә чыгып, Казан хәлләрен, ыгы-зыгыларны тәмам онытып тора идем. Быел чыңлап торган ачы хәсрәт күңелемә ияреп килде. Фәрваз чирли, Фәрваз! Әзгә генә булса да аны онытып тормакчы булам, юк, кылт итеп көзге очрашуларыбызның берсе хәтергә төшә дә... дерт итеп сискәнеп китәм. Үлсә, бу дөньядан, безнең яннан китеп барса?!

Төрмәдән кайткач, мин университетта, әлеге дә баягы, икенче курста укый башладым. Фәрваз белән шунда таныштык, тиз аңлаштык, якынайдык. Җитдилеге үзенә тарттымы, җиңеллеге, шук-шаянлыгы ошадымы? Баштарак мин өйләндем — ул кияү егете иде Соңрак Фәрваз Сания исемле кызны яр итте, кияү егете булып, кыз алырга мин бардым. Без тормышны корып җибәрдек, алар да ипле генә яшәп киттеләр, малай белән кыз үстерделәр...

Фәрваз, Фәрваз... Күңелдән һич китмәскә ияреп килгән бу сөйкемле исем! Язучылар берлегендә эшләгән чагын нык хәтерлим мин аның, үтә тырыш, намуслы һәм уңган егет иде. Союзның бөтен эшен берүзе сөйрәде диярлек. Мөдәррис Мусинны өнәмәде, яратмавын яшермәде дә. Үткән съездларның берсендә шыпырт кына «переворот» езерләделәр һәм, алдан чак кына да белдермичә, Фәрвазны алып ыргытып, урынына Разил Вәлиевне Чаллыдан кайтардылар. Шушы белдерү ясалганнан соң эшсез вә урынсыз калган гаепсез Фәрвазның кыяфәте күз алдымда... Әҗәлгә алып баручы чире шул съезддан башланмады микән?! Көл төсенә кергән Фәрваз янынннан шыпан-шыпан гына качты съезд халкы. Ары-бире карангач, оятларына көч килеп, Шәүкәт Галиевне «эшеннән азат итеп», шул урынга Фәрвазны тәгаенләделәр. Егетне бөтенләй үк урамда калдырырга ярамаганлыгын бөтен кеше дә ачык белә иде Шәүкәт урынында утырды Фәрваз. «Казан утлары»на баш мөхәррир сыйфатында барасы килде, барып чыкмады. Союз рәисе булырга теләгән Равил Фәйзуллинны журналга җибәреп «төс сакладылар». Бара-тора Фәрваз нәшриятта баш мөхәррир дәрәҗәсе алды, намусын сатмады. Шушы җайсыз чорда әдәбият үсешенә кулыннан килгәнчә рыясыз булышып килде

Туксан дүрттә аңа нәкъ алтмыш тула «Саулыгым какшады», дип элегрәк тә уфтана иде, менә ике-өч ел инде ул очраган саен зарлана. Егет дәва эзләп уңга-сулга каерылды, үләннәр эчте, дарулар йотты Хәле торган саен авырлашты. Хастаханә кунагы булып китте берзаман Фәрвазыбыз. Кherә, ята, тикшерелә, бик сирәк очрый торган әмрикән тоймәләрен алып чыга, шулар ярдәмендә әл-хәл ала Күңелендә шом «Безнең нәселдән ир-аттан алтмышны үтә алганнар юк!» Күңел кап-

касын киереп ачып, ШОМга юл бирдеңме — беттең..

Китәремә атна калгач, карчыклар чуагының матур, йомшак бер көнендә Литвин белән Фәрваз янына кагылдык Алексей Львовичның үз йомышлары, минем дә нәни генә белешәсе эшем бар, берочтан юлга чыгар алдыннан саубуллашырга да кирәк Кердек, утырдык, сүз ялганмый интектерде Була бит, өчебезнең дә тел очында сүзләр туып сүнә, берәү дә ачыктан-ачык уртадагы суык учакка ботак ташларга ашыкмый Фәрваз элек тә уфтангалый торган иде, ниһаять, өстәлгә түше белән ятып, янтаеп зарланырга тотынды «Авырта.. теге дару сызлауларны баса торган иде элек, хәзер дару юк. Казанда да юк икән! Польшада бар диләр, кабы йөз мең сум! Ул кадәр акчаны мин каян алыйм! Һич түзәр әмәл калмады.» Эссе көн, беркү бүлмә, дәүләт оешмаларында ремонт гасырлар буе тукталмый, коридордан буяу исе саркыла, тынны кыса. Фәрваз тәрәзәгә моңсу гына карап алды да: «Әллә иртәгә бер җай табып табигатькә чыгып керәбезме?» дип сорады. Без, Литвин белән алмаш-тилмәш, аның бу фикерен хупларга тотындык.

урманлык...»

Килешенгәнчә, көндезге өчтә машина белән алар килеп җиттә, мин чыгып утырдым, яңа диярлек «Волга» машинасы алга элдерде. Литвин белән Фәрваз арткы урыннарда, Фәрваз аякларын кая куярга белмәгәндәй, ярым ятып, кыймшанып, әйләнгәләп бара. Литвин үз дачасына барырга өнди, мин:«Кая алай еракка? Ике сәгатьтән караңгы төшә, якты күздә кайтып элгешергә иде!» дип кирегә сукалыйм Чуар-чабар киемнәргә төренеп каршылаган урман эчләп беравык бардык, машинага юл еракмыни, «Аккош күле»нә якынлаштык. «Аккош күлендә туктыйбыз», диде Фәрваз. Без риза, җил ягыннан гына торабыз, Фәрвазга каршы сыңар уебыз да юк. Уңга борылдык, язучылар дачасына таба юл алдык. Бу сукмак-юлларда байтактан булганым юк иде, онытылган, ятсынып як-ягыма карап барам. Урман эчләп әллә нинди коттеджлар, йорт-куралар салып бетергәннәр, юан-юан аркандай койрыкларын селкеп олы, авыр авызлы этләр шигәеп озатып кала. Барып җиттек. Әдипләрнең тарихи, мәшһүр мәйданын уңда калдырып, алгарак үттек, канатлары салынган капка белән җирне тырнап ачып, дачаның эченә үк барып кердек. Җирдә башлары муртайган өч-дүрт бүрәнә ауный, уртада агач төбе. Яндагы йортка ишарәләп, Фәрваз: «Монда Равил Фәйзуллин тора». диде дә «Теге башында Мансур Вәлиев», дип өстәде. Литвин букчасыннан коньяк чыгарды, мин вак-төяк ризык хәстәрләгән идем, коньяктан соң йотарга су да ачтык. Фәрваз эчәрме, юкмы дип көтеп тордык, кулы белән ишарәләп «Миңа да салыгыз!» дигәч, каршы килмәдек. Дустыбызның хәлен ачык белгәнгә, җитди сүз үргетү шактый кыен иде кыенын. Ни турында кузгатсаң да сүз яшәү белән үлем тирәсенә барып керә, ярый әле, юморга шактый оста булган Литвин коткарды. Коньяктан соң тел ачыла, ул килештереп кенә бер-ике анекдот та сөйләп алды. Гадәтенчә, яһүдләр турында яһүд чыгарганнарны сөйли ул. «Бер йортның урам як ишегенә кайчы сурәте ясалган такта элгәннәр икән. Үтеп баручы берәү ашыгып кына килеп керә дә. «Монда чәч алалармы?» дип сорый. «Юк, — дигән хуҗа, карт яһүд, — монда сөннәткә утырталар» «Ник алайса кайчы сурәте ясап элдегез соң?» Хуҗаның кашы өскә сикергән «Ә нинди сурәт ясарга боерасыз?» Мин Литвинга, Фәрваз миңа ияреп көлде... Тәки коньякның башына җиттек, тәвәккәлләп, Фәрваз да капкалады Ризык чемченеп, шара-бара сөйләшкәләп басып тордык та баягы капканы йокысыннан уятып, шыгырдатып ачып урман якка чыктык Төмле-татлы исләр таратып яткан урман юлы буйлап атлыйбыз, аякларыбыз балачактагы кебек рәхәткә чумып, кызгылт-сары яфракларны көрәп юл ачалар Кинәт Фәрваз сүзсез генә алга ыргылды бер җир буе барды, тукталды иелеп җирдән нидер алды Тын гына, каккан казыктай шунда хәтсез вакыт басып торды Литвин белән без бер-беребезгә караштык һәм икебезгә дә бер уй, шомлы һәм аяусыз уй иңде «Урман белән саубуллаша бит бу егет!» Безнең шикне раслагандай, Фәрваз яныбызга борылып килергә ашыкмады үзе генә белгән нокталарны эзләгәндәй әйләнеп-тулганып йөрде, таныш агачларының көүсәләрен сөеп-сыйпап басып торды әле бер куентыкка, әле икенчесенә барып керде, нидер эзләде, тапкан сыман да булды Без аның ялгызлыгын бозмас өчен кыймшана да алмыйча, өсәренеп басып тордык Борылып килгәндә дә аның олы җитдилеге кимемәгән, ул тирә-якны күкрәгенә сыйдырырга телләгәндәй, як-ягына текәлеп карый-карый авыр гына атлый иде Без аны сүзсез генә каршыладык, ул да сүз әйтергә ашыкмады Ниндидер тантаналы, сәер тынлыкта машинага кереп утырдык Фәрвазның бу тирәләрдән җәһәт кенә аерыласы килми иде, ахрысы, күл турына җитәрәк, ул машинаны уң кул якка борырга кушты, «Волга»быз суга терәлеп диярлек янтаеп туктады. Машинадан төшкәч Фәрваз баягы җитезлек белән яр буйлап теге башка китте, тукталды, озак итеп күлнең җансыз, шыксыз суына текәлеп-текәлеп карап торды, баш очына шәрә ботакларын сузган таныш агачларга каранды Ул монда яшәгән ләбаса! Без баягы шомлы фикерне кабатладык. «Күл белән саубуллашуы егетнең!» дидек Бу юлы ул иләп адымнарын санап, як-ягына җете каранып килде-килде дә шоферга багажнигын ачарга кушты Шофер аракы чыгарды, ике чәркәгә яртышардан койды, Фәрваз үзе эчмәде, безне нык итеп, таләпчән тавыш белән кыстады Нишлисең, тотарга туры килде. Ярлар котсыз, чүп-чар баскан, суы кимегән җансыз күл җагасында без озак тормадык, күз бәйләнә башлаган иде Шикле адәмнәр төялгән бер-ике машина да килеп туктады, эчтән кызлар чыркылдаганы ишетелде Шофер алар ягына карамыйча гына әрләп. «Ишәләр... ярларны!» дип куйды.

Фәрваз белән «Аккош күле» урманына сәяхәткә чыгуыбыз миңа кире вә кискен тәэсир ясады. Шуңамы, яңа әсәргә ныклап тотынырдан элек, шушы хатирәләрне язып калдырырга булдым. Гомере озын булсын дустымның.. Тәгәрәп үсеп килгән ике кызы бар! Аларны азмы-күпме аякка бастырасы, кеше итәсе бар лабаса! Асия Минһаҗева Күкләр телендә сөйләшә белсә дә җир, дөнья мәшәкатьләренә ул кадәрле үк яраклашкан җан түгел дип беләм! Фәрвазыннан башка ул ничек яшәр?.. Татар әдәбияты һәм без ничек көн күрербез?

* * *

Дуслык дәрәҗәсен төгәл үлчи торган кораллар дөньяда юк, аның зурлыгын, чынлыгын белсә бер Аллаһы Тәгалә беләдер... Алай да күңелем түренә кадәр үтеп керә алган ике Олы зат бу дөньядан күчкәч, миңа ямансу булып калды. Бөек шагыйрем, акыл иясе Гамил Афзал әйткәнчә, «сирәгәеп калды урманлык». Ни әйтмәк кирәк, Фәрваз Миңнуллин юк, туган-үскән ягының җылы мендәр-туфрагына кайтып ятты. Мөхәммәт Мәһдиев тә якты дөнья белән хушлашып китеп барды. Мин тырмашкан булам әлеге. Дөнья үзгәрә, бик күп мөнәсәбәтләр ваклана, халык әдәбият, сәнгатькә битараф, ваемсыз була барган саен без дә кечерәябез. Чордашларымның бөеклеген алдагы елларга күтәреп барырга хәзерге татарларның зәгыйфь иңе чыдармы? Ниләр генә булса да, авышырга яраткан халкым кая гына сәрлексә дә Фәрваз Миңнуллинга, Мөхәммәт Мәһдиевкә бәяләрем үзгәрмәс. Шушы инану да миңа яшәргә көч бирә. Сирәк агачлы урманда җилләр бөгырьнә кисеп исә торган була, салкын анда, шыксыз...

Ноябрь, 1995 ел.

Лариса МАСЛОВА:

«Музыканы таный белү — зыялылык билгесе»

Татарның танылган виолончелисты Лариса Маслова белән шулай бервакыт очрашкач, «Чит илләрнең кайсы сәхнәләрендә чыгыш ясаганыгыз бар?» — дип сорадым Баксаң, кулыннан 20 елдан артык виолончелен төшермәгән Ларисаның музыкант буларак бер генә ерак чит илдә дә булганы юк икән Югыйсә Мстислав Ростропович, Нәҗип Җиһанов, Натан Рахлин, Родион Щедрин, Бакый Урманче Андрей Эшпай кебек мәһшүр шәхесләрнең мактау сүзләренә, аларның зур өметләр баглаган фикерләренә лаек булган. Мәскәү сәхнәләрен шаулаткан музыкант ич ул! Ничек инде шундый музыкант Русия сәнгать казанында гына кайнарга тиеш?! Миңа каршы әйгүчеләр табылыр, безнең артистлар, кайбер башкаручыларыбыз бигрәк тә фольклор коллективларыбыз чит илләрдә еш булалар дияр Шулаен шулай, ләкин мин дөнья җәмәгатьчелегендә Татарстан турындагы фикер фольклор группаларыбызның чыгышлары буенча гына формалашмасын иде, дигән фикердә торам Дөньяга безнең классик музыка башкаручыларыбызны да күрсәтәсе, академик музыкабызны тыңлатасы иде бит Килешегез, бу инде үзгә сәнгать, үзенә бер дөнья цивилизация дәрәҗәсен күрсәтүче бер гамәл Лариса Маслова да бу фикер белән килеште Шулай да ул күңелен төшерми элеккечә үк эшли бирә, күп чыгыш ясый Мәктәпләрдә еш була Менә әле дә музыкант редакциябезгә 18 нче татар музыка мәктәбеннән кайтышлый виолончелен күтәреп килеп керде Ул анда укыта икән

— Лариса, Сезнең концертлар, Сез уйный торган әсәрләр — җитди музыка, аны тыңлый һәм аңлый белү үзе осталык сорый. Классик музыка хәзерге яшьләр өчен түгел кебек, чөнки бүгенге заман каядыр ашыгучылар, кабаланучылар чоры, гомумән, болганчык вакыт.

— Шулай да яшьләр классикага битараф димәс идем Күптән түгел Г Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе опера-камера бүлегенең Офицерлар йортында чираттагы сезоны ачылды Мин анда чыгыш ясадым һәм әйтергә кирәк, тамашачыларның күбесе өлкән яшьтәгеләр булса да, араларында яшьләр дә бар иде Талантлы яшьләр шактый күп бездә Менә мин дәресләр бирә торган 18 нче татар музыка мәктәбендә дә күренә алар Яшь виолончелистларның уңышлары музыкага җаннары-тәннәре белән тартылулары сөендерә

Атаклы музыкант белән без мәктәптә музыкаль белем бирү классик музыкага мәхәббәт тудыру турында сөйләшеп киттек Ул үзе белән Находкада булган вакыйганы сөйләде Концерттан соң Татарстан вәкилләре шәһәргә килгән япон делегациясе белән очрашалар, музыка турында сөйләшә башлыйлар һәм японнарның бер егете Бетховенның 9 нчы симфониясенең баш партияләрен җырлап бирә Лариса Кояш иле егетенең профессиональ музыкант түгел, ә бәлки гади бер хезмәткәр икәнен белгәч шакката

— Ә бездә — ди ул — классиканы белүче бик аз Хәтта зыялылар арасында да Кайвакыт телевизордан төрле бәйге-конкурсларда зыялы-әдәпле күренгән кешеләрнең иң популяр классик әсәрләрне дә белмәүләрен күргәч оят булып китә Музыканы таный белүе кешенең тәрбияләнгән зыялылыгын күрсәтүче гамәл дип саныйм Безгә дә гомумбелем мәктәпләрендә халык арасында да классик музыкага мөнәсәбәтне үзгәртәсе иде

Бу эштә меценатлар хәзергечә итеп әйтсәк, химаячеләрнең эше турында да сөйләштек без Лариса Идел-Кама акционерлык банкы идарәсе рәисе Рөстәм Сөләймановны «изге ниятле егет» дип телгә алды «Кантилена» кыллы квартеты аңа бик рәхмәтле Әлеге музыкантлар еш кына шифаханәләрдә картлар йортларында, интернатларда чыгыш ясыйлар ә банк аларга акчалата ярдәм итеп тора Менә шундый игелекле эш белән шөгыльләнәләр алар Гомер көзендә ялгыз калган кешеләр канатлары сынган ятимнәр һәм язмышлары каһәрләнгәннәрнең күңелләрен күтәреп йөриләр

— Лариса, әйтегез әле, Сез үзегезне министр кәнәфиендә күз алдына китерә аласызмы?

— Мин бу урында хатын-кыз түгел ир-ат утырырга тиеш дип саныйм Министр булу ул бит хатын-кыз өчен бик авыр Хәтта музыкант хатын-кызларга да эшләве җиңел түгел

Шушында ул әле күптән түгел генә булган күңелсез вакыйганы искә төшерде Иртәгә сезон ачыласы дигән көнне Лариса филармониядә үзенең смычок кылларының өзелгәнен күрә Нишләргә? Бу хәлдән аны музыкаль инструментлар остасы Борис Елезов коткара Карт оста иртәнге бишкә кадәр смычокка ат кылларын тарттыра Ул кылларны лупа аша карап аларның лезвие белән киселгәнен әйтә

— Мин Борис Владимировичка гомумән барча осталарга бик рәхмәтлемен — ди Лариса Маслова Инструменттан башка музыкант була алмый шуңа да безне «ашатучы» уен коралларын карап-төзәтеп торучы осталарны тиешле оешмалар да, мәдәният темасына язучы гәзит-журналлар да онытып бетермәсеннәр иде

— Лариса, алдагы көнгә уй-ниятләрегез нинди?

— Соңгы вакытларда борынгы татар халык көйләре белән кызыксынам Шундый язмаларны тыңлап нотага төшерә барам виолончель өчен яраштырам Мин үз вакытында атаклы рәссамыбыз Бакый ага Урманче белән аралашкан идем Ул остаханәсендә авыз эченнән көйли-көйли эшли иде Бик матур җырлый да иде Аның җәмәгате Флора ханым Әхмәтова-Урманче аларны магнитофонга яздырып алган Шуларны тыңлагач мин «Таһир-Зөһрә» «Ончы Фәхри»нең берничә варианты бар икәнен белдем бик күп бәетләр мөнәҗәтләр өйрәндем

Сүземнең ахырында укытучыларыма рәхмәтемне җиткерәсем килә Махсус урта музыка мәктәбендә минем укытучым Иршат Хәйретдинов иде ә консерваториядә һәм аннан соң аспирантурада аның абыйсы Афзал Хәйретдинов классында белем алдым Минем Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исем алуымда да Русиядә бәйге-конкурсларда җиңеп чыгуымда да аларның өлеше зур Рәхмәт аларга

Әңгәмәне **Наил ФӘЙЗЕТДИНОВ** үткәрде

Радик ФӘИЗОВ

Гөли

Хикәя

Чын исеме Гөләндәм булса да, авылның яше-карты аны Гөли дип кенә йорде. Акылы балачагыннан ук сәер, бик үзенчә булды Синең белән ни булса да сөйләшә башласа, кисәк ярты юлда тукталып кала, күзләрен челт-челт йомгалап көлеп җибәрә, йә, үз уйларына бирелеп, сине оныта да, сүзсез калып тик басып тора иде.

Гөли үләннәрне, чәчәкләрне, җирдә йөгерүче һәм шуышучы барча вак-төяк җан иялэрен бик яратты. Җәй көннәрендә аны, җаена торып кына, юмалап-юкәләп, бакча башындагы болынлыкка каз бәпкәләрен сакларга чыгарып җибәрәләр.

Аның әти-әнисе авылның хәлле генә кешеләре, бик эшчәннәр. Гайфетдин абзый үзе уен-көлкеле генә бер кеше, гомере буена авыл халкына мич чыгарды. Сугышта яраланып, бер кулы чулакланып кайткач та, бу эшен ташламады. Аның мич чыгарганын карап торуы үзе бер кызык. Менә ул, кирпечне сыңар кулы белән тотып ала да, аны җәлт итеп кенә ике тез арасына кыстырып куя, җентекләп карый. Аннары балчык сылап, өеләп килгән мичкә урнаштыра.

Гайфетдин абзыйның сәламәт кулы ифрат та көчле. Ул үзенең киң учын баш түбәңә салып куя икән, күпме көчәнмә, торып китә алмыйсың. Хатыны Гайшә апа — тулы гәүдәле, түгәрәк йөзле, зур күзле хатын — авылның оста уракчысы иде. Кыскасы, алар авылның гади кешеләре, берәз аерымлыклары шул: бүтәннәрдә кимендә биш-алты бала булганда, боларның ике генә бөртек — олы уллары Ильяс һәм дә кечесе әнә шул Гөли.

Ильяс әтисе шикелле уен-көлкеле, сау-сәламәт, эшчән булып үсте. Тракторга, комбайнга укыды, иген икте. Вакыты җиткәч өйләнеп, яхшы йортлар салып башка чыкты, балалар үстерде. Менә Гөләндәмнең генә язмышы һаман да элеккечә калды.

Кыз бала инде үсеп уку яшенә җиткәч, Гайфетдин абзый белән Гайшә апа алдан бик зур өзерлекләр күреп, матур күлмәкләр кидереп, матур сумкалар тоттырып, аны мәктәпкә озатып куйганнар иде. Булмады шул, булмады! Авылның күптәнге, балаларга бик шәфкатьле укытучысы Галия апа хәтта үзе дә Гөлигә белем бирә алмады. Бала дәресне тыңлый алмый, төшенми, һаман да шул үз дөньясына бирелә, йә кычкырып көлеп җибәрә, йә булмаса, урыныннан торып, класстан чыгып ук китә Ә аны тәртипкә чакырып маташуның бернинди файдасы юк Менә шундый баланы укытып кара син! Аңа белем биреп... Шулай да Галия апаның сабырлыгы, зур тырышлыклар куюы белән Гөли берничә ел мәктәпкә йөрде. Аны хәтта аз-маз укый ала, яза да белә икән, дип сөйләделәр. Тик, авылдагы башлангыч мәктәптә укыгач, Гөли инде аннан ары класска, күрше авылга барып йөрмәде. Укуны шуның белән тәмам итте.

Гөләндәм асылда акылга сай, бер тинтәк булдымы икән? Адәмнәр бит шулай: кемнең дә булса акылы гадәтидән аз гына үзгә, сәер була икән, аны җәтрәк тинтәкләр рәтенә чыгарып куялар. Янәсе, ул безнеңчә түгел, кешечә түгел. Әйтик, Гөләндәмгә табигатьнең, Тәңренең үзе тарафыннан бирелгән акыл шундый сәер, үзенчәлекле булса? Үзенә күрә ул чын, камил акыл булса? Бу сорауларга кем генә төгәл җавап бирә алыр. Кеше үзенчә уйлый, бу дөньяны үзенчә таный, бүтәннәргә үзенчә мөнәсәбәт күрсәтә икән, бу бит әле аны тинтәккә исәпләргә нигез була алмый.

Җитмәсә, Гөлинең хәтере бик әйбәт, кайчак аннан олкәннәргә хас тапкыр сүзләр дә чыгып куя иде. Бервакыт шулай кышның җылы бер көне иде, яфрак кадерле җепшек кар төшә. Югары очтан авылның ихтирамлы карчыгы Камилә әби кайтып килә. Күркәм әби, башында кара камчат бүреге, кулында матур таяк Шунда җыелып торган ирләрдән берәү ил карчыгына сорау бирде:

— Камилә әби, киләсе елда игеннәр ничек булыр? Киләсе җәйнең кайсы вакытына туры килә бу җепшек кар?

— Менә оланнар, Аллаһы боерса, киләсе җәйләр явым-төшемгә бай булыр. Игеннәр күкрәп торыр Бу карлар бодай башак чыгарган вакытларга туры килә инде. Шул чакта шифалы яңгырлар явып үтәр. Аллаһы боерса, шулай булыр, — дип гөман кылды әби.

Тик киләсе җәй... кайда ул шифалы яңгырлар! Яман да эссе, коры килде ул җәй. Ә инде кып-кыска булып үскән бодай башак чыгарганда күк йөзе чалт аяз, башың пешәрлек кызу иде Әлбәттә инде, бу хәлдән пошаманга төшкән авыл халкы Камилә әби белән булган теге сөйләшүне әллә кайчан онытып бетергән иде. Тик менә авылдан бер кеше — Гөли бу юрауны хәтерендә саклаган икән. Беркөн Камилә әби үзен гадәтенчә бик күркәм тотып, таягына таянып, югары очтан кайтып килә икән, каршысына әллә кайдан ук кычкыра-кычкыра Гөли йөгереп килгән.

— Камилә әби! Камилә әби, син ялганчы икәнсең бит!

Мондый сүздән бичара карчык туктаган җирендә артына авып китә язган.

— Ниләр сөйлисең син, гөнаһым шомлыгы? Ниткән ялганчы ди ул тагын? — дигән ул.

— Ник, әби? Син, бу җәйдә яңгырлар күп явасы, дигән иең ич. Бер дә яумады ич, әби! — дигән Гөли.

— Кит! Тинтәк бала... Акылың оешып җитмәгән нәмәрсә... Күземнән югал! — дип сөйләнгән әби һәм гомердә булмаган тизлек белән, җәтрәк өенә җилдерткән.

Гыймади абзыйларның мәчесе балалаган. Өйдә болай да кытлык. Агай мәче балаларын капчыкка салган да инеш буена алып киткән. Суга салырга Каршысына Гөли очраган.

— Гыймади абый, нәрсә бар синең ул капчыгыңда? — дигән ул, кызыксынып.

— Мәче балалары анда, кызым.

— Ай, карыйм әле... Матурлар микән?

Агай капчыкны чишеп җибәрүгә, Гөли берсеннән-берсе матур мәче балаларын алып күкрәгенә кыскан.

— Ә кая алып барасың син аларны?

— Суга салам менә. Ярлылык хәттин ашты бит, Гөли Сот тә юк бит безнең йортта...

— И, Гыймади абый, суга салма син аларны. Гөнаһлары үз өстеңә кайтып төшсә, ни хәл итәрсең. Өегезгә апкайтып куй син аларны. Күршеләрегез дә кереп алыр әле. Зинһар, аларны суга салма! — дигән Гөли.

Кыз баланың бу сүзләреннән, үзенә текәлгән ялварулы карашыннан агай тетрәнеп киткән. Хатыны белән әрепләшеп булса да теге нәниләрне исән калдырган. Соңыннан, чыннан да, ул песи балаларын күршеләре кереп алып бетерделәр. Гыймади абзый бу хәлне кешеләргә сөйләп, куанып йөрде.

— Зур бер гөнаһтан саклап калды мине Гөли. Әле дә булса рәхмәтле мин шул балага, — диде ул.

Мәктәптә укыган иптәшләреннән аерылып, һаман да шул болынлыкларда, бакча башларында йөрсә дә, ялгызы булса да, Гөли яшьтәшләреннән калышмый үсте. Тик менә акылы гына әллә ни алга китә алмады. Һаман да шул бөҗәкләр, бакалар белән матавыклана, алар белән сөйләшә иде. Дөрес, инде ул йорт эшләренә дә булыша. Түтәлләргә су сибә, мунчага су китерә, бәрәңге төбен өя, чүп утый. Тик аның башлаган эшен ярты юлда калдыруы, коедан су алып кайтканда чиләкләрен урам уртасына утыртып, үзенең болынлыкка төшеп китүе дә бар. Монда инде берни дә кыла алмыйсың, ул — шундый. Аңа әйтүнең, кисәтүнең, хәтта куркытып маташуның бернинди файдасы юк. Ул үз юлы белән китә, җаны теләгәнне эшли.

Гайфетдин абзый белән Гайшә апа кызларына беркайчан да авыр сүз әйтмәделәр, какмадылар-сукмадылар, аны берни белән дә битәрләмәделәр Гайшә апа кайчак кешеләр барында:

— Өлешемә тигән көмешем! — дип кызының башын күкрәгенә кыса, аркасыннан сөя.

— Ай, Аллам, гөнаһысыз бала шул... — дип, елап та алгалый иде. Абыйсы Ильяс та сеңлесен чын туган итте, барган җиреннән аңа бүләксез кайтмады. Гөлине көчтән килгәнчә, үз яшьтәшләреннән бер дә ким итмичә киендерделәр. Үлән арасында, бакча башларында йөрсә дә, ул үзе дә яхшы ук җыйнак, пөхтә кыз, өстен-башын чиста йөртә белә иде.

Унбиш-уналты яшьләрендә инде ул зифа гына буйлы, калку күкрәкле, озынча аксыл йөзле, кара кашлары сызылып киткән бер кыз булып үсеп җитте.

Мәхәббәт! Кешелек дөньясы инде күпмә яшәп тә, серенә әле беркем төшенә алмаган мәхәббәт хисе! Вакыты җиткәч, барыбызга да килеп кагыла, һәммәбезне тигезли ул. Адәм балалары белән могҗизалар ясый. Дәрәҗәңне дә, акылыңны да тикшереп, төпченеп тормый.

Безнең Гөли дә гашыйк булды!

Ни сәбәптер, безнең авыл халкы әүвәлдән үз малларын үзе көтми. Көтүчене чит авыллардан чакырып китерәләр. Күп еллар буена мари кешесе Никодим көтүче булды бездә. Авыл кешеләре әйткәнчә — Нигудин. Инде Нигудин картайгач, бу язлыкта шактый ерактагы авылдан бер егет килде. Татар егете. Гәүдәгә таза гына, әллә ни кызлар күзе дә төшәрлек түгел кебек үзенә, кызгылт чәчле, битен чәберчек күкәенә төшкән таплар төсле эре сипкелләр каплаган. Башка көтүче халкыннан аермасы шул: Рәсим исемле бу егет аракы эчми, тәмәке тартмый торган булып чыкты.

Көтүченең аерым фатиры юк, куелган гадәт шулай: ул өй борынча йөри, бүген иртән бер кешегә керә, шунда туена, шунда төн куна, иртәгә — икенче кешегә. Көтүчегә пачут та, сый да бик дәү. Һәр хуҗабикә аңа үзенең пешерү осталыгын күрсәтә, тәм-томын кызганмый. Йорттан-йортка кунак кына булып йөри бездә көтүче!

Көннәрдән бер көнне Рәсим Гайфетдин абзыйларга керде. Керде һәм... шуның икенче көнендә үк бөтен авыл халкына таралган хәл булды. Кичен түбән очтан көтү кайта гына башлаган иде, ни күрәбез, Гөли урам уртасына чыгып баскан. Койма буена яисә капка төбенә дә түгел, нәкъ менә урамның уртасына! Өстендә — бик матур, зәңгәргә ак чәчәкләр төшкән күлмәге, үзе тәмам үзгәреп, чибәрләнеп киткән, бит урталарына алсулык бөреп чыккан. Ә күзләре... Гөлинең гадәттә уйчан, битараф карашлы күзләре хәзер нинди дер бер эчке нур, хис, куаныч белән балкып торалар иде. Терләкләрен каршыларга капка төпләренә чыккан кешеләр аптырады бу хәлгә.

— Ходаем, бу балага ни булган?

— Кая дип җыенган ул бу тиклем?

Борчулы авазлар да ишетелде.

— Гөли, чык урам уртасыннан! Сыерларны куркытасың ич.

— Мир үгезе сөзеп китмәсен!

— Сөзсә сөзәр... Ә мин Рәсимне каршы алырга чыктым! — диде Гөли, куанычлы елмаеп.

Һәм көтү үтеп беткәнче урам уртасында шулай басып торды ул. Аннан, һаман шулай елмайган килеш, көтү артыннан кайткан Рәсимнең каршысына килде. Тегесе бу хәлдән аптырап, тукталып калды, кешеләрдән уңайсызланды, ахры, кып-кызыл булды. Гөли исә аңа якын ук килде, өстендәге кожаның җиңенә сыенды, хәтта башын егетнең иңбашына салып алды. Балкып торган күзләре белән аның күзләренә карады.

— Әйдә, безгә кайтабыз! — диде ул егеткә, иркә тавыш белән.

— Юк... Гөли... Мин ни... сезгә кайта алмыйм шул. Сезнең чират үтте бит инде, — дип сөйләнде тәмам югалып калган егет.

— Алайса, син безгә иртәгә килерсең, яме! — диде Гөли.

— Ярый, ярый, Гөли... Мин сезгә иртәгә килермен, — диде егет.

Һәм Гөлигә шул җитә калды. Ул, кулындагы талчыбыгын селтәп, бәхетле елмаеп китеп барды. Бу хәлне күреп торган кешеләр башларын чайкап калды. Кайбер апалар яулык чите белән күзләрен сөртеп алды. Орынып торган күршеләре Бәдәр апа әйтеп куйды:

— Нарасыйдан чыкмаган шул, ни хәл итәсең...

Тик акылы нарасый булса да, Гөлинең табигате балалыктан чыккан иде шул инде. Ул моннан ары һәр кичтә Рәсимне шулай каршы ала торган булды. Алай гына да түгел әле, кайбер көннәрдә көндезләрен дә, үзенең зәңгәр күлмәген киеп, Рәсим янына, ерактагы киң болынга төшеп киткәләде. Кая барасың сорасалар, җавабы туп-туры иде:

— Рәсим катына төшәм!

Акны карадан аермаган гөнаһсыз кыз бала бит, ул-бу килеп чыкмасын, оятлы хәл булмасын дип, авыл егетләре Рәсимне бик каты кисәтеп куйдылар. Моңа каршы ул үзе дә әйткән:

— Нәрсә, мин аңламыйммыни, егетләр?!.

Аллам сакласын! — дигән.

Гайфетдин абзый белән Гайшә апа менә шушындый хәлдә дә сабырлык күрсәттеләр, кызларының мондый кыланышларына да түзделәр, аны тиргәү, акыл бирергә тырышу, куркытып караулар булмады Гөлинең ирегән чикләргә маташу аны җәфалау гына буласын бик яхшы беләләр иде шул алар.

— Тәкъдирнең язганы булыр, — дигән Гайфетдин абзый.

Ә тәкъдирнең язганы шул булды: Гөлидә дөрләп кабынган ярату хисләре сүнмәде дә, сүрелмәде дә Теләсә кайсы эшне ярты юлда калдыра, теләсә кайсы шөгылен онытa торган бу кыз бала Рәсимне бер генә минутка да исеннән чыгармады. Хәзер инде ул урамда очраган бер кешегә сөйли иде:

— Кичәгенәк без Рәсим белән болында йөрдек...

— Без Ашыт суында галәмәт тә зур чуртан күрдек.

— Рәсим миңа, болынга тагын төш, диде.

Кыз бала тәмам үзгәреп китте. Хәзер инде аның йөзендә алсулык, иреннәрендә бәхетле елмаю сүнми, чәчләрен гел тарап, гел матур киенеп йөри башлады. Хәтта акылында да, нәни генә булса да, ниндидер үзгәреш булды бугай Ул хәзер инде бакча башларында үлән арасыннан бөҗәкләр эзләп ялгызы гына йөрми, урамда кешеләр янында еш була, кибеткә менгәли. өйдә кул эше белән утыра иде. Гайшә апа күршесе Бәдәр апага, сер генә итеп, Гөлинең бик күп... нәни бала күлмәкләре тегеп куюын әйткән.

Ай, Аллаһымның эшләре!

Хәзер инде Гөлинең телендә кая барса да, «Рәсим белән без» иде. Аллаһының рәхмәте, нарасый күңелле бу кыз баланың эчкерсез мәхәббәтенә кәтүче егетнең йөрәге дә җавапсыз ук калмады, күрәсең. Рәсим үзе дә Гөлинең шулай көтүдән каршы алуларына, болынга төшеп йөрүләренә күнегеп китте. Болардан ризасызлык та, кимсенү дә белдермәде. Әлбәттә, бу уңайдан аңа төрттерүчеләр табылган:

— Исемеңә тап төшереп, шул тинтәк белән маталанмасаң... авылда кызлар беткәнме сиңа?

— Ник, Гөләндәмгә нәрсә булган ул кадәр?.. Аның белән сөйләшеп йөрүләре рәхәт. Ялганны, хәйлә дигәнне белми ул. Бүтәннәр кебек... — дигән андыйларга егет.

Рәсим кайчак хәтта, авылның кызлар янына йөргән башка егетләре кебек үк, кичләрен Гайфетдин абзыйларның капка төбенә килеп, Гөлине дәштереп, сөйләшеп тә торгалады. Үзенең кисәк көлеп җибәрүләре белән Гөли бүтәннәргә шактый комачау салса да, алар клубка, кинога да менгәләделәр. Егетнең дә чыны булып чыкты Рәсим, Гөлине ким-хур итмәде, аның турында беркем алдында да андый-мондый сүзләр әйтмәде. Юкса бит, «Бәйләнде бу тинтәк миңа!» дип, үзенә сырпаланган кызны яныннан куып җибәрсә дә, аны битәрләүче табылмас иде. Ә Гөли исә аңа дөрестән дә сырпалана, бергә килсәләр, гел аның иңбашларына салынып, күзләренә карап кына тора иде.

Авылда бу хәлне төрлечә юрадылар:

— Ниләр белән генә бетәр инде бу?..

— Әллә, мәйтәм, Гөлинең акылы утырып китәр иде микән. Әгәр кияүгә чыкса, дим...

— И, җаным, ул тинтәкне кем алсын инде?! Рәсимнең башына тай типмәгән ләбаса!

Их, менә шулай шул ул! Тормышның аның үз законнары, үз кануннары. Ә ул законнар рәхимсез, бәгырьсез, алар адәм баласының күңелен таптап үтүне, бәхет-өметен сүндерүне берникә дә санамыйлар.

Матур җәйләр үтеп тә китте, көзләр җитте.

Гөли — күкнең җиденче катында, күзләрендә куаныч нурлары балкый, Рәсиме янына болынга көн дә төшә. Шунда авылга Рәсимнең әти-әнисе килеп төште. Әле чагыштырмача яшь кенә, ару гына кешеләр икән. Күрәсең, аларга кемдер, нәрсәләрдер хәбәр иткән, алар барысын да алдан белеп килгәннәр. Башта авыл советында булып, Гөли хакында бәйнә-бәйнә сорашканнар, аннары Гайфетдин абыйларга төшкәннәр. Рәтле кешеләр икән, алай каты бәрелмәгәннәр үзләре.

— Сез безне аңларсыз дип уйлыйбыз, без улыбызны бүгеннән үк моннан алып китәбез. Ул — техникум укучысы, җөен акча эшлим дип кенә көтү көтеп йөри Улыбыз белән сөйләштек, шуны аңладык. монда эшләрнең буталып та китүе бар икән Акыл керең җитмәгән яшьлек бит... Без улыбызның киләчәк көненә күз йома алмыйбыз Сез дә безне төшенә торгансыздыр, — дигәннәр.

Гайфетдин абзый белән Гайшә апа моңа каршы ни әйтсеннәр инде? Монда ни әйтеп була? Башларын түбән игәннәр дә ым каккаңнар. Тик, инде кунакларны ишектән озатканда гына, Гайшә апа сорап куйган:

— Рәсим үзе ни әйтә соң?

— Аның белән үзебез хәл итәрбез. Ата-ана сүзенә колак салмас бала түгел ул, — дигәннәр тегеләр.

Чыннан да, икенче көнне үк Рәсим безнең авылдан гаип булды. Әле көтү кирәргә иртәрәк иде. Калган көннәрдә авыл кешеләренә малларын чиратлап көтәргә туры килде.

Әти-әнисе дә, авыл халкы да Гөли өчен бик курыкканнар иде Рәсимне эзләр, аны таптыра башлар, ахырда, тәмам акылыннан шашып ниләр эшләп бетәр дип. Ходайның рәхмәте, алай ук булмады тагы Гөли, кичен көтү кайтканда, гадәтенчә бизәнеп-ясанып, Рәсимне каршы алырга чыкты Көтү артыннан аргы якның олпат гәүдәле егете Фәрит кайтып килә иде. Бу хәлдән бик аптырады Гөли, як-ягына каранды, терлекләрен көтеп капка төпләрендә басып торган кешеләргә карады. Аннары күзләрен тутырып Фәриткә текәлде.

— Рәсим кайда?

Кәне буе сыер-сарыклар артыннан йөреп арган бу ялкау гына егет ачулы иде.

— Мин каян белим? — диде ул тупас итеп һәм, Гөлинең үзенә текәлгән карашына түзә алмыйча, капка төбендәгеләргә ишарәләде. — Әнә алардан сора. Мин белмим!

Шунда бу хәлне күреп торучылар тетрәнеп киттеләр. Әйтерсең, әле генә балкып, яшьнәп утырган гөлчәчәк кинәт сулып, шиңеп калды. Гөлинең иңбашлары салынып төште, әле генә куаныч белән балкып торган күзләре сүнеп, аларга хәсрәт кереп урнашты Йөзенә бик тә, бик тә үпкәләү, кимсенү бәреп чыкты.

— Һәй, мәхәббәтсез! — диде ул һәм, кулындагы чыбыгын читкә ташлап китеп барды.

Шуннан соң инде бу кыз бала көлү-куанычларны, матур киенеп йөрүләрне белмәде. Акылы да үзгәреп ничектер утырып киткәндәй булды Ул инде көнозын өйдә йорт эшләре карый. үзалдына гел нидер сөйләнә. үз дөньясы белән яши иде Кайчак урамга да чыгып йөри очраган һәр кешегә хәсрәтле күзләрен текәп бер сорауны бирә:

— Рәсим кайда икән?

Бервакыт кайсыдыр имансызы әйтеп куйган:

— Гөли, ул Рәсимең үлде синең. Аны зиратка илтеп күмеп куйдылар

Гөли шунда ук авыл башындагы каберстанга менеп киткән Зират эчендә йөренә һәр кабер янында туктала, озаклап карап тора, нидер көткәндәй сагаеп тора икән Бу хәл берничә тапкыр кабатлангач, авыл картлары җыелып килделәр Гөлине төрлечә юмалап, кулыннан җитәкләп зираттан алып чыктылар. Икенче монда кереп йөрергә ярамаганын әйтеп кисәтеп куйдылар Шуннан соң инде Гөли зиратка кермәде аның коймасы буйлап кына йөри башлады Килә-килә дә кисәк туктала, каберләргә текәлә Озаклап карап үз дөньясына чумып тора Сәер итеп елмая Шулай йөри-йөри ул куе булып үлән үскән зират коймасы буена сукмак салды.

Зират эченә кереп йөрмәсә дә, Гөли моннан ары күмелгән һәр кешенең каберен, җирләнгән көнен хәтерендә саклады Авыл кешеләре. читтән кайтучылар аннан кайчак әти-әниләре, туганнарының каберен сорыйлар Гөли уйлап та тормый әйтеп бирә.

.. Бу хәлләрдән соң инде күп еллар үтте. Гайфетдин абзый белән Гайшә апа күптән мәрхүм инде Гөли исән әле Ул абыйсы Ильяс йортында яши Ильяс үзе дә олыгайды, Гөли дә карчык инде Ап-ак йөзле, ап-ак чәчле. матур гына бер авыл карчыгы Ул хәйран гына йөри. хәйран гына сөйләшә. Тик менә зират коймасы буенда йөрүеннән әле дә булса туктамаган Әле дә булса аның үз сукмагы бар.

И, Тәңрем! Адәм балаларыңны сау-сәламәт, гадәти акыллы итеп ярат. Акылы китек, сәер балаларың була икән, аларны газап-борчуларга салма...

Әйт әле, «Күбәләк»

Адәм баласын хәзер берни белән дә шаккатырып булмый. Бигрәк тә шәһәр җирендә. Берсеннән-берсе шәбрәк җырчылар, берсеннән-берсе даһирак шагыйрьләр, үзләре шигырь язып, шуңа көй чыгарып, шуны сәхнәдә үзе уйнап, үзе җырлаучы шагыйрь-җырчы-музыкант-композиторлар яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр төсле туып кына тора Радио-телевидение дигәнең көн-төн шау-гөр килеп эшли тора, берсеннән-берсе кызыклырак өр-яңа гәҗит-журналлар бер-бер артлы дөньяга килә тора.. Тик менә аларда җанны җылытырлык, күңелне яктыртырлык мәгълүматлар табуы бик кыен. Нихәл итмәк кирәк, безнең өлешкә менә шундый болгавыр (шулай да кызыклы) заман туры килде. Әмма без әле һаман өметне сүндермибез, гел-гел болай булмас, дөньялар үзгәрер, дип үз-үзебезне юатып яши бирәбез. Аннары дөнья гел караңгылыктан гына тормый икән ләбаса! Әле мин язарга теләгән очрашу шул караңгылык патшалыгындагы якты нур сыман күңелемне җылытып, яктыртып җибәрде. Ул очрашу әле шактый вакытлар узгач та яшәргә көч биреп торыр Очрашу Казан шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр системасының татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә республикабызның төрле төбәкләреннән килгән укытучылар һәм мәктәп укучылары белән булды. Бу очрашуга шагыйрә һәм прозаик, танылган балалар язучысы Резеда апа Вәлиева белән миңа бару насыйп әйләде Очрашу очрашу инде, таныштык, сөйләштек, шигырьләр укыдык, балалар сөйләгәнне тыңладык. Мин язарга теләгән нәрсә очрашу хакында түгел (алар, Аллага шөкер, йә тегендә, йә монда әледән-әле булып тора), ә шушы очрашуга килгән «күбәләкләр» турында 6 нчы музыка мәктәбендә оештырылган, төрле фестивальләрдә өч мәртәбә лауреат исеме алган «Күбәләк» балалар ансамбленең нәни артистлары — җырчылар, музыкантлар турында. Шул араларда да, «күптән үткән заманнарда» да нинди дә булса тамашаны шулай тәэсирләнеп, дулкынланып караганымны хәтерләмим мин Баян да бар иде монда, аккордеон да, тальян гармун да, барабан да, курайлар да, кубыз да. мин исемнәрен белмәгән бүтән кораллар да.. 10-13 яшьләр тирәсендәге балаларның һәркайсы милли киемнәрдән Мине бигрәк тә ансамбльнең солисты, җырчы Ирек Сәгиевнең тавышы, осталыгы сокландырды (ул 96 нчы мәктәпнең 7 нче сыйныфында укый икән). Балаларның уйнау-җырлаулары чын профессионалларча Үзләрен тотышлары да сокланырлык. Сәхнәдә туып, шунда үскәннәр диярсең. «Күбәләк»ләр татар халык көйләрен, популяр җырларны башкардылар. Рәхмәт яугырлары, күңелләрне язгы ләйсән кебек сафландырып, җылытып җибәрделәр, әле яшибез икән, бәлки, шулай тернәкләнеп тә китәрбез, дигән өмет уяттылар Ансамбльнең җитәкчесе Валерий Бирюков — үзе бер могҗиза. Бер генә кеше дә аның татар түгеллеген башына да китереп карамагандыр Чонки урыс егетенең (әйе, әйе, керәшен түгел, саф урыс егете) татар сәнгатенә, татар музыкасына шулай җаны-тәне белән бирелеп, аны үзенеке белән бертигез яратып, милләтебезгә чын күңелдән хезмәт итеп яшәвен, алай гына да түгел, шул милләт балаларында үз сәнгатьләрен, музыкасына мәхәббәт тәрбияләргә алынуын ничектер башка сыйдырып булмый (без мондый хәлне күреп гадәтләнгәнмени инде?) Валерий Михайлозичның 10 яшьләрендәге бик тә сөйкемле үз кызы да курайда, кубызда уйный Төрледән-төрле курайларның берсен ала, берсен куя...

Мин Валерий Михайлозичның җәмәгатен дә күрдем Хатыны — үзебезнең милләт кешесе икән Ул Валерий Михайловичның үзенең дә татарча сөйләшергә өйрәнергә теләге барлыгын әйтте Монысы нур өстенә нур булыр иде.

Сүземнең ахырында шунысын да әйтәсем килә: китапханә заллары искиткеч матур, якты. чиста, зәвыклы итеп бизәлгән Мондый җиргә йөрмәс җиреңнән йөрерсең. Тик менә кайбер китап киштәләренең буш торуы гына кәефкә күләгә төшерде. Китапханәдә китап киштәләре буш торса, шактый күңелсез авыр була икән. Сәбәбе — акча юк. Хәер хәзер бу иң еш ишетелә торган сүздер инде. Мин кулымнан килгәнчә, китаплар табарга, ул киштәләрне тутырырга булышырмын дип күңелемә беркетеп куйдым.

Бу китапханә Вишневский урамындагы 10 нчы йортта урнашкан. Күңелләренә якты, җылы эзләгән кешеләр анда үзләренә җан азыгы тапмый калмас дип ышанам.

Фирая ЗЫЯТДИНОВА.

Авылны һаман изәләр

Русиядә быел крәстияннең айлык эш хакы уртача 195800 сум тәшкил итә. Бу — промышленность эшчеләренекеннән 2,6 тапкырга кимрәк. Аларга бирелә торган төрле өстәмәләр дә 21 мең сумнан артмый Болар бөтенесе бергә дә яшәү минимумын тәэмин итә алмый. Өстәвенә эш хакы вакытында бирелми. Октябрь аена бирелмәгән эш хакының күләме 2,2 триллион сум. Бу саннар өлешчә Татарстанга да кагыла.

(«Известия»).

«Биш»легә үтерүче

Тольятти шәһәрендә була бу хәл. Җиденче сыйныф укучысы Артем Кузьменко үзенең класс җитәкчесен һәм аның алты яшьлек кызын башларына чүкеч белән сугып үтерә.

— Нигә болай эшләдең? — диген сорауга малай: «Ул миңа чиреккә «биш»ле урынына «дүрт»ле куярга теләгән иде. Ә мин бит отличник», — дип җавап бирә.

«Тегe җир» кыйссасы

Күптән түгел Макеевка хастаханәсеннән Мәскәүгә җан җирен эт тешләп өзгән ир кешене китерәләр. Табиблар, әлбәттә, аңа ярдәм итәләр, җенси әгъзасын мөмкин кадәр яхшы итеп тегеп куялар. Аннары үзеннән ничек болай булганлыгын сорашалар.

Әлеге ир-ат эштән кайтып машинасын гаражга куя да самогон эчә Гараж кооперативы территориясеннән чыкканда каравылчыга бәйләнә. Каравылчының эте исә хуҗасын яклап әлеге кешегә һөҗүм иткән икән

(«Комсомольская правда»).

Ике аккош

Дөресрәге — ике Лебедь. чөнки фамилияләр тәрҗемә ителми. Үзәк сайлау комиссиясе депутатлыкка кандидатлар исемлеген тикшергәндә кызыклы хәлгә очрый Александр Иванович Лебедь диген кандидат ике исемлектә — «Урыс общиналары конгрессы» диген иҗтимагый-сәяси хәрәкәтнең гомумфедераль исемлегендә, икенчесе Ә Е.Давиташвилинең сайлау алды блогы региональ төркеме исемлегендә беренче урында тора.

Гаҗәпләнеп, тикшерә башлагач, ике Лебедьнең бер үк кеше түгел, ә адашлар гына булуы ачыклана Берсе — күпләргә яхшы таныш генерал булса, икенчесе — гади кеше Тик сайлаучыларның аны да генерал дип аңлаулары ихтимал бит

(«Российская газета»).

Аман Тулеев кардәшебезме

Узган сайлауларда үзен Русия Президентлыгына кандидат итеп күрсәткән иде ул Әнисе татар икән дип язучылар да булды ул чакта. Бу юлы Аман конгрессмен булырга омтыла. Ноябрь азагы, декабрь башларында ул Татарстанга килергә, Казан, Зеленодол, Әлмәт шәһәрләрендә булырга җыена икән. А.Тулеев Русия коммунистлар партиясеннән күрсәтелгән кандидатлар исемлегендә беренчелер рәтендә тора.

(«Вечерняя Казань»).

Һәркем Президент була ала

Үзенең конституцион вәкаләтен үтәп, Федерация Советы Русия Федерациясе Президентын сайлаулар көне итеп 1996 елның 16 июнен билгеләде. Ул «Русия Федерациясе Президентын сайлаулар турында»гы Законга нигезләнә. Законда әйтелгәнчә, «сайланган Президентның конституцион срогы узуга беренче якшәмбе сайлаулар көне була». Президентка яше 35тән ким булмаган, бу илдә 10 елдан да ким яшәмәгән һәркем үзен кандидат итеп күрсәтә ала.

(«Российская газета»).

Төркия дә безнең шартларга җайлаша бара

Төркиядә эшләнгән «Рено-19» маркалы милиция автомобиле тиздән Түбән Кама шәһәре урамнарында пәйда булачак. Заман техникасы белән җиһазландырылган әлеге автомобиль Татарстан юлларына һәм безнең климат шартларына җайлаштырылган. Түбән Кама милициясен Төркиядә эшләнгән автомобильлә итүдә Түбән Каманың «Нефтехим» акционерлык җәмгыятенең Төркиядәге вәкиллеге һәм «Татурос» уртак ширкәте булышты.

Истанбулда шулай ук Казанның «ПОГАТ-3» акционерлык җәмгыятенә 30 микроавтобус сату турындагы килешүгә кул куелды. Мондый автобуслар Казанда ике ел хезмәт күрсәтә инде. Хәзер Төркия микроавтобусларының саны 100гә җитәчәк.

(«Заман-Татарстан»).

Мәнә сиңа мә

Чаллыдагы 32 нче мәктәп-гимназия «Вот так» диген кызыклы гына 4 битле гәзит чыгарып килә. Анда «Ялт-йолт» диген татарча сәхифәләр дә дөнья күрә. Урысча басмада укучылар юморына зур урын бирелә. Язмаларның авторлары — укучылар үзләре. Яшьләр шулай үзләренең каләмнәрен чарлый, журналистлык һөнәрен үзләштерә.

Журналист буласыгыз килсә...

Татарстан хөкүмәтенең республика укытучыларына 40 миллиард сум бурычы бар, дип яза «Мәгърифәт» гәзите. Аннары ул гәзит каршында яшь журналистлар мәктәбе эшләвен хәбәр итә.

«Менә берничә ел рәттән, — дип яза ул, — гәзитебез киләчәккә журналист һөнәрен сайларга теләгән чыгарылыш класс укучылары арасында конкурс үткәреп килә. «Булачак журналистлар клубы» дип аталган бу бәйгенең максаты — иң сәләтле, иң актив хәбәрчеләр Казан дәүләт университетының журналистика, социология һәм психология факультеты студенты булсын өчен булышлык итү. Җиңүчеләрне — гәзит битләрендә кимендә 3-4 язмасы дөнья күргән һәм абруйлы жюри тарафыннан уңай бәяләнгән яшь авторларны — югарыда телгә алынган факультетка имтихансыз кабул итәргә тәкъдим кертәчәкбез».

Мәрҗани җәмгыяте тәкъдим итә

Шиһабетдин Мәрҗани җәмгыяте түбәндәге тәкъдим белән Казан шәһәр Советына мөрәҗәгать иткән:

— Заманында Шиһабетдин Мәрҗани яшәгән, аның йорты урнашкан Каюм Насыйри урамын Мәрҗани урамы дип үзгәртергә;

— Каюм Насыйри яшәгән, аның йорты урнашкан Париж коммунасы урамын Каюм Насыйри исеме белән атарга.

Тик бу тәкъдимгә җавап алынмаган. Җәмгыять 1552 елда Казанны яклап һәлак булган Кол Шәриф исемен дә мәңгеләштерү мәсьәләсен күтәрә.

Читләрнекен макта, үзеңнекен кара

Соңгы вакытта кинофильм карарга йөрүчеләр бөтенләй бетә язды. Фильмнарны залда нибары берничә кеше карый. Күрсәтелә торган фильмнар — барысы да диярлек Американыкы.

Шуны исәпкә алып булса кирәк, Русия Федерациясе хөкүмәте «Үз илебез фильмнарын саклау һәм аларны күрсәтүне арттыру чаралары турында» карар кабул итте. Аны гамәлгә ашыру өчен бюджеттан шактый күләмдә акча бүлеп бирү күздә тотыла. Бәлки, моның җиле Татарстанга да кагылыр.

(«Российская газета»).

Корольләр дә «ужымга керә»

Англиядә принцесса Диана үз гаиләсенең «ужымга керү»е турында телевидениегә интервью биргән. Ул ирә принц Чарльзның соңгы айларда сөяркәсе Камилла Паркер-Баулз белән ачыктан-ачык йөрүләрен әйткән. Ул үзе дә армия офицеры Хьюнт белән гыйшык-мыйшык уйнаган икән. Тик Хьюнт, принцесса белән булган интим мөнәсәбәтләрә турында китап язып, аны хур иткән.

Алга таба бергә яшәп калырлармы алар? Ике бала анасы Диана үкенә, аерылышырга теләми. Шулай да ахырын киләчәк күрсәтер. Бу мәсьәләдә соңгы сүзне Чарльз әйтергә тиеш икән.

(«Известия»).

Бөтенрусиянең алданучылары, берләшегез!

1992 елда бик күп ватандашларыбызның саклык банкына салган акчалары «янган» иде, дөресрәге, инфляция нәтиҗәсендә меңләгән сум акча тиеннәргә әйләнгән иде. Бихисап карт-карчыклар үлемтеккә дип җыйган акчаларыннан да мәхрүм калды. Бу хәлгә зар елаучылар хөкүмәткә дә, Президентка да ризасызлыкларын белдереп хатлар яздырдылар.

Әлеге мәсьәләне ничек хәл итү турында Русия Федерациясе Дәүләт Думасы озак баш ватканнан соң, ниһаять, алданган кешеләргә компенсация ясарга диген карарга килде. Шуның нигезендә Русия Президенты вкладчылар һәм акционерларның хокукларын яклау буенча кайбер чаралар турында фәрман чыгарды. Анда компенсация эшен гамәлгә ашыру өчен федераль иҗтимагый-дәүләт фонды төзергә әмер бирелә.

(«Российская газета»).

Аллам, үзең ярлыка...

«Шаттл» астронавтлары ватылган «Хаббл» космик телескобын ремонтлауга ук Галәм читендәге йолдызлар тупланмасын күзәтә башлыйлар һәм телескоп... «Алла йорты»н сурәткә төшереп ала.

Телескоп узган елның 26 декабрендә Мэриленд штатында урнашкан космик үзәккә йозләгән шундый фотолар тапшыра. Фотода нурлар чәчеп утыручы. Галәм киңлегендә бик гадәти рәвештә йөзеп йөрүче ак шәһәр сурәтләнгән НАСА чыганакларыннан күренгәнчә, бу шәһәр «Алла йорты» булырга тиеш. чөнки мәңге караңгы Галәм киңлекләрендәге һавасыз бушлыкта тормыш булуы мөмкин түгел Фотоның авторы, тикшеренүче Марсия Мэссон «Хаббл» телескобының иң кирәкле вакытта нәкъ шул юнәлешкә борылуын «кемнеңдер» хикмәтле эше булуына шикләнми Ә бит Галәм иксез-чиксез ди ул

НАСА вәкиле исә Марсия әйткән сүзләр хакында җәелеп сөйләргә теләми Шулай да киң мәгълүматлы башка вәкилләр әлеге сенсацион вакыйга турында «кешелекнең киләчәген үзгәртердәй нәрсәдер табылды» димичә булдыра алмыйлар



Алар шулай ук Президент Билл Клинтон һәм вице-президент Эл Горның әлеге фотолар белән гаять кызыксынуларын һәм көн саен исәп-хисап таләп итүләрен әйтәләр.

Бу фотолар НАСА аналитикларын да хәйран калдыра, алар кат-кат тикшергәннән соң да үз күзләренә ышанмыйлар Галимнәр шулай ук «Алла шәһәре»нең гадәти булмавына, ягъни анда без күзаллаган гадәти тормыш булмавына да басым ясап әйтәләр.

Безнең материалистик аңыбыз андый абстракт төшенчәләрне сыйдыра алмый шул. Галимнәр бу очракта бердәнбер логик фикер — биредә үлгән кешеләрнең якты җаннары яши, диген фикер әйтәләр. Бу, могаен, дөреслеккә күбрәк туры киләдер. Изге Коръәндә дә, дөньялыкта яхшы гамәл кылып, биш фарызны үтәп яшәгән изге җанлы кешеләр күкнең җиденче катына ашар, диелгән.

(«Всемирные новости»).

Уңөченче бит

Алмаз ХӘМЗИН

Ур-ра кычкырып...

Әй, балалар, башлар каткан инде, нәрсә уйларга да белгән юк. Уйлап та карадык инде, эшләп тә, ешләп тә. Бу доньяда безгә җүнләп яшәргә язмагандыр инде. Әйбәт кенә, тыныч кына яшәп ятканда нәрсә булса да ишеп төшерәләр безнең башка. 95 кәник җиткәненә үкенеп яшисең, билләһи.

Яшь гомеркәйләремнең чәчәктәй вакытында революция чыкты. Сорап та тормыйча мине бер большевикка кияүгә бирделәр. Мамадыш янында аклар белән сугышканда ур-ра кычкырып үлде. Ике бала белән өчәүләп акырып елап калдык. Шуннан соң, әйбәт кенә яшәп ятканда, колхоз төзи башладылар. Бер коммунистка кияүгә чыктым, өч көннән соң, ур-ра кычкырып йөри торган җиреннән юкка чыкты. Кулаклар урманда агачка асып киткәннәр. Өч бала белән дүртәүләп акырып елап калдык. Шуннан, әйбәт кенә яшәп ятканда, ике балалы бер председательгә кияүгә чыгып, дүрт көн үткәч, моны да «халык дошманы» диеп, ур-ра кычкырып йөри торган җиреннән алып киттеләр. Әле дә кайларда башы югалганын әйтүче юк. Биш бала белән алтаулап акырып елап калдык. Тагын шуннан, әйбәт кенә яшәп ятканда, хатыны үлгән ике балалы бер иргә кияүгә чыккач, немес белән сугыш башланды. Мәскенкәемнең, ур-ра кычкырып атакага барган чагында авызына пуля кереп җан тәслим кылган. Җиде бала белән сигезәүләп акырып елап калдык.

Менә шулай гомерләр үтте. Җиде бала үстереп бирдем туган илгә. Сигезәүләп, ур-ра кычкырып, коммунизм төзедек.

Беренче балам, чирәм җирләргә китеп, тракторга кысылып ур-ра кычкырып үлде. Икенче балам җир тетрәгәч Ашхабадка китеп ур-ра кычкырып басылып үлде. Өченчесе Днепрогэс төзергә китте. Суларга батып үләсен белсәм, җибәрмәгән булыр идем. Ур-ра кычкырып, субай сугып, бетте безнең татар башлары. Дүртенчесенең гомерләрен шахта күмерләре алды. Бишенчесе утызын да тутыра алмады, бер гаепсезгә төрмәләрдә черетеләр газиз башкаен. Алтынчымның язмышы минекенә охшаса да охшар икән бер дә кияүдән уңа алмый Эчәләр бит ирләр, эчәләр, ур-ра кычкырып эчәләр. Малае Әфганда югалды. Җиденчемнеке — Чечняда, әле исән ди, ур-ралар кычкырмады микәнни?..

Әй заманалар! Тагынниләр күрсәтер бу дөнья? Пенсияләр бирү дә бетәр микән инде? Сберкнишкәдәге акчалар да ур-ра кычкырып янды. Их, ур-ралар кычкырып үләр идем, үлемтеккә акчам җитми.

Әй, онытып торам икән бит әле. Безнең авыл Ташлыкта яңалыклар булды бит әле. Гомер буе тыныч кына яшәгән авылның дүрт урамы кисешкән чатка ур-ра кычкырып светофор куйдылар. Район буенча светофор кую планы үтәлсен өчен куйдылар микән инде аны, әллә берәр нәчәльниккә медаль кирәк булды микән. Әй, нәрсәгә соң әле монысына катышып торам... Куйган көннең шул мизгелендә үк бер кәҗә тәкәсен бәреп үтерделәр. Кызыл утка аркылы чыгып барганда яшел ут белән килүче пионерлагерь нәчәльниге машинасы белән сытып киткән. Шул ук көнне шул урында өч песинең, биш этнең башына җиттеләр. Ике кеше чатан калды, бер сәпит яньчелде, бер К-700 бетон баганага бәрелеп мәңге кабынмаслык хәлгә килеп, гомерлек һәйкәл булды. Шул бәрелүләрдән светофорга бик якын торган мәчетнең манарасы яңадан янтайды. Җен Фатыйх бер төн эчендә йортын элекке урыныннан 50 метрга эчкәрәк күчереп салды. Авыл халкы хафага төште. Киңәштеләр дә килештеләр: светофорга тимәскә, чөнки өстәгеләрнең ачуы кабарырга мөмкин, ә шулай да аның бер генә төсен, кызыл төсен генә калдырырга булдылар. Һәм шулай иттеләр дә. Тимерче Бәдерттиннең кадими заманыннан калган кувалдасын апкилеп светофорның тимер баганасын төяргә тотындылар. Башта светофор бөтенләй сүнде, тагын бераз кыйный торгач сарысы кабынды, аннан яшеле баганада шактый яньчелгән бер кызыл ут калды.

Шул ук көнне багана төбендә колхозның Алмаз исемле пләмәнни үгезен таптап киттеләр Светофор төбендәге кибеткә аракы кайткан булган. комбайнерлар моны ишетеп. комбайннары белән кайтып килгәндә. кызыл утлы светофорны сөзеп маташкан чагы булган, үзе пычакка килеп керде, диделәр, ур-ра кычкырып

Шул ук көнне. аракыга Шәңгәлчеләр килеп. утыз гавык, кырык казны илле үрдәкне таптатып киткәннәр, имеш Ташлыкта светофор куелганны белмәгәннәр.

Шуннан, авыл халкы тагын җыелып, бу светофор мәсьәләсен хәл итергә булды Әйдә. өстән куйдырткач торсын инде. ачуларын кабартмыйк дип. шул ук Бәдерттин кувалдасы белән бәреп, үзебезчә — татарча булсын дип, яшелне генә калдырдылар Өстән күрше Кушай авылы кешесе Жәкәүне ГАИ итеп куйдылар Күп тә үтми аның тапталган гәүдәсен пычрак юлдан куптарып алдылар Әле җан бирмәгән булган Үзе шәп кенә җиффәргән Җиффәрмәгән булса, исән каласы түгел икән Күрше Тоба авылы кешеләре бу нинди җүләр авыл уртасында күсәк болгап тора дип, иске «Запорожец» машинасы белән таптатып киткән булганнар.

Икенче көнне светофорның утын шул Бәдерттин кувалдасы белән бәреп сары утка күчерделәр

Шул төнне җиңгәчәмнең Чечнядагы малае психованный булып кайтып, светофорны Казандагы элеккеге обком бинасы каршына утыртып куйган Барсагыз, күрерсез Сары уты әле дә бертуктаусыз янып-сүнеп эчне пошырып тора. Торсын — урыны дөрес куелган Өстәгеләргә ул килешә торган төс — ни кызыл түгел, ни яшел. Монда хайван тапталасы юк, рәзве андә-монда берәр кеше эләксә генә инде, үзегез беләсез, бездә кеше чутта түгел Аннан соң, өстәгеләр беркайчан да ур-ра кычкырып яшәмәделәр. Ур-раны без кычкырдык, хәер без инде башка бер нәрсә дә эшли белмибез.

Фәйләсүф

Бер олы фикер иясе фани дөнья мәкатьләреннән ваз кичеп, тирән базга ешеп, фәйләсүфия белән мәшгуль булын. Көннәрдән бер көнне яшьләр моңа, азында эзләп табып, әйткәннәр:

— Фәйләсүф ага, әйдә, чык базыңнан! рамда, өстә каты сугышлар бара, халыбызны кыралар, иленнән сөрәләр, каннары да кулына корал алырга кур. Син мәшһүр шәхес, чык дөньяга, хакны көрәшкә күтәр! — дигәннәр. Юкса, безнең милләт изелеп-сытып, кырылып бетәчәк.

— Бу бик вак мәсьәлә! — дигән фикер се. — Сез төрекләрдән куркыгыз, алар тар халкын кол итмәкче була!

АЛТАТАР.

А. УТЭГОНОВ рәсеме.

● **Күз алдыны китерегез: кичәгенәк миңа чәчәк бүләк итеп маташа!..**

Кирам САТИЕВ

Микрофонны тота белмисез

Элек мин зур артист идем Ә хәзер гади бер тамашачы Залда концерт карап утырам Шәп җырлыйсыз сүз дә юк Ләкин микрофонны тота белмисез!

Учлап тотма! Син бит доярка түгел артист! Микрофон ул сыер җилене түгел Аны бармак очлары белән генә тотарга кирәк Культурно итеп

Хәзер инде нинди ераклыкта тоту мәсьәләсен хәл итик Авызга якынрак булган саен. микрофон тавышны көчәйтә сизгерлеге арта Ләкин аны кайбер җырчылар кебек авызга тыкмаска кирәк Микрофон ул авыз гармуны түгел

Авыздан чыккан ят тавышлар гыжлау чапылдау һ б лар микрофонга кермәсен өчен аны ераграк тотарга киңәш бирәм Микрофон ераграк булган саен тавыш та чистарак була

Кулны арытмас өчен микрофонны куеп торырга да рөхсәт ителә Моның өчен махсус җайланма — стойка бар Ул булмаса, урындыкка да өстәлгә дә куярга була Ләкин микрофонны идәнгә сузып салырга һич кенә дә ярамый куйганда. алганда кулга шырпы керүе ихтимал

Соңгы вакытта сатуда пластмасс микрофоннар күренә башлады Бу бик яхшы чөнки элеккеге тимердән эшләнгәннәре ягылмаган клубларда кулны өшетә иде Ләкин аларны тагын да камилләштерергә дигән тәкъдим бар боларга тире чорнарга кирәк Заводтан ук микрофонны чын тиредән ясап чыгарсыннар иде Урысча әйткәндә — натуральный кожадан Беренчедән бу сәламәтлеккә файдалы икенчедән кулны өшетми өченчедән тотарга рәхәт Чын тире кыйммәт тора торуын ләкин моңа акча кызганмаска кирәк Ясалма тиредән эшләнгән микрофон сәламәтлеккә зыянлы Аның шулай икәнен озаграк күбрәк. ешрак тоткан саен ныграк тоясың.

Инде бу җайланманың зурлыгы турында да аңлашыйк Кайберәүләр зуррак булган саен яхшырак дип уйлыйлар Хикмәт аның зур булуында түгел ә сыйфатында Кечкенәсе белән дә көчле тавыш чыгарырга була һәм киресенчә

Һәркемнең үз микрофоны булырга тиеш Беренчедән үз әйбереңне саклап кадерләп тотасың, икенчедән сәламәтлек министрлыгы шулай куша чөнки теләсә кем тоткан әйбер чиста булмый

Микрофонның чукмары зур булмасын иде Бәлки ул шулай яхшырактыр ләкин тамаша залыннан караганда ифрат дәрәҗәдә ямьсез күренә Ә төсе кызыл булсын иде Ут сүнгән очракта ерактан ук күренеп торсын өчен

Соңгы елларда шнурсыз (киндерәсез) микрофоннар пәйда булды Болары депутатлар өчен бик уңайлы Урыннан тормый гына сөйлисең дә микрофонны күршеңә тоттырасың Күршең дә күршесенә суза.

Микрофонны кайсы кул белән тоту хәерле? Ничек тә ярый Кушылучыларның урыннарын алыштырудан сумма үзгәрми Ә менә бер егет бу җайланманы ике кул белән тота Концерт беткәч түзмәдем сорадым «Нигә мин әйтәм син аны ике кул белән тотасың?» «Ничек телим шулай тотам анысы минем эш», — диде дә грим бүлмәсенә кереп югалды Ә чынлап та ике кул белән тотарга ярыймы соң? Ярый Тоталык урыны булса

Беркөнне сәхнә артында яшь артисткалар кызып-кызып бәхәсләшәләр микрофонның ниндие яхшы диләр Бик озак тарткалаштылар.. Түзмәдем кистереп җавап бирдем «Эшли торганы», — дидем

ШАГЫЙРЬНЕҢ ЙӨРӘК БӘЙРӘМЕ

Минзәлә тургаенда кунакта

Дәвек авылы мәчете.

Минзәлә халкы, көзге эшләрне тәгәлләгәч, бер җилкенеп күңел ачып алырга гадәтләнгән. Авылларда туйлар да шушы ноябрь башларына туры килә. уңыш бәйрәме дә, хезмәт алдынгыларына кадер-хөрмәт күрсәтү дә Минзәлә туфрагында туып үскән талантларны барлау-хөрмәтләү дә күтәренкә күңел белән көзге муллыкта уза. Узган ел да шулай булды Минзәләнең үзендә һәм авылларында, минем тыйнак иҗатыма югары бәя биреп, зурласалар, быелгы уңыш бәйрәме чорында, гөрләтеп, шагыйрь Рәшит Гәрәйнең иҗат атналыгын уздырдылар Шагыйрьгә 65 яшь тулу уңаеннан уздырылган бу күркәм бәйрәм минзәләлеләр хәтерендә озак сакланыр әле

Бәйрәм хәзерге көндә Тукай районына керә торган Малтабарда — шагыйрьнең туган авылында башланып китте Җыйнак кына авыл клубында алма төшәр урын да юк яше-карты авылдаш шагыйрьнең бәйрәмен тамаша кылырга җыелган. Кичәне Калмия авыл советы рәисе Ринас Исламов ачып җибәрде. Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле, иҗаты хакында бик тәфсилләп район хакимияте башлыгы урынбасары Зөһрә ханым Павлова сөйләде. «Искра» күмәк хуҗалыгы рәисе Рәзиф Кәримов Тукай районы хакимият башлыгы урынбасары Фәһимә ханым Гыйниятуллина шагыйрьнең беренче укытучысы Галия апа Ямалова язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин һ б лар Рәшит Гәрәйне кайнар котладылар аның иҗаты, холкы-фигыле турында җылы сүзләр әйттеләр, бүләкләр тапшырдылар Кичә тәмамлангач та, халык клубтан таралырга ашыкмады: һәркайсының Рәшит Гәрәйгә җылы сүз әйтеп каласы аркасыннан сөеп, кулын кысып ихтирамын белдерәсе килә иде Мин Минзәләдә узган очрашулардан шуны аңладым Р Гәрәйнең шигърияте якташлары яхшы белә ярата, матурлык игелек гойгысы — авыл кешеләренең йөрәгендә

Малтабардан без Минзәлә ягына юл тоттык. Дәвек урта мәктәбендә укучылар, ата-аналар, укытучылар белән бик җылы, самими очрашудан соң, мәктәпнең музеена да күз салдык. Археологлар бу авыл тирәсендә моннан берничә мең ел элек яшәгән кешеләрнең торак урынын тапканнар Музейда борынгы эш кораллары. мамонт тешләрен күрдек Казаннан ерак бу авылда язучылар сирәк кунак була шулкадырмы. очрашу аеруча җылы үтте Дәвектән Кадрәк авылына киткәндә безнә Шәрык стилендә кызыл кирпечтән салынган. үзенчәлекле архитектура өлгесе булырлык, яңа мәчетнең айлы манарасы озатып калды

Кадрәк авылында күпчелек керәшеннәр яши Татарлар да шактый Төзек. матур авыл Кадрәк — Калинин исемендәге күмәк хуҗалыкның үзәге Хуҗалык Җәмәк, Яңа Тәкермән. Иске Мунча. Мортыш Тамак һәм Кадрәк авылларын берләштерә Колхозны Мәгъсүм Рәхимов җитәкли Хуҗалык ит, сөт җитештерә. игенчелек белән шөгыльләнә Быел, корылык ел булса да, һәр гектардан 25 центнер уңыш алынган. Авылда урта мәктәп һәм әйбәт мәдәният йорты бар Китапханә дә бай, бөтен гәзит-журналларны алдыралар Анда 500гә якын (балаларны да исәпләп) укучы йөри Мәдәният сараенда шагыйрьнең иҗат бәйрәменә ныклап әзерләнгәннәр Диварларда Р Гәрәйнең аерым шигырь юллары язылган. рәсемнәр белән бизәлгән плакатлар. аның иҗатына багышланган әдәби бюллетень, стена гәзите чыгарганнар. Урта мәктәпнең татар теле укытучысы Фәридә ханым Нәҗмиева укучыларны шагыйрьнең тәрҗемәи хәле белән таныштырды, иҗат баскычларын тасвирлады. Мәктәптә ана теленә укытуга зур игътибар бирелә икән Балалар сәхнәгә берәмләп тә. төркемләп тә чыкты Р Гәрәйнең шигырьләрен укыдылар җырлары яңгырады Аннары мәктәпнең үз «шагыйрьләре» сәхнәгә күтәрелде Алтынчы сыйныф укучысы Ландыш чәчәкләр турында мондый шигырь язган

Чәчәкле матур болынга
Әнем белән бардык без.
Чәчәк җыеп уйный-уйный,
Өйгә соңга калдык без
Әнем әйтә әйдә. апа,
Туры юлдан кайтабыз.
Бәлки. бик-бик нык йөгерсәк,
Без көтүдән калмабыз
Йөгердек без бик ашыктык,
Арыдык еш тын алдык,
Әмма ләкин барыбер дә
Көтүдән соңга калдык.
Әни безне орышканчы,
Чәчәкләр биреп калдык,
Шулай хәйләкәрлек белән
Бу җәзадан котылдык.

Без инде менә-менә сәхнәгә Энҗе Афзалова йөгереп менәр дип көткән идек. Яшь шагыйрә — Кадрәк кызы Чаллы шәһәрендә татар гимназиясендә укый булып чыкты. әнисе генә соңыннан килеп безне сәламләде

Бәйрәм матур үтте Авыл советы рәисе Юрий Евграпов авылдашлары исеменнән шагыйрьне котлап, аңа изге теләкләр теләде бүләк тапшырды Авыл үзешчәннәре кунакларга һәм шагыйрь хөрмәтенә концерт күрсәттеләр Комбайнчы. баянчы. җырчы Айбулат Ганиев. авыл советы рәисе урынбасары Вәдүт Хәсәншин, җырчы Расиха Камалова һәм башкаларның чыгышын барыбыз да бик яратып тыңладык.

Малтабар авыл клубында очрашу вакыты. Сулдан: М.Хәбибуллин, «Минзәлә» гәзите мөхәррире М.Хәбриев, шагыйрьләр Р.Гәрәй, С.Гәрәева.

Минзәлә шәһәре мәктәпләрендә, «Чишмә» бакча-гимназиясендә, педагогия училищесында һәм медицина техникумында да очрашулар эчкерсез һәм җылы үтте. 3 нче урта мәктәптә, ремонт эшләре барса да, Р.Гәрәйнең бәйрәмен үткәрүдән баш тартмаганнар. Биредә 4 сыйныфта бөтен фәннәр татарча укытыла, ә 4 сыйныфта ана теле урыс һәм татар балаларына аерым укытыла икән. Инде сигез ел буе мәктәптә 1-6 сыйныфларда хореография дәресләре алып барыла, быел Болгариягә фестивальгә барып, тамашачыларны хәйран калдырган «Умырзая» балалар фольклор ансамбле (җитәкчеләре — ирле-хатынлы Биктаһировлар) шушы мәктәптә туган. Ансамбль шагыйрь бәйрәменә дә берничә бию әзерләгән иде. Шушы мәктәптә бер кыз бала, шигырь сөйләгәннән соң, үтенеч сүзләре дә әйтте:

Шагыйрьнең беренче укытучысы Г.Ямалсва.

— Язучы абыйлар һәм апалар, Казанга кайткач министр абыйларга үтенечебезне җиткерегез мәктәбебез бик иске. безнең яңа мәктәп-гимназиядә укыйсыбыз килә алар безгә ярдәм итсеннәр. Ә без тагын да тырышыбрак укырбыз. — диде Соңгы очрашуыбыз Тауасты Байлар авылында булды Ык елгасы буенда утырган бу матур авыл «Яңа юл» колхозының үзәк авылы. Кунаклар белән очрашуга авыл советы рәисе Ләүсирә ханым Ханова, колхоз рәисе Айрат Бариев һәм ата-аналар кил[...] Балалар шагыйрь абыйларының шигырьләрен, аның шигырьләренә язылган җырларны гына яңгыратып калмадылар, үзләре язган шигырьләрне дә укып күрсәттеләр Ана теле укытучысы, мәктәптә 43 ел дәвамында татар теле һәм әдәбияты дәресләре алып баручы Муфавазә ханым Минаева әдәбият түгәрәге оештырган, яшь иҗатчыларның шигырьләрен, фоторәсемнәрен берничә альбомга туплап бара икән. Мәктәпнең ана теле кабинеты да бик үзенчәлекле, керсәң, чыгасың килми... Балалар саф ана телендә чатнатып шигырь сөйләде. Р Гәрәй шигырьләренә инсценировкалар уйнап күрсәтте Дәртле биюләр җырлы уеннарына кунакларны да дәштеләр һәм күренекле язучыбыз Мөсәгыйт Хәбибуллин бер бәләкәч малай белән чүгә-чүгә биеп ки[...] кәнен үзе дә сизми калды «Я[ңа] юл» — районның иң күркәм һә[м] иң бай колхозларыннан берсе Быел икмәкне гектарыннан 29.3 центнер җыеп алганнар мал-туар күп. Быел балык тоту артеле оештырып, лицензия алып җибәргәннәр, алма бакчасы утырткаңнар Һәр кешедә ихата тулы мал, 2-3 койма. Авылга газ кертелгән, җи[ң]ел машиналар, мотоцикллар отыры ишәеп тора, туйлар гөрл[и] балалар туа. Быел октябрь-н[о]ябрь айларында авылда дүрт туй булган. Колхоз рәисе Айрат Газиз улы Бариев, эчке бер горурлык белән, шуларны сөйләде. Минзәләнең авыл хезмәтчәннәре ты[ры]рыш, авыллар төзек, зиратлар ка[ра]лган.

Рәшит Гәрәйнең шигырь бәйрәме әнә шулай матур үтте. Һәр очрашу шагыйрьнең чыннан да «Минзәләнең җырчы тургае» булуына дәлил иде Авыл кешеләрен. авы[л] табигатен туган җирне ихлас да[...]лаган шагыйрь атна буе якташла[ры]рының кадер-хөрмәтен. яратуы[н] үз-якын итүен җаны-тәне бел[ән] тоеп торды

Туган-үскән җиргә булган т[у]рылыкны халык белә, тоя һәм а[ңа] югары бәя бирә икән..

Салисә ГӘРӘЕВА
Казан-Минзәлә-Каз[ан]

Сакләбиләр патшасына

әл-Мөктәдирдән илче булып барган Әхмәд ибне Фазлан китабы

(Борынгы текстны СОЛТАН ШӘМСИ эшкәртте һәм тәрҗемә итте)

(Дәвамы. Башы 16-19 нчы саннарда).

Мин аңа әлеге хатны укып чыктым. Тылмач аңлатып торды. Әтрәк Исламга күчү-күчмәү турында:

— Сез бу сәфәрдән әйләнеп кайтмыйча, мин берни дә әйтә алмыйм, — диде. — Әйләнеп кайткач, нинди карарга килүемне хәлифәнең үзенә язармын.

Шушы сүзләрдән соң ул өстендәге парча киемнәрне салды, бүләк ителгән киемнәрне киеп карамакчы булды. Шунда мин парча кием астындагы эчке киемгә игътибар иттем — ул, озак вакыт салмыйча кигәнлектән, бик нык керләнгән һәм череп өзгәләнә үк башлаган иде. Моңа гаҗәпләнәсе түгел, чонки алардагы гадәт буенча берәү дә, өстендә киеме тузып бетмичә, аны салып ташламый. Кара мыеклы, йолкынган сакаллы бу кеше хәрам агасын хәтерләтә иде.

Сөйләүләренә караганда, Әтрәк төрекләр арасында иң әйбәт җайдак санала икән. Чыннан да, бер көнне без ат өстендә бара идек, шунда мин очып барган бер кыр казын күреп алдым. Әтрәк кинәт җәясен тотты да атын чаптырып шул якка китеп барды. Бераздан казга төзәп атып та җибәрде һәм казны җиргә бәреп төшерде. Өстәвенә, ул әле менә дигән мәргән дә икән.

Көннәрдән бер көнне Әтрәк үз кул астындагы башлыкларны җыйды — анда Тархан, Йынал һәм Баглыз бар иде. Арада иң дәрәҗәлесе Тархан булып чыкты, ул аксак, сукыр һәм чулак адәм иде.

Әтрәк сүзне болай башлады:

— Сезнең алдыгызда гарәп хәлифәсенең киявем Шилке углы Алмыш хозурына җибәргән илчеләре. Мин сезнең белән шушы хакта киңәшергә телим.

Тархан беренче булып телгә килде:

— Моңа хәтле безнең мондый хәлләрне күргәнебез дә, ишеткәнебез дә юк иде. Бу яклардан берәр илнең илчеләре дә үтмәде. Ата-бабаларыбыз да мондый хәлләрне белмәгән. Минем уемча, бу эш хәлифәнең берәр хәйләсе булырга тиеш. Ул бу кешеләрне хәзәрләргә җибәреп, аларны безнең белән сугыштырырга җыена кебек. Иң яхшысы — бу илчеләрне тотып тураклларга да, мал-мөлкәтләрен тартып алырга.

Икенчесе:

— Юк! Үтерергә ярамый. Малларын алырбыз, үзләрен шәп-шәрә калдырып, кире илләренә озатырбыз, — диде.

Өченчесе моңа каршы төште:

— Юк! Һич ярамый. Хәзәр патшасында безнең әсирләребез бар. Боларны шунда алып барып, үзебезнекеләрне тоткынлыктан йолып алыйк.

Алар шулай җиде көн буена безнең язмышны хәл итә алмыйча бәхәсләштеләр. Безгә бу вакытта үлем куркынычы янады. Бәхәсләшә торгач, алар, ниһаять, уртак бер фикергә килделәр дә, безне җибәрергә булдылар. Без Тархан исемлесенә мерв кафтаны белән ике кисәк пайбәф тукымасы, калган башлыкларга берәр куртка бүләк иттек. Өстәп тагын борыч, тары, колчәләр дә бирдек. Шуннан соң алар безне ташлап киттеләр

Без юлны дәвам иттердек. Һәм Йаганды[13] дигән су янына килеп чыктык. Кешеләр юл йөрү өчен дөя тиресеннән махсус тегелгән зур капчыклар тартып чыгардылар да, аларны җиргә җәеп салдылар. Аннан соң йомарланган капчыкларны дөяләр ярдәмендә киерделәр, эченә кием-салым, кирәк-яракны тутырып, авызын кысып бәйләп куйдылар. Суга төшергәч, һәркайсына дүртәр-алтышар кеше менеп кунаклады. Кулларына колгалар алып, аларны ишкәк урынына кулланып, каршы ярга таба ишәргә тотындылар. Көчле агым аларны елга буенча алып китте һәм бик нык әйләндерә башлады. Бу хәл алар каршы ярга барып җиткәнче дәвам итте. Атлар белән дөяләрне исә бик нык кычкыргалап-каулап кына елга кичәргә мәҗбүр итеп булды. Мондый кичү вакытында иң әүвәл каршы ярга кәрванны саклар өчен коралланган бер төркем сугышчылар чыга. Бу чара мондагы башкортлар искәрмәстән кәрванга һөҗүм итмәсен өчен эшләнә.

Йаганды суын без шундый ысул белән кичтек. Соңрак шулай ук Җам суын да чыктык. Аннан соң безнең юлда Җахыш, Изел, Әрдән, Варыш, Анхаты, Вабна дигән гаять зур елгалар очрады[14].

Аннан соң без бәҗәнәкләр җиренә аяк бастык. Алар диңгезне хәтерләткән зур су янында торалар иде. Бәҗәнәкләр тышкы кыяфәтләре белән кырылган сакаллы, кара тутлы халык, угызлар белән чагыштырганда, алар бик фәкыйрьләр. Угызлар арасында мин унар мең җылкы һәм йөзәр мең куйлары булган кешеләрне күрдем. Аларның куйлары аяк астында ни тапсалар, шуның белән туеналар, тояклары белән карда тибенеп йөреп коры үлән ашыйлар. Ашарга тапмаганда кар кимерәләр. Коры үлән туклыклы, ул куйларны бик нык симертә. Арт саннарында җыелган майлы көрдек җирдә үк сөйрәлеп йөри. Җәй җитү белән куйлар яшел үлән ашый башлый һәм ябыгалар.

Бәҗәнәкләрдә без бер генә көн кундык. Аннан соң кабат юлга чыктык һәм Җаек суы буенда туктальш ясадык. Бу без күргән елгаларның иң зурысы булып, агымы да бик көчле иде.

Чыннан да, елганы кичкәндә кешеләр утырган берничә капчык капланды да алар батып үлделәр. Гомумән, бу елганы чыкканда без шактый кешеләребезне, дөяләрне, атларны югалттык. Җаек аша чыгу безгә бик кыенга туры килде.

Байтак көннәр үткәч, безгә башта Җаха[15] елгасын, аннан Ирхиз, Бачаг, Сәмур, Кинал, Сух, аннан соң Көнҗеле дигән суларны кичеп чыгарга туры килде Бу елгаларны үткәннән соң без төрек кавемнәренә кергән башкортлар иленә килеп җиттек. Без бик нык сакланып, курка-курка гына хәрәкәт иттек, чөнки бу кавем төркиләр арасында иң начарлардан санала. җитмәсә алар бик пычрак яшиләр һәм кеше үтерү алар өчен берни тормый Аларның берәрсе икенче бер ят кешене ачык далада очратса, башын кисә дә үзе белән алып китә, ә гәүдәсен шунда калдыра.

Алар сакалларын кырып йөриләр һәм бет ашыйлар Берсенең курткасын салып, аның җөйләрендәге бетләрне теше белән сыткалавын үз күзләрем белән күрдем Безнең арада бер хезмәтче мөселман башкорт бар иде Бервакыт ул киеменнән бет тотып алды да, аны тырнагында изгеч, теле белән ялап куйды

Аларның һәрберсе таяктан ирләрнең җенес әгъзаларын юнып ясый, аны бау белән муенына асып куя Берәр сәфәргә җыенганда яисә дошман белән очрашканда шушы таякны үбә аңа сәҗдә кыла.

— Йа, Тәңрем, ярдәмеңнән ташлама! — ди.

Бу хәл миңа кызык тоелды һәм мин тылмачтан:

— Берәрсеннән бел әле, алар ни өчен болай эшлиләр, аңа нинди мәгънә салалар? — дип сорадым — Ни өчен Тәңреләре итеп ирләрнең җенес әгъзаларын сайлаганнар?

Башкорт безгә:

— Ни өчен дисезме? Чонки мин якты дөньяга шушы нәрсә аркасында килгәнмен. Башка тудыручыны белмим, — дип җавап бирде

Бервакыт арадан берсе минем унике иям бар дип әйтте һәм санап күрсәтте: кыш иясе, җәй иясе, яңгыр иясе, җил иясе, агачлар иясе, көн иясе, өҗәл иясе, җир иясе, ә Тәңре — ияләрнең иң зурысы һәм көчлесе — күктә яши икән[16]. Ләкин ул калган ияләр белән дә үзара тату тора, гомумән, ияләр дә бер-берсе белән каршылыкка кермиләр. Үземнән шуны өстәп әйтә алам. безнең Аллаһыбыз бу ияләрнең барысыннан да өстен һәм бөек, Аллаһыбызның кодрәте чиксез.

Без аларда бер кабиләнең еланга, икенчесенең — балыкка, өченчесенең торналарга табынуын да күрдек. Миңа башкортларның ниндидер дошман белән сугышуын сөйләделәр, дошманнары өстен чыгып, тегеләрне качарга мәҗбүр иткәннәр. Шул вакыт дошман артында калган торналар шундый итеп тавыш күтәргәннәр ки, дошманнар куркудан үзләре үк качып беткәннәр. Шул көннән башкортлар ярдәм иткән өчен торналарга табына башлаганнар «Торна — безнең тәңребез, ул дошманыбызны куркытты, аны качарга мәҗбүр итте», — диләр алар

Күпмедер вакыттан соң без башкортлар иленнән китеп бардык һәм Җамсаран (Чирмешән) суын кичтек. Аннан соң Үрән, Урым, Байнах (Майна), Ватыг (Утка), Нийасна һәм Җавшыз елгалары аша уздык. Беренче елга белән соңгысы арасын ике-дүрт көндә үтәргә мөмкин

Болгар патшасына килеп җитәргә бер тәүлек ара калганда, ул безне каршыларга үзенең дүрт биен, ир туганнарын һәм улларын җибәрде. Алар безне кулларына икмәк, ит, тары тоткан килеш каршыладылар һәм юлны бергәләп дәвам иттерделәр. Патша безне урдасына ике фәрсах[17] ара калганда каршы алды. Күреп алганнан соң атланган атыннан төште дә бөек һәм кодрәте чиксез Аллаһка рәхмәтләр әйтеп, каршыбызда тез йөгенде Аның җиң эчендә дирһәмнәр булган икән, ул аларны безнең өскә сипте Ул шулай ук чатырлар тирмәләр куйдырды һәм без анда урнаштык.

Без болгар патшасына 309 елның 12 мөхәррәмендә ял көнне килеп җиттек (722 елның 12 мае) Җөрҗаниядән (Харәзем) аның иленә кадәр без җитмеш көн килгән булып чыктык

Ял дүшәмбе сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрне без үз тирмәләребездә ял иттек бу вакыт Болгар иленең төрле якларыннан әлтабар урдасына шушы җирнең биләре аксакаллары олуг затлары һәм гади халык агылды Алар хәлифә хәзрәтләре җибәргән хатны уку мәрасименә[18] җыелалар иде

Хәлифә хәзрәтләренең хатын уку тантанасы чакырылган халык килеп беткәннән соң пәнҗешәмбе көнне булды Без алып килгән ике кара байракны сүтеп җибәрдек бүләккә дип билгеләнгән ак юртак сыртына зиннәтле иярне салдык әлтабарның үзенә мөэминнәр әмиренең иң олкән түрәләре генә кия торган кара чапан кидердек, башына чалма чорнадык Әзерлек тәмамланганнан соң мин хәлифә хәзрәтләренең хатын кулыма алдым да әлтабарга

— Хәлифә хәзрәтләренең хатын утырган килеш тыңлау килешеп бетмәс, — дидем

Ул аягына торып басты дәүләтнең олуг адәмнәре дә аңа ияРделәр Әлтабар үзе гаять юан һәм зур корсаклы кеше иде Мин хатның кереш өлешен укып бетереп хәлифә хәзрәтләренең Алмыш әлтабарга юллаган сәламнәрен, аңа иминлек теләвен Аллаһыбызны зурлап әйткән кәлимәләрен тапшыргач «Син дә җавап йөзеннән мөэминнәр әмиренә сәламәтлек һәм иминлек телә» — дидем

Ул тиешле сүзләрне әйтте башкалар аның артыннан кабатлады

Тылмач укыган һәр сүзне тәрҗемә итә барды Хат укылып беткәч алар барысы берьюлы дәррәү күтәрелеп «Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр!» дип шундый итеп кычкырдылар. бу авазлардан хәтта җир тетрәнеп куйды Аннан соң мин әлтабарга вәзир Хәмид ибне әл-Габбасның хатын укыдым Аннан соң утырырга куштым һәм Надыйр әл-Хураминың хатын ул инде утырган килеш кенә тыңлады

Хатлар уку тәмамлангач яраннары аның өстенә күп итеп дирһәмнәр сиптеләр Шуннан соң мин бүләкләр тапшырырга керештем — хушбуйлар хуш исле матдәләр кием-салым асыл ташларны берәм-берәм аның үзенә һәм хатынына тапшырдым Бу эш тәмамлангач, алар гадәте буенча. әлтабар янәшәсендә утырган хатыны янына килдем дә җыелган халык алдында аның иңенә ихтирам хөлләсе[19] салдым Хатын иңенә ихтирам хөлләсе салынгач хезмәтче хатыннар аның өстенә дирһәмнәр сиптеләр Шуннан соң без китеп бардык

Бер-ике сәгатьтән болгар патшасы безнең янга кешеләрен җибәрдә һәм үзенә чакырды Без аның тирмәсенә кердек. Кабилә башындагы биләр аның уң кулында утыралар иде, безгә ул сул кулдан урын күрсәтте Ә уллары аның каршысында урнаштылар Әлтабар үзе рум парчасы ябылган тәхеттә утыра иде

(Дәвамы бар).

---

[13] Йаганды — Көнбатыш Казагыстаннан ага торган Чаган елгасы

[14] Шәрык кешесе Ибне Фазлан кечерәк елгаларны да зур дип кабул итә аларның исемнәрен дә бераз бозып яза.

[15] Җаха — Җаекның уңъяк кушылдыгы Ибне Фазлан санап киткән елгаларның хәзерге исемнәре түбәндәгечә Ирхиз — Иргиз Бачаг — Моча Сәмур — Самара, Кинал — Кинел Сух — Сок. Көнҗеле — Кондызча Шулай итеп, илчелек кәрваны Иделнең Самара дугасын әйләнеп узып Болгарга якынлаша

[16] Төрки халыкларның төп алласы Күк Тәңре дип аталган

[17] Фәрсах — 1 фәрсах 6-7 чакрымга тиң.

[18] Мәрасим — церемония

[19] Хөллә — халат

Хәсән Туфанның тууына 95 ел

Намуслылык үрнәге



Безнең халык Хәсән Туфан, аның аянычлы язмышы турында укып та, ишетеп тә белә. Күпләрне бер сорау борчый торгандыр. «Ничек соң Туфан шундый хәлгә тарган, бер яклаучысы да табылмаган?» Бу сорауга җавап бирер өчен, «Совет әдәбияты» журналының 1930-1940 нчы елларда дөнья күргән саннарын карыйм һәм 1936-1938 елларда чыккан тәнкыйть мәкаләләреннән кайбер өзекләрне укучыларга тәкъдим итәргә телим.

«Совет әдәбияты» журналы 1936 елның 4 нче санында татар совет язучыларының Казан шәһәре күләмендәге дискуссиясендә сөйләнгән берничә чыгышын бастыра. Кави Нәҗми (ул елларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе) үз чыгышын «Социалистик реализм өчен» дип атый. «Алты утырышка сузылган бу зур дискуссия безнең күз алдыбызга күп кенә начар һәм кайберләре турыдан-туры зарарлы булган әсәрләрне китереп бастырды. Бу нәтиҗә шушы җыелышта тәнкыйть ителгән әсәрләргә һәм бигрәк тә Хәсән иптәш Туфанның «Ант» поэмасы белән Ш.Усмановның «Легион юлы»на карата дөрес.

Әгәр дә Ш.Усманов иптәш үзенең ялгышлары тирәсеннән бик җиңелчә генә котылып үтсә, Туфан инде аларны үзенең ике сәгатьлек речендә бөтенләй томалап калдырды...

...Бу чыгышында Туфан үз иҗатын яклый, масаюы, үз иҗатына соклануы, халык интереслары белән санашмау шундый ачык күренде ки, без беребез дә ул речь яныннан тыныч кына үтә алмадык...»

Журнал Гомәр Галиевнең (бу вакытта «Совет әдәбияты» журналы мөхәррире) «Туфан иҗаты турында» дигән чыгышын бастыра.

Г.Галиев Х.Туфанның «Урал эскизлары» (1926) һәм «Башлана башлады» (1927) поэмаларының уңышлы булуын әйтеп үтә. Х.Туфанны аерым алганда, ил үсешеннән артта калуда, совет поэзиясен экспериментлар лабораториясенә әйләндерүдә гаепли. Г.Галиев «Ант» (1935) поэмасы турында түбәндәге фикерләрне әйтә: «Туфан поэзия аркылы Ленин-Сталин чорының иң югары идеяләрен чагылдырырга тели. Үткән гасырларга, аның идеалистик шагыйрь һәм философларына экскурслар ясап, безнең илебездәге беренче чынбарлыкны, Ленин-Сталин өйрәтүләрен тормышка ашыру нигезендә ирешелгән бөек уңышларны шуларга контраст итеп куярга тели... Композициядә зур буталчыклык, бәйләнешсезлек күрәбез. Төп моментлар әсәрнең тап каркасы белән һичбер бәйләнмәгән рәвештә килеп керәләр. (Хәят фәлсәфәсе, мунча мәсьәләләре, «Каф тавы» әкиятләре һ.б.)».

Г.Галиев Х.Туфан иҗатындагы кимчелекләрне күрсәтүдә ике юнәлеш билгели:

1) Большевикларча ярдәм итүчеләр;

2) О.Мортазин кебек, «Мин Туфанның бу ялгышларына шатланам» диючеләр. Бик нечкә тоемлау белән генә тотып алып була — Г.Галиев Туфанга теләктәш. Ләкин ул тәнкыйди чыгыш ясарга мәҗбүр. Ул тырыша-тырыша Х.Туфан иҗатыннан җитешсезлекләр эзли. Бу елларда чыккан тәнкыйть мәкаләләренең иң дорфасы итеп Т.Имаметдиновның 1938 елда «Совет әдәбияты» журналының 5 нче санында чыккан «Х.Туфан иҗаты турында» дигән мәкаләсен күрсәтергә булыр иде.

Т.Имаметдинов монда Х.Туфанның 1932 елда чыккан шигырьләр җыентыгын тәнкыйтьли.

«Туфан үзенең зур политик, идеологик хаталарын иҗаты формасындагы хаталарга гына кайтарып калдырырга уйлый».

Автор шагыйрьне яңа сүзләр уйлап чыгаруда, образларны бирә белмәүдә, шигырьдәге мәгънәнең авыр аңлаешлы булуында гаепли. Мисал итеп, «Козырь туз» (1925), «Еллар» (1925), «Иске Рәсәй үлде» (1927) шигырьләрен китерә.

Имаметдинов. Х.Туфан шатлыклы җырларны совет власте белән канәгатьсезлеген сиздермәс өчен генә яза, дигән нәтиҗә ясый. Шулай ук шагыйрьнең милли мәсьәләләрдә буталуын әйтеп уза һәм исбат итү өчен

«Аңлаттылар шунда
Милләттән
Сыйныф ягы важный икәнне» — дигән юлларны китерә дә, «Аңлаттылар» сүзен ирония белән әйтә бит ул, дип өстәп куя.

Тәнкыйтьчегә Туфан шигырьләренең ике мәгънәлелеккә урын калдырулары да ошамый. «Ант» поэмасын «Идеологик зарарлы һәм политик хаталар белән тулган». — ди.

Билгеле булганча, Х.Туфан 1937 елда «политик хаталары» өчен Язучылар союзыннан чыгарыла.

Т.Имаметдинов үз мәкаләсен «Җыелыш Туфанны бүгенге иҗаты белән совет Язучылар союзына член итеп кайтарырга иртәрәк әле, үзен иҗаты белән күрсәтсен һәм Совет платформасыннан торып язылган художестволы әсәрләр бирсен», — дип тәмамлый.

Туфанның тырнак астыннан кер эзләүчеләрнең күбесе үзләре дә шәхес культы корбаннарына әйләнә. 1940 елның козендә Туфан кулга алына. Иреккә ул 16 ел үткәч кенә чыга.

Уннарча ел буена шагыйрь никадәр пычраклык, вәхшилек күрсә дә, үзенең кешелеген югалтмый. Аның күңеле баланыкыдай саф, чиста, тормыш ваклыкларыннан югары кала.

Хәзерге вакытта Х.Туфанны шагыйрь итеп кенә түгел, намуслылык үрнәге буларак та өйрәнергә кирәк.

Резида ӘХТӘМОВА,
Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты аспиранты

Дәүләт

Китап



Инде хәбәр иткәнебезчә, үткән атнада Татарстан Дәүләт Советында «Татарстанда китап нәшер итүнең һәм аны таратуның торышы турында» парламент киңәшмәсе булып узды.

Киңәшмәне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.Харисов алып барды. Мәсьәләнең үтә дә җитдилеген истә тотып, без бу сәхифәдә парламент мөнбәреннән ясалган кайбер чыгышларны беркадәр кыскартулар белән укучыларыбыз дикъкатенә дә тәкъдим итәбез.

Ислам ӘХМӘТҖАНОВ, Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министры:

— Бүгенге көндә матбагачылык катлаулы чор кичерә. Китап нәшер итүнең кискен кыскаруы җәмәгатьчелекне дә, язучыларны да, укучыларны да нык борчый, билгеле. Беренче чиратта татар китапларын һәм классик язучыларыбызның әсәрләрен тиешле дәрәҗәдә бастыра алмавыбыз нык борчылу тудыра. Китап киштәләрен отыры агрессив масса-культура продукциясе били бара.

Югыйсә, демократик җәмгыятьтә китап сагында, һичшиксез, дәүләт үзе торырга тиеш. Хәзергесе вакытта бездә 151 нәшрият исәптә тора. Алар арасында иң эреләре икәү — Татарстан китап һәм «Мәгариф» нәшриятлары. 1991 елга кадәр Татарстан китап нәшрияты дәүләткә табыш бирә торган оешма иде. Ә хәзер? Мәсәлән, 1995 елда нәшрият 150 исемдә китап чыгаруны планлаштырган һәм моның өчен дәүләттән 3 млрд. 345 млн. сум дотация сораган. Ләкин дәүләт тарафыннан нәшриятка 1 млрд. 440 млн. сум гына акча бүлеп бирү каралган. Шуңа күрә быел нәшриятның дәүләт ярдәме белән нибары 76 исемдә генә китап чыгарырга мөмкинлеге бар. Инде хәзер чагыштырып карыйк. 1988 елда, мәсәлән, нәшрият 312 исемдә китап бастырып чыгарган, 1989 елда да шул ук күләм сакланган. 1990 елда — 259, 1991 елда 267 исемдә китап нәшер ителгән. 1996 елда Татарстан китап нәшрияты 130 исемдә китап бастырып чыгаруны планлаштыра. Моның өчен бюджеттан җәмгысе 21 млрд. сум күләмендә акча бүлеп бирү күздә тотыла. Ә безнең исәпләүләр буенча, әлеге сумма республика газет-журналларына һәм ике нәшриятка кәгазь юнәтү өчен генә җитә.

Харис ӘШРӘФҖАНОВ, Татарстан китап нәшрияты директоры:

— Татарстан китап нәшрияты вәгъдә ителгән сумманың 1 ноябрьгә нибары 43 процентын гына ала алды. Ә бүгенге көндә 9-10 басма табаклы китап нәшер итү өчен кимендә 70-75 млн. сум күләмендә акча кирәк. 5 мең данә белән чыккан андый китапның сатудагы бәясе дә 8-9 мең сум булырга тиеш. Ләкин бу хакка аны, ай-һай, сатып алучы табылыр микән? Шунлыктан без ул китапларны 1-2 мең сумга сатарга мәҗбүрбез. Күрәсез, аз тиражлы татар китапларын дәүләт дотациясеннән башка нәшер итүне күз алдына да китереп булмый. Бу җәһәттән Русиядәге 13 нәшриятның үз, җирле язучыларының китапларын бөтенләй бастырмый башлауларын да әйтеп китү урынлы булыр.

Әмма нинди генә кыенлыкларга да карамастан, без әлегә кул кушырып утырырга җыенмыйбыз. Мәсәлән, бүгенгесе көнгә нәшриятыбыз 80 исемдә китап бастырып чыгаруга ирештә, шуларның 47се — татар телендә. Ел ахырына кадәр тагын 20 чамасы китапны укучыларыбыз хөкеменә тапшыра алырбыз, дип уйлыйбыз. Хәзерге бәяләр белән исәпләгәндә, нәшриятка киләсе ел өчен 9 млрд. сум акча таләп ителә. Дотация күләмен алга таба да кыскарту республикабызны зур интеллектуаль югалтуларга, нәшрият коллективын тәмам таркалуга китерергә мөмкин.

Роберт МИҢНУЛЛИН, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының милли һәм мәдәният мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе:

— Җөмһүриятебездәге матбагачылык эшенең торышы белән якыннан танышкач, шундый нәтиҗәгә киләсең: без бүген дә галиҗәнап татар китабын мәсхәрәле торган данлы традицияне бик лаеклы рәвештә дәвам итәбез әле. Сәер хәл бит: финанс министрлыгы нәшриятларга хәтта тиешле акчаны да биреп җиткерми, ә нәшриятлар үз чиратында полиграфчыларга, ә сәүдә предприятиеләре нәшриятка бурычка бата. Шулай итеп ниндидер сихерләнгән боҗра барлыкка килә. Ә ахыр чиктә без барыбыз да укучы алдында бурычлы булып калабыз.

Дөресен әйтергә кирәк, бездә китап бастырып чыгару эшенә үтә дә кадими караш яшәп килә әле. Миңа калса, төп бәла дә әнә шунда бугай. Безнең түрәләр өчен мәдәният барыннан да элек тамаша булды һәм шулай булып кала да. Дәүләт, хөкүмәт җитәкчеләре дә тамаша кыла торган «правительственный концерт»ларны хәвеф-хәтәрсез, ЧПсыз гына үткәреп җибәрү алар өчен иң югары мәдәни казаныш санала. Кызганычка, бу түрәләрнең күбесе татар мәктәбендә белем алмаган, балачактан татар әдәбиятын укып үсмәгән, мәдәниятебез тарихы белән кызыксынмаган. Һәм, ни аяныч, алар татар әдипләрен хәзер дә укымыйлар.

Турысын әйтергә кирәк, бүген иҗат әһелләре арасында язучыларыбыз иң кыен, иң кызганыч хәлдә торып калды. Дөрес, язучы халкына элек тә җиңел түгел иде, ә хәзер алар туры мәгънәсендә хәерчелектә, мохтаҗлыкта очын-очка ялгап җан асрый. Әнә, Татарстанның халык шагыйре 62 яшьлек Илдар Юзеев та, чир-сырхаудан арынмавына карамастан, балалар газитендә әдәби хезмәткәр булып эшләп йөрергә мәҗбүр. Андыйлар бик күп. Мин инде вафат булган язучылар гаиләләренең хәле турында әйтеп тә тормыйм. Кыскасы, без китапның язучы өчен бердәнбер яшәү чыганагы булуын һәрдаим истә тотарга тиешбез.

Туфан МИҢНУЛЛИН, Татарстанның халык депутаты:

— Гафу итәсез, мин чыгышымның файдасыз һәм мәгънәсез булу-

ын белә торып чыгыш ясыйм. чөнки организмымда җыелган адреналин бераз таркалмасмы, димен. Миңа калса, китап безнең дәүләткә кирәкле әйбер түгел бугай. хөкүмәткә — бигрәк тә. Әгәр дә ул безнең хөкүмәткә кирәкле әйбер булса, мәсьәлә инде күптән хәл ителергә тиеш иде. Бу турыда инде сүз ничә еллар буе бара лабаса. Без әлеге мәсьәләне бары тик китап чыгару, китап сату, сәүдә өлкәсенә генә кайтарып калдырдык, ә бит аның төбендә «Татар милләтенең киләчәге бармы, юкмы?» дигән мәсьәлә ята. Әгәр шушылай итеп карамаганда, бу хакта сөйләшеп торуның мәгънәсе юк. Бүгенге киңәшмәдә Президент үзе катнашса да, зыян булмас иде. Әйе, без бүген матди хәерчелек кенә түгел, рухи хәерчелеккә таба барабыз, без упкын кырыенда басып торабыз. Әгәр шушылай дәвам итсә, тагын 5-6 елдан безгә бернинди китапның да кирәге калмаячак. Без инде тотташтан исерек, сәрхуш җәмгыять булачакбыз. Аракы сату бездә бик дөрес куелган, ә менә китап сату беркемгә дә кирәкми.

Гомумән, китаптан ниндидер файда күрергә тырышу ахмаклыктыр дип уйлыйм. Менә монда әйтәләр, авылда китап укыйлар, авылга илтеп сатарга кирәк, диләр. Ә мин әйтәм: укымыйлар, укырга теләмиләр, димен. Китап укудан чиновниклар гына түгел, гади укучы да бизде инде. Хәзер укыттырыр өчен, җаным, менә укы, дип кулына бирергә кирәк аның, бушка бирергә кирәк. Син надан калма, бәгырькәем, менә, акчаң юк икән, ал, укы, югыйсә, харап булабыз бит, дип әйтергә тиеш.

лык арасында да мәдәниятнең бәясе артыр иде. Әгәренки Президент, Премьер-министр, Дәүләт Советы Рәисе дәрәҗәсендә безнең әдәбият, сәнгать, мәгариф һәм фән белән шөгыльләнәләр кызыксыналар икән, димәк, аның белән халык та кызыксыныр иде. Инде бер әйткәнемчә, без болай да җитәкчеләргә карап яшәргә өйрәнгәнбез ич. Әнә теге вакытта Мөхәммәт Сабиров ындыр табагы хәтле фуражка тектереп кигәч, бөтен Татарстан район җитәкчеләре шундый фуражка киеп йөри башлады. Димәк, безнең җитәкчеләргә карыйлар, аларга игътибар итәләр. Шуңа күрә җитәкчеләребезнең биредә булуы бик тә кирәк иде.

Безнең республикада бүгенге көндә дүрт меңгә якын китапханә бар. Алар югары уку йортларында, төрле оешмаларда, мәктәпләрдә урнашкан. Ә дәүләт китапханәләре мәдәният министрлыгына караганнары — 1653. Шул 1653 китапханәдә 22 миллионга якын китап бар, аларның 4 миллионга якыны татар китабы. Мине иң борчыганы шул: татар китапларының китапханәләргә килүе ел саен 10-15 процентка кими бара. Татар китабын китапханәләр алмый. Менә Туфан Миңнуллин әйтте: татар китабын укымыйлар диде. Юк, китапны китапханәләрдә укыйлар. Халык бәлки китапны кибетләрдән сатып ала алмый торгандыр, чөнки хезмәт кешесенең хәзер акчасы юк, ә китаплар кыйммәт. Әмма ләкин китапханәләрдә китап уку, бигрәк тә татар китабын уку көннән-көн арта бара. Мәсәлән, республика буенча бер китап ике мәртәбә, ә татар китабы өч мәртәбә алына. Димәк, татар китабы күбрәк укыла, димәк, халыкта ихтыяҗ бар, дигән сүз. Ә менә 1994 елда 21 районда Татарстан китап

национальной библиотеке Башкортстана собирает заказы на литературу издательства «Китап» на 1996 год. Литература отпускается бесплатно, просим выслать ваши заказы» — дип язылган. Күрәсез, Башкортстанда китапны бушлай тараталар. Бер тиен дә акча алмыйлар, алыгыз инде зинһар, дип мөрәҗәгать итәләр. Ә без акча эзләп йөрибез. Нишләп соң ул күршеләрдә китапка андый мөнәсәбәт, тә бездә мондый мөнәсәбәт соң? Менә мин шуны һич кенә дә аңлый алмыйм.

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ, Татарстан халык депутаты, Язучылар берлеге идарәсе рәисе:

— Бүгенге көндә татар әдәбияты, татар китабы чыннан да һәлакәт алдында тора. Чөнки бүгенге хәлдә язучы турында кайгырту мөмкин түгел. Бик тырышканда да мөмкин түгел. Аерым бер классик язучыга ярдәм итеп була, аерым бер язучының юбилей кичәсен уздырып була. Аерым бер язучының китабын чыгарып була, ләкин бүгенге көндә язучы булырга хыялланып булмый. Хәтта иң күренекле язучыларыбыз да бүген китапларын чыгара алмыйча, ничарадан бичара хәлдә яши. Мәсәлән, Гариф Ахунов үзенең юбилеена бик тә чыгарасы килгән китабын нәшер итә алмады. Туфан Миңнуллинның да үзе теләгән китабы чыкмый калды. Илдар Юзеев та үзенең чыгарасы килгән китабын укучыларга ирештерә алмый йөри. ГУЛАГларны кичкән Гурий Тавлин да үз язмышын сурәтләгән романын 70 яшенә чыгара алмады. Һәм шулай чыгара алмады, чыгара алмады.

Шәхсән мин китап нәшриятында да үзгәртәсе әйберләр бар, дип уйлыйм. Әйтик, өсте-өстенә штатлар тоту бүгенге көндә кирәк түгел. Ул кадәр штат

...ЯЗМЫШЫ — ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ

без бүген. Аннары бездә Телләр турындагы закон да бөтенләй эшләми. Менә шул Законны гамәлгә кертергә 4 миллиард сум акча бүлеп бирелгән, ләкин аны беркем белми: кая киткән ул акча, бирелгәнме-бирелмәгәнме? Бирелгәне кая китә, ни эшли ул акча — аңа беркайчан да контрольлек ителми. Безнең хәрби промышленностька ташламалар бар, «Мелита»га ташламалар бар, ә китапка — юк. Китап белән сәүдә итүчеләр дөрес әйтә, алардан әле бирелмәгән акчаны талыйлар бит. Нишләп әле безнең мәдәниятебез формалаша торган үзәктә китапка салым аракы сату белән тигез куелырга тиеш?

Ни кызганыч, безнең әлеге сөйләшү урынбасарлар дәрәҗәсендә генә үтә. Һәм ул, кем әйтмешли, япон заводларында директорының карачкысын кыйнауга гына кайтып кала шикелле. Ә бит мәсьәлә бик җитди һәм ул шулай дәүләт хөкүмәт җитәкчеләре алдына куелырга тиеш тә.

Разил ВӘЛИЕВ, Татарстанның халык депутаты, Милли китапханә директоры:

— Без бу парламент киңәшмәсен күптән көткән идек, инде ике-өч ел хыялланып йөргән идек һәм бик зур өметләр баглаган идек. Кызганыч, безнең бу өметләребез, инде күренеп тора, акланмады.

Бик дөрес әйттеләр, бүген монда сораучылар җыелган, бирүчеләр берсе дә килмәгән. Без моңа кадәр үзебезнең кабинетларда, үзебезнең оешмаларда аерым-аерым җылый идек. Менә хәзер бергә җыелып хор белән җылыйбыз инде. Ләкин аны тыңлаучы гына юк.

Миңа, китапханәдә эшләгәч, шактый китаплар, шактый мәгълүмат белән танышып барырга туры килә. Америкада кызык бер нәрсә бар: ел азагында АКШ Президентының унике ай дәвамында нинди китап укыганы, нинди театрларга барганы, нинди опералар тыңлаганы, нинди балетлар караганы, нинди музейларда булганы турында мәгълүмат басыла. Әгәр без дә шушыны гамәлгә кертсәк, безнең ха-

нәшриятында, «Мәгариф» һәм башка нәшриятларда чыккан татар китабын алдырмадылар. Бәлки райондагы кибетләргә күпмедер алганнардыр да, ләкин кибетләргә ул бик аз бара. Әмма, кабатлап әйтәм, безнең Милли китапханә аша 21 районда бер китап та алдырмадылар. Быел, безнең мәгълүмат буенча, 16 район китап алдырмады. Шулай ук үткән елны 20 районда китапханәләргә абунә өчен акча бирелмәде. Байтак китапханәләр, клублар җимерек, бер баян, бер гармун, бер китап алырга, бер гәзит-журналга язылырга хәлләре юк.

Иң мөһиме: безгә базар белән мәдәниятне, халыкның иманын, халыкның культурасын бутарга ярамый. Бер базарда да без үзебезнең культурабызны милләтебезне сатарга тиеш түгелбез. Бәрәңге сатылсын, ит сатылсын, башка товар сатылсын, әмма безнең китабыбыз, культурабыз һәр кешегә барып җитәргә тиеш.

Телләр турындагы законга акчаның бирелмәве турында әйттеләр инде. Мин инде «шпион» булып бетә яздым, финанс министрлыгына 20-30 мәртәбәләп бардым, ике тапкыр депутат гозере бирдем. Башка министрлыкларга да еш барам, әмма Телләр турындагы законга бирелгән акчаның кая киткәнен беркем дә белми. Әгәр дә без кайчан да булса шушы эшләр белән шөгыльләнә торган дәүләт комитеты, милли эшләр, милли мәсьәләләр белән шөгыльләнә торган дәүләт комитеты оештырмасак, бу өлкәдә беркайчан да тәртип булмаячак.

Менә мин Башкортстаннан бер генә мисал китерәм. 1995 елга Татарстан бюджетында мәдәниятка 24 миллиард сум акча каралган. Татарстанда 3 миллион 800 мең кеше яши, Башкортстанда 4 миллион кеше яши, ягъни 200 меңгә күбрәк. Ә менә Башкортстан бюджетында культурага 86 миллиард сум акча каралган. Нәрсә, башкортлар дүрт мөгезле, ә без ике мөгезлеме әллә? Без нишләп алардан калышырга тиеш? Менә миңа Башкортстаннан хат килеп төште, анда акка кара белән: «Отдел комплектования книг при

җыеп аппарат асрап салым түләп ятуның һич хаҗәте юк. Бүгенге көндә нәшриятлар заманга мөмкин кадәр җайлашырга тиеш. Хәтта язучы үз китабын үзе дә редакцияләп китерә ала. Дәүләттән бүленгән акча беренче чиратта штат тоту өчен түгел, ә китап чыгару өчен биреләдер. Ә инде артыграк штат тоту ул эшләп тапкан акча хисабына булырга мөмкиндер. Язучы үз китабын чыгарырга кайдан акча алсын бүгенге көндә, аның эшләгән хезмәте өчен акча бирелмәгәч. Мин үзем дә әйтәм каләмдәшләремә: йә каян алыйк безгә ришвәт китермиләр, без урлый кеше түгел, алмыйбыз, шулай булгач, нигә бездән акча сорыйлар, димен. Бу бит абсурд. Химаяче табыгыз, дигән сүз дә дөрес түгел: алар каян тапсыннар бүгенге көндә бер кешенең дә кесәсендә артык акча юк. Булса, ул аңа коттедж сала һ.б. Ә дәүләттә акча бар, дәүләттә акча барын без беләбез. Казанның үзәгендә 100әр миллион долларлык биналар төзелә. Әйтик, Бутлеров урамында төрекләр саклык банкын нәрсә хисабына төзи, дип беләсез. Аның һәр кирпече доллар белән түләнә.

Китап бастыру һәм аны таратуны җайга салу җәһәтеннән минем ике тәкъдимем бар. Беренчедән, китап нәшриятын, полиграфия һәм китап белән сәүдә итү оешмаларын 1996 елда тәҗрибә рәвешендә булса да салымнардан азат итәргә кирәк. Югыйсә яңа төзелгән коммерция оешмалары да 2-3 елга салымнардан азат ителә бит. Ә ни өчен китап баскан, китап тараткан һәм полиграфия эше белән шөгыльләнгән оешмаларга шушындый күчеш чорында гына булса да ташлама ясамаска? Икенчедән, һәрбер авыл, район кибетләрендә китапның мәҗбүри ассортименты булдырылырга тиештер. Шул ук аракының мәҗбүри ассортименты бар, ә нигә китапныкы да булмаска тиеш ди? Әгәр без шуны гамәлгә ашырмасак, китап укымыйлар, китап алмыйлар, дигәнебез сафсата сату гына булып калачак.

Фәндәс САФИУЛЛИН, Татарстанның халык депутаты:

— Әйе, китап чыгару һәм аны тарату мәсьәләсен без мәдәниятка гомуми мөнәсәбәт белән комплекслы рәвештә карарга тиешбез. Әйтик, әгәр безнең хөкүмәт җитәкчебез матбугатта татарга аерым югары уку йортлары кирәк түгел, дип белдерү ясый икән, бу инде хөкүмәтнең гомум мәдәниятебезгә мөнәсәбәтен ачык күрсәтеп тора.

Үткән парламент киңәшмәсендә шунысы да мәгълүм булды, җөмһүриятебездә 100 мәктәпне, 100 балалар бакчасын балалардан тартып алып, төрле структураларга, шул исәптән дәүләт структураларына да бүлеп биргәннәр икән. Шулай ук Көче сәнгать академиясе урнашкан бинага да яңа хуҗа табылган. Алыйк безнең М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрын. Анда да татарның әле туып кына килгән опера һәм балет сәнгатен юкка чыгару өчен бик зур көч куела. Без хәзер урыс сәнгатен күрсәтүдә урысның үзеннән дә уздырып җибәрмәкче булабыз. Аурупа әсәрләрен уйнап, шуның белән дан казанырга, менә без хәзер дөнья дәрәҗәсендә чыгыш ясыйбыз, дип күкрәк кагарга телибез. Ә моның өчен казнадан йөзәрләгән миллионнар бүлеп бирелә. Инде килеп, Сталин заманында да, торгынлык дип аталган елларда да театр сезонын татарча әсәр белән ачалар иде, быел аныcын да «оныттылар».

Кыскасы, безгә салым, милек мәсьәләләрен өр-яңадан карап, татар мәдәниятенә һәм мәгърифәтенә, шул исәптән китап чыгару һәм аны таратуга булган мөнәсәбәтне яңабаштан тикшерергә кирәк. Бу юлы безнең сөйләшү бик үк килеп чыкмады, без узара фикер генә алыштык, дип уйлыйм мин. Татар мәдәниятенең хәзерге хәле турындагы мәсьәлә сессиянең көн тәртибенә кертелеп, яңабаштан каралырга тиеш.

Индус ТАҺИРОВ, Татарстанның халык депутаты:

— Бу сөйләшү әлбәттә үзара елашу, зарланышу гына түгел. Моның кайбер файдасы да булыр, дип уйлыйм. Чөнки без сөйләгәннәр алар язылып бара, һәм кайбер кирәкле кешеләр аны тыңлап та тора. Һәм инде әгәр дә без Дәүләт Советы сессиясендә бюджет тикшерелгән вакытта шушындагы моң-зарны илтеп җиткерә алсак, аның да кайбер файдасы булыр, дип уйларга кирәк. Ләкин мин икенчерәк юнәлештә сүз алып бармакчы булам. Без кузгалткан мәсьәләләрне һәрвакыт татарның үз язмышына, татар теленең язмышына бәйләп тикшерү кирәк. Бездә татар теленең гамәлләшү законы һәм аның программасы бар. Әгәр дә без татар китабын бастыру һәм аны тарату мәсьәләсен шушы законга бәйләп тикшермәсәк, ул һич кенә дә хәрәкәткә килмәячәк һәм бу чыннан да файдасыз сөйләшү булачак. Ник дигәндә, әгәр дә без китап чыгару эшен аякка бастырып, аңа акча җәлләмәстән матур китаплар чыгара башлап, аны укырдай кеше калмаса, ул чакта нишләрбез? Шунлыктан әлеге мәсьәлә дәүләт программасы һәм Телләр турындагы законны гамәлләштерү кысасында кабул ителергә һәм тикшерелергә тиеш.

Инде тагын шуны әйтәсем килә: авылларда китапларны чыннан да укыйлар, укырга теләүчеләр бар, ләкин ул барып җитми. Шуңа күрә китапны Татарстан авылларына һәм татар яшәгән төбәкләргә илтеп җиткерү безнең максатыбыз һәм менә шуны гамәлгә куюны без бюджетка кертергә, аның чараларын күрергә тиеш булабыз.

Инде соңгысы — ул да булса татар милли гуманитар институты проблемасы. Без бу хакта Дәүләт Советында карар кабул иттек, ләкин бюджетта шушы карарны гамәлләштерү каралмаган икән. Без карар да чыгарабыз, сөйләшәбез дә, әллә нинди тәкъдимнәр дә кертәбез, ә бюджетта ул чагылмаса, сөйләшү бушка булачак.

Язманы **Газинур МОРАТ** әзерләде

Идел бит ул!

Гадәттә, һәр санның «кендеге», ягъни күләмле һәм затлы бер әсәре була. 10 нчы санның «кендеге» — Ркаил Зәйдулланың «Тимер Буга» кыйссасы. Әсәр тарихи хикәяләр конкурсына тәкъдим ителгән.

...Би улы Тимер Буга, искил ыруыннан китеп, Болгарга килә. Болгарларның Ислам динен рәсми рәвештә кабул итәргә әзерләнеп йөргән чаклары. Егет урыс коллыгына эләккән ырудаш кызны очрата һәм... Анысын әсәр белән танышкач белерсез.

Безгә, ягъни тулаем милләткә, гомер буе юлдаш булып ни килгән? Бу сорауга шушы ук санда яшь галим Илшат Вәлиулла җавап бирә.

«Моң, — ди ул, — гасырларга сузылган коллык халәтенең татар күңелендәге чагылышы». Үз язмасын яшь фикер иясе «Татар декадансы» дип исемләгән.

Мәгълүм ки, «Идел» — конкурслар журналы. Башка яктан да, һәм, әлбәттә ки — бу нисбәттән дә, татар журналлары арасында аңа тиңдәшләр юк бугай әле. Фәнис Яруллинның «Сөенә беләсезме?» — дип аталган публицистик мәкаләсе «Татар әхлагы конкурсы» шигаре астында дөнья күргән.

Чеченнәрнең фаҗигале тарихына азатлык сөюче кешеләрнең берсе дә битараф түгелдер. Шулай да, чечен милләтенең бәйсезлеге өчен көрәшкән татарлар хакында әле күпләр белмиләрдер. Фаяз Фәизнең «Татар белән чечен кушылса» дип аталган язмасы әнә шул бәйләнешләргә багышланган.

10 нчы сан укучыларыбызга әр-яңа ике сәхифә бүләк итә. Аларның беренчесе — «Хак юл» — Коръәнне урысчага шигъри тәрҗемә иткән Валерия Порохова белән әңгәмәдән башлана.

Бу кешене бөтен дөнья белә. Урыс дворяннары токымыннан булган бу итагатьле ханым, мөселман хатыны, Суриянең башкаласы Димәшыкта яши һәм, төгәл тарихи-фәнни мәгълүматларга таянып, Ислам дине хакында бик тәэсирле вә үтемле аңлату эшләре алып бара. «Коръән — дөньяда бердәнбер изге Китап. Нигә изгеме? Чөнки ул иңдерелгән чакта ук язып та алынган. Анда — Аллаһы сүзләре. Ә Библия исә — Гайсә апостолларының «мемуарлары», авыз иҗаты җимеше ул, аны кешеләр язган», — ди Валерия ханым.

Икенче яңа сәхифәбез «Әл-хазна» дип исемләнә. «Әл-хазна» — гарәпчә «хәзинә», «казна», «байлык» дигән сүз. Әл-хазна — борынгылардан безгә мирас булып калган барча рухани вә матди байлыклар ул. Узган гасырларның әхлак, сәнгать мирасы бүгенге көннең сурәтен тудыруда катнаша, рәссамнарның иҗатларыннан саркый, югары илһам һәм гадәти тәкълид-иярү чыганагы булып тора. Сәнгать белгече Лилия Саттарова алып барачак яңа сәхифәбез әнә шул хакта. Бүгенге рәссамнар иҗаты турындагы мәкаләләре белән безгә инде таныш автор биредә яңа сыйфатта — мөселман дөньясы сәнгате тарихчысы буларак чыгыш ясый. Шушы мәкаләдән башлап һәм киләсе ел дәвамында без аның мөселман сәнгате тарихы турындагы җентекле, нечкә тоемлы вә гамьле язмалары белән таныштыра барырбыз.

Югарыда атап әйтелгәннәрдән тыш, журналда Нәбирә Гыйматдинованың йорт ияләре — мафлоклар хакында гаҗәеп кызыклы язмасы, Мәхмүт Әхмәтҗановның «Тәкъдир бармы?» дигән уйланулары һәм Зөлфәт Хәкимнең «Ша-Ярыш» конкурсына тәкъдим ителгән сатирик хикәясе дөнья күргән.

Бу санның «Шигърият» сәхифәсендә мәгълүм гәнкыйтьче, шагыйрь Фәиз Зөлкарнәйнең фәлсәфи, ә Башкортстанда яшәүче яшь шагыйрь Мөнир Вафинның исә яшьлек рухы сирпелгән шигырьләре урын алган.

Әйе, әле моннан берничә ел элек кенә йөз меңнән артык укучысы булган «Идел»нең бүгенге көндә абунәчеләре шактый кимеде. Хәер, бу очракта «Син кем?» дип татар милләтенә сорау бирү зарур. Кем син — эстоннар кебек, үз милли матбагаң өчен җан атучымы, әллә...

Мәскәүдә нәшер ителүче урыс гәзитләренең берсе әле күптән түгел генә Татарстан элемтәчеләрен «Адидас» спорт киемнәре белән бүләкләде. Элемтәчеләр теге гәзитне тарату, сату чыгымнарын үз өсләренә алганнар икән. Ә нигә соң әле алар «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», «Идел» кебек гәзит-журналларыбызның да чыгымнарын күтәрмиләр? Үзләренә «Адидас» түгел, хәтта Арчаның дерматин читек-чүәкләрен дә бүләк итә алмавыбызны чамалаганга күрәме әллә...

Мәгълүм октябрь түнтәрелешенә кадәр беренче дәрәҗәле (гильдияле) сәүдәгәр булу өчен бер байлык кына таләп ителмәгән. Сәүдә әһеленең химаячелеге (меценатлыгы) исәпкә алынган. Мисалга, әдәбият вә сәнгать мәнфәгатьләренә һич кызганмыйча акча сарыф итүчеләр иң югары дәрәҗәле, иң абруйлы байлардан саналганнар.

Соңгы арада Мәскәүдән генә түгел, хәтта океан артыннан ук агыла башлаган кырыкмаса-кырык төрле «Сәхнә йолдызлары»на химая кылганчы, салым акчасын чәчән кардәшләребезне тупка тоткан җинаятьчел дәүләткә биргәнче, милли басмаларыбызга язы[...] мең вә мең тапкыр изге дә, мәртәбә[...] дә гамәл ләбаса!

Инде менә берничә ел рәттән М[...] мадыш районының спирт заводы д[...] ректоры Котдус Зиннәтуллин үз к[...] лективының алдынгы эшчеләренә һ[...] ветераннарына завод исәбен[...] «Идел»не яздыра. Милли җанлы ку[...] кче! Афәрин! Кама Тамагы район[...] караган күмәк хуҗалык рәисләре [...] фазль Гыймадиев белән Миңнур[...] биуллин да журналга шул рәвешле [...] дәм итеп киләләр.

Соңгы вакытта милли матбуга[...] быз аеруча зур кыенлыклар кичер[...] Аңа хәл кадәри ярдәм итәргә теләүче[...] ләр, түрәләр, оешма җитәкчеләр[...] Нәкъ менә сезгә атап, ягъни кил[...] елга журналга язылучы предприят[...] һәм оешмалар өчен «Идел»нең мах[...] индексы булдырылды (татарча[...] — 73959, ә урысча тәрҗемәсе[...] — 73960). Алар өчен ярты еллык аб[...] 25 мең 710 сумга, ә тулаем бер еллы[...] исә 51 мең 420 сумга төшәчәк.

1996 елда «Идел»гә үзләре (аеру[...] язылучы кешеләргә алты айлык абу[...] бары тик 14 мең 910 сумга, тула[...] елныкы исә 29 мең 820 сумга [...] төшәчәк. Индекслары (татарча[...] — 73951, урысча тәрҗемәсе[...] — 73952) үзгәрмәде. Теләүчеләр ([...] калабызда яшәүчеләр) редакц[...] үзенә дә (Комлев урамы, 14) ки[...] языла алалар. Бу очракта ярты ел[...] абунә фәкать 10 мең, ә тулаем ел[...] — 20 мең сум гына тәшкил итә[...] Әмма шунысы бар: бу абунәчеләр ж[...] рналны редакциядән үзләре ки[...] алырга тиеш булалар.

Марат ЗАКИ[...]

«Идел» журналы[...] бүлек мөхәрри[...]

Ак юл сиңа, Туллар!

Бөек Ватан сугышына кадәр дә, аннан соң да Башкортстандагы татар мәктәпләренең саны Татарстандагы белән чагыштырганда 200гә артыграк. Һәм бу һич тә гаҗәп кол түгел идә. Татар халкының чама белән яртысы Башкортстанда яши бит. Аннары Мәскәү Татарстанны «коммунизмга ашыгыбрак кертә» башлады. Шуның нәтиҗәсендә татар мәктәпләренең саны нык кимеде. Ә Уфа бу мәсьәләдә аеграк акыл белән эш йөртте. Ләкин Башкортстанның хакимият башына татар милләтеннән булган «башкорт» Мидхәт Шакиров куелгач (әти-әнисе чын татарлар, әтисе Казанда Күл буе мәдрәсәсен тәмамлаган кеше), татар белән башкорт мөнәсәбәтләре нык кискенләште. «Башкортлаштыру» шуның кадәр көчәеп китте ки, тиз вакыт эчендә бик күп татар мәктәпләрен башкортча укытуга күчерделәр. Ата-аналардан, укытучылардан Мәскәүгә «ризасызлык белдереп» меңнәрчә хатлар ява башлады. Мәскәү исә мыек астыннан гына елмаеп торды. Чөнки Шакиров татарларны юкка чыгару сәясәтен тормышка ашыра иде! Тора-бара күп кенә мәктәп җитәкчеләре, «ата-аналар теләгән искә алып» (кара А.Хәлим, «Сагыш китабы»), балаларны урыс телендә укытуга күчтеләр. Ул вакытта укытучылар аңына да «Сез коммунизмда яшәячәк кешеләр, ә анда урыс теле генә булачак», дигән ялган фикер салынды. Без мәктәптә ана телебездә белем алдык. Шуңа күрә дә аннан Ф Ганиев, дүрт бертуган Гайнановлар, В.Гайнетдинов, Ф Хәлиуллин, Г Мөхәммәтдинов кебек булачак күренекле галимнәр, Р Исмәгыйлев, М.Галимов, Р Вәлиәхмәтова, Г Мирхәйдәров, Татарстанның һәм Русиянең халык артисткасы Зилә Сөнгатуллина кебек артистлар тәрбияләнеп үсте. Хәзер берәү дә юк, чөнки укыту урыс телендә бара. Бу хәл бигрәк тә иҗат өлкәсендә эшләүче зыялыларның юлын кисә. Бик тирәнтен һәм яхшылап уйланылган сәясәт!..

Соңгы вакытта «Азатлык» радиостанциясе (ярый әле ул бар) атна буе диярлек Уфадан бер шатлыклы хәбәрне тапшырып торды. Биш ел көрәш алып бару дәвамында ниһаять, Бәләбәй шәһәрендә татар гимназиясе ачылачак икән. Башкортстанда беренче татар гимназиясе! Бу уңайдан бер чагыштыру китерәсем килә: соңгы өч-дүрт ел эчендә Татарстанда йөзләп милли гимназия, лицейлар ачылды. Уфада татарларның саны Казандагыдан аз түгел. Ә Уфада бер татар мәктәбе дә юк! Самарада бер үч татар бардыр. Әмма ул шәһәрдә татар урта мәктәбе эшли.

Татарстанда татар телендә унике журнал чыгып килә. Ә Башкортстанда узган ел татар телендә «Шура» журналының беренче саны дөнья күреп калды. Ул безнең «Мирас» журналына аваздаш булмас микән, дигән өмет бар иде. Әмма өметләр акланмады. Менә шундый кыен шартларда узган елны Уфада татар телендә Башкортстан яшьләре журналы «Туллар»ның дөньяга килүе шактый кыю адым булды. Ул ике айга бер тапкыр дөнья күрә.

Менә «Туллар»ның тәүгә саны. Беренче битте, гадәттәгечә, журнал коллективын котлаулар, изге теләкләр урнаштырылган. Алар арасында Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники, «Идел»нең баш мөхәррире Фәиз Зөлкарнәй (икесе дә Башкортстанда туып үскән), Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев, Башкортстанның татар телле язучылар берлеге рәисе профессор Рәиф Әмиров, Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Динис Бүләковның котлаулары да бар. Әмирхан абый, журнал татар-башкорт дуслыгын ныгытсын иде дигән теләк белдерә. Минем шуны кистереп әйтәсем килә: татар беркайчан да башкортка карата начар карашта булмады. Ләкин дуслык урамы берьяклы гына була алмый. Заманында Казанда чыга торган гәзит-журналлар Уфа татарларының өстәлендә ята иде. Шуның нәтиҗәсендә рухи дуслык дәвам итте. Хәзер исә мондый мөмкинлек бик чикле. Менә шушы шартларда «Туллар»ның пәйда булуы ике республика халкының да уртак шатлыгы уңышы итеп каралырга тиеш. Ләкин Уфада бездәге кебек иркенлек юк: авызны үлчәп ачарга туры килә. Чөнки әдәбият сәясәт түгел ул, дип уйлаучылар да бар әле анда. Әмма бу фикер һич дөрес түгел. Әгәр әдәбият сәясәткә хезмәт итмәсә, Сталин һәм аның яраннары әдипләрне бертуктаусыз «тәрбияләмәсләр» иде. Хәзерге шартларда «Туллар»ның төп бурычы — тыныч рәвештә үз республикасындагы татарларның милли уҗаның уятудан гыйбарәт. Хәлбуки, бу гамәл башкорт кешесенә каршы юнәлдерелмәгән. Журналның дөнья күргән биш саны да шуны раслый.

Таһир Таһировның «Әрвахлар күктә яши» дигән повесть-эссесен дулкынланмыйча укып булмый. Чөнки бу язучы һәр язганын йөрәге аша уздыра. Монда авыллар тарихы, бөтен халык [...]лышы яктыртыла. Әдип чуваш х[...] лык язучысы Яков Ухсай, татар халы[...] язучысы Гомәр Бәширов белән очра[...] шуларын да матур һәм ышандыры[...] лык тел белән тасвирлый. Зур гал[...] рәссам, гармунчы, фронтовик күрен[...] кле җәмәгать эшлеклесе Таһир Таһ[...] ров 37 нче ел фаҗигаләрен кичер[...] яшьләй әнисез кала, сугыш бетәр[...] берничә көн кала аның әтисе дә һәла[...] була.

Зур күләмле әсәрләрнең икенчес[...] — «Пәйгамбәр таңы» дип атала. Авто[...] ры — танылган галим һәм язучы С[...] фиян Поварисов. Әсәр бөек әдип Г[...] лимҗан Ибраһимовның балачагы[...] яшьлегенә багышланган.

Сан саен берничә кыска хикәя ([...] реләп баруын да (Казанда аларга к[...] лык зур) журнал өчен отышлы яр[...] дип санарга кирәктер. Кызганыч ә[...] гә хикәяләр турында да тәфсилле с[...] әйтеп булмый — күләм чикли. Шул[...] да Суфиян Сафуановның «Рәхилә [...] гән кровать» дигән хикәясенең ш[...] тый уңышлы һәм чын әдәби сәнга[...] югарылыгында булуын әйтәсем ки[...] М Кәбиров, Р Чурагупова, Ф Хәбиб[...] лин хикәяләренә дә уңай бәя бир[...] мин. Шигырьләргә дә урын кызган[...] ган журнал. Минем үземә шагыйрь [...] бдрәхим шигырьләре аеруча ош[...] Ул журнал белән киләчәктә дә хезм[...] тәшлек итәр дип ышанасы килә. [...] ньяга философик караш, сәяси яр[...] лык, шигъри аһәң беркемне дә б[...] раф калдыра алмый. Дилә Булгак[...] шигырьләре исә күңелләргә дәрт [...] яшәүгә мәхәббәт уята..

Басманың киләчәге өметле һәм [...] ты. Килер бер көн, ул айлык журна[...] әверелер. Ак һәм бәхетле юл си[...] «Туллар»!

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНО[...]

Каз[...]

СЕБЕР ҖЫЛЫНДЫМЫ?

«Мәдәни җомга»ның 12 нче санында без Төмән өлкәсендә татар мәдәнияте көннәре үткәрелачәге турында хәбәр иткән идек инде. Бу бәйрәмдә газетабезнең махсус хәбәрчесе Харис ЗАКИРОВ та катнашты. Түбәндәге язмада ул Себердә яшәүче татарлар белән очрашулар вакытында алган тәэсирләре белән уртаклаша.

...Сургутта соңгы ун ел дәвамында «Намус» татар-башкорт мәдәни үзәге эшләп килә икән. Аның каршында «Дуслык» җыр-бию,фольклор ансамбле бар. Ансамбль белән якташыбыз, Кукмара кызы Нурия Җиһаншина җитәкчелек итә. Шәһәр читендә булса да, татар балалары өчен якшәмбе мәктәбе эшли. Ял көннәрендә шул мәктәптә нәниләр җырга-биюгә, нәфис сүз сөйләргә өйрәнә. Сургутлы милләттәшләребезнең үзәк китапханәдән татарча китап алу мөмкинлеге дә бар икән. Соңгы елларда телевидениедән татарча тапшырулар карау бәхете дә елмайган үзләренә. Әмма болар, дәүләт тарафыннан билгеле бер системага куелмаганлыктан, чикләнгән чаралар гына булып калалар. Әйтик, шул ук «Намус»ның бинасы да, телефоны да юк. Атнага бер тапкыр җәмәгатьчелек тәртибендә генә эшләгән якшәмбе мәктәбендә дә малайлар-кызлар ял хисабына йөрергә тиеш.

Татар тормышын ничек җанландырырга соң? Шул хакта уйлана торгач, мәчет салырга ниятлиләр сургутлылар. Имам-хатиб булып Казаннан Габделхак хәзрәт Саматовның улы Таһир хәзрәтнең килүе билгеле булгач, бу теләкләре тагын да ныгый төшә, чөнки Таһир хәзрәт әзерлекле белгеч, остазәнә, үзе яшь, мәчет төзүгә дә бик теләп алыначагын әйтә.

Менә без мәчет биләмәсендә беренче булып төзелгән бинада утырабыз.

— Бүгенге көндә мәчет булып торса да, киләчәктә әлеге бина мәдрәсәгә әйләнәчәк. Ә 300 урынлы чын мәчетебез менә шушындый булачак, — дип Таһир хәзрәт өстәлдә торган макетка күрсәтә. — Ә бу бинаны узган елның 20 сентябрендә сала башлаган идек, быелның 25 февралендә — Кадер кичәсенә каршы көндә ачтык та.

Ике катлы, һәм ир-ат, һәм хатын-кыз — җәмгысе 100 кеше намаз укырлык әлеге мәһабәт бинаны нибары биш ай эчендә кемнәр шулай күтәреп куйган соң? Таһир Саматның әйтүенә караганда, күпләр, бик күпләр икән андый игелекле кешеләр. Мәсәлән, алар арасында конденсатларны стабильләштерү заводы директоры Хәмит Ясәвиев, «Автодор» фирмасы директоры Рамил Мусин, «Нефтехиммонтаж» трестының баш инженеры Әхмәт Якупов, газ эшкәрту заводының генераль директоры урынбасары Флорид Шакиров, «Сургутнефтегаз» акционерлык җәмгыятенең нефть газын җыю һәм файдалану идарәсе начальнигы Виктор Вахрушев, «Газпром» автотранспорт берләшмәсенең директоры Җәүдәт Сәлахов бар. Булышчыларның күбесе Татарстаннан икән. Арада Башкортстаннан килгән татарлар да бар.

Таһир хәзрәт белән ишегалдына чыгабыз. «Мәчет белән мәдрәсәдән тыш, проектта кунакханә, имам йорты да каралган», — дип сүзен дәвам итә хәзрәт. Әйе, матур һәм мактауга лаек эш башкаралар Сургут мөселманнары. Татар милләтенең киләчәген күз алдында тотканда, мөселман динен торгызмый, шәригать кануннарын үтәми торып, без хак юлга чыга алмаячакбыз. Әлбәттә инде, динне кайтару өчен мәчет салу үтә дә җитди эш булса да, аңа кешеләрнең йөрүе тагын да мөһимрәк галәл Шуңа күрә саубуллашыр алдыннан хәзрәттән:

— Мәчеткә халык күп йөриме? — дип сорадым.

— Кызганыч, яше 60-70 кә җитеп тә мәчет бусагасын беренче тапкыр гына атлап керүчеләр очрый. Яшьләр турында әйтеп тә торасы юк. Җитмеш ел буе дингә каршы алып барылган коткы үз ролен уйнамый калмады. Шулай да өмет белән яшибез. Динебезгә йөз белән борылачаклар, Аллаһы боерса. Татар балалары укый торган якшәмбе мәктәбен дә бирегә — мәчет биләмәсенә күчерергә ниятлибез.

Әнә шулай дип җавап бирде Таһир хәзрәт Самат. Алга китеп булса да әйтик, мондый җавапны безгә Нижневартовскиның имам-мөхтәсибе Абделгадел хәзрәт Гыйлләҗетдиннән дә ишетергә туры килде. Шунысы гаҗәп: ни өчендер милләттәшләребез — татарлар мәчеткә бик аз йөриләр икән. «Дагстанлылар, чечәннәр, әзәриләр, үзбәкләр, фәләстин гарәпләре, төрек эшчеләре, хәтта урыслар (мөселман динен кабул иткәннәре) мәчеткә килә, ә татарлар берән-сәрән генә күренә», — ди Абделгадел Гыйлләҗетдин. Әмма аңа карап мөхтәсибәт эшен туктатмый, киресенчә, үзенә караган Лангепас, Мегион, Радужный, Покачи кебек шәһәрләрдә мәчет салу хәстәрен күрә. Әйтик, Покачида биш бүлмәле фатир сатып алып, шуны мәчет иткәннәр.Радужныйда да мәчет өчен бина табылган.Ә Нижневартовскидагы мәчет 12 май көнне, Корбан гаете алдыннан ачылган. Ул да кеше йорты булган, аны Альберт һәм Салават атлы сәүдәгәрләр сатып алган. «Башта 8-10 кеше генә йөри иде, хәзер җомга намазына йөздән артык кеше килә. Милләтне милләттән аермыйбыз, һәр мөселманга ишегебез ачык», — ди Абделгадел хәзрәт.

Без мәчеттә булган көнне авар агае Ширван Чупалаев белән таныштык. «Белоозернефть»тә шофер булып эшләүче 55 яшьлек Ширван ага 40 чакрым җирдән намаз укырга килгән.

— Татарларны да мәчеткә тартырга кирәк бит инде. Сургуттагы кебек, Нижневартовскида да милләттәшләребез аз түгел икән, — дим өнгәмәдәшемә.

— Килерләр, намаз укырлар дип кул кушырып утырмыйбыз. Адәм баласының күңеленә орлыкны яшьтән салырга кирәк. Мәчеттән 50 метрлар гына ераклыктагы урта мәктәптә балалар өчен өч сәгатьлек уку оештырдык. Анда якшәмбе көнне Абдерахак хәзрәт Гарифулла ислам кануннарын һәм гарәп телен өйрәтә. Ул бу эшне Чаллыдан килеп башкара. Аның торкемендә хәзер 20 кыз укый. Ә ир балаларны мин үзем укытам.

Болардан тыш — Көнбатыш Себердә яшәүче милләттәшләребез өчен Нижневартовски мөхтәсибәте «Свежий ветер» дигән айлык гәзит чыгарырга да җыена икән. Дөньяви гәзит буларак күзалланган әлеге басмага кушымта рәвешендә «Исламский вестник» та дөнья күрәчәк. Тора-бара бу кушымта «Сыратул мустекыйм» («Туры юл») исемле мөстәкыйль гәзиткә әйләнәчәк.

Кыскасы, һәм Сургутта, һәм Нижневартовскида дингә хезмәт итәргә алынган кардәшләребез акрынлык белән булса да алга баралар, милләттәшләребезнең күңелен сафландырырга хәл кадәрле өлеш кертәләр.

* * *

Инде матбугатта хәбәр ителгәнчә, Себердә булып үткән татар мәдәнияте көннәре Сургут шәһәре хакимияте белән Татарстан мәдәният министрлыгы арасында мәдәни бәйләнешләрны үзара җайга салуны күздә тоткан шартнамә төзү белән төгәмамланды.

Шартнамәдә себерлеләр өчен кадрлар әзерләү, моның өчен аларны Казанга җибәреп укыту да каралган. Шунысы игътибарга лаек: мәдәни чараларны тормышка ашыру өчен Сургут шәһәр бюджетыннан акча бүлеп бирелә-чәк. Бу җәһәттән, нижневартовскилыларга сургутлылардан үрнәк алырга да була. Нижневартовски шәһәрендә бөтен Төмән өлкәсенә берденбер татар халык театры бар. Театр Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар», И.Юзеевның «Кыр казлары артыннан» кебек әсәрләрен сәхнәләштергән. Әмма ул хәзер соңгы сулышын алып ята. Шушы ук шәһәрдә «Муниципаль ял һәм иҗат итү үзәге» мәдәният сарае каршында «Шатлык» исемле татар-башкорт эстрада төркеме бар. Аның җитәкчесе Нурфия Маннанованың әйтүенә караганда, смотр вакытында призлы урын алган өчен бирелгән 1 миллион сумны группа үз мөнфәгате өчен файдалана алмый иза чигә икән. Әлеге ял һәм иҗат итү үзәге администрациясенең җавабы бер: акчаны сезгә аерым тотсак, башка милләт вәкилләре дә бездән акча таләп итә башлаячак, янәсе. Таныш, бик тә таныш җавап бу. Заманында үзебездә дә яшьләр журналы ачу турында сүз чыккач, КПСС Үзәк Комитетыннан нәкъ шундый ук җавап булмадымыни?!

Ләкин, миңа калса, Себердә яшәүче милләттәшләребезнең үзләренә дә активрак булырга кирәктер. Мәсәлән, бәйрәм көннәрендә Татар дәүләт драма һәм комедия театры чыгыш ясаган Сургуттагы «Энергетик» һәм «Нефтяник», Нижневартовскидагы «Октябрь» мәдәният сарайлары заллары артылаш буш иде. Мәшһүр җырчыларыбыз Зөһрә Сәхабиева, Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Ильясов Лянтор шәһәрендә буласы концерты да, тамашачылар килмәү сәбәпле, өзелде. Юкса, әнә бит, бөтен шартларын туры китереп әзерләгәч, сентябрь аеның беренче якшәмбесендә нефть һәм газ промышленносте эшчеләре бәйрәме уңаеннан «Кубань халык хоры» куйган концертта алма төшәрлек тә урын булмаган. Казакларны олысы-кечесе, татары-урысы әле дә сагынып искә ала. Сүз уңаеннан әйтик, казаклар да «Сургутнефтегаз» акционерлык җәмгыяте белән шартнамә төзегәннәр, концертларын ешрак күрсәтергә килешкәннәр икән.

Бер сүз белән әйткәндә, Себерне җылыту өчен иҗатың да җылы, бу юлда кылган гамәлең дә җылы булырга тиештер. Шунысы куанычлы, әлеге юнәлештә төгә адым дәүләт оешмасы тарафыннан ясалды. Хәзер инде дәвамын күтәргә кала.

● **Татарстан мәдәният министры урынбасары И.Тарханов сургутлыларга Татарстан туграсын тапшыра.**

Габделбәр **РИЗВАНОВ** фотосы.

(Дәвамы Башы 15 — 17, 19 нчы саннарда).

Сөннәт

Сөннәт гамәлләре дип кайсыларын Мөхәммәд пәйгамбәр үз гомерендә күп мәртәбәләр кылып, бер ике тапкыр гына яки аннан да бераз артыграк калдырып торган, әмма аларны башкаруны гадәте иткән эшләргә әйтәләр. Мәсәлән, тешне мәсвәк чистарткыч белән чистарту, азан, камәт, җәмәгать белән намаз уку һ б.

Сөннәтнең хөкеме шунда ки, әгәр дә аны кылсаң, рәхмәткә ирешәсең, савап табасың, әгәр дә калдырсаң, ул вакытта моның өчен җәза вә газап ирешми, шулай да шелтә бирелә. Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатеннән коры калырга мөмкинлек өчен сәбәп барлыкка килә. Шулай да бер-бер мөселман бәндәсе «Сөннәт әле әллә ни түгел», дип уй хисап кыла икән, моның нәтиҗәсе бер дә яхшыга китерми: ул диненнән чыккан, динен ташлаган кешеләрдән санала. башлый. Иман яңартуы кирәктер.

Фәрит ЯХИН

ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ БӘЯНЕ

Сөннәт гамәлләре өч төрлегә бүленә. Аларның берсен — сөннәт мөвәкдә, икенчесен — сөннәт гайре мөвәкдә, өченчесен сөннәт гали-әл-кифайә диләр.

Сөннәт мөвәкдә дип кайсы гамәлләрен Мөхәммәд пәйгамбәр үз гомерендә бер яки ике тапкыр гына үтәмичә калдырган, әмма моның өчен аерым олуг сәбәпләре булган нәрсәләргә әйтәләр. Мәсәлән, иртә һәм ахшам намазының сөннәтләре, йәсигъ намазының соңгы ике рәкәгате, өйлә һәм җомга намазларының әүвәлге һәм соңгы сөннәтләре. Боларны ялкаулыгы аркасында һәм «өйдә ярар» рәвешендә фикерләп калдырган кешеләр бозыклык эшләүчеләр ратенә төшәрләр, гонаһка батарлар, Аллаһы Тәгаләнең шәфкатеннән мәхрүм калырлар.

Сөннәт гайре мөвәкдә дип, кайсы гамәлләрен Мөхәммәд пәйгамбәр бер вакыт эшләп, икенчесендә ташлаган булса, аннан тагын башкарса әйтәләр. Әйтик, икенде һәм йәсигъ намазларын укыганда әүвәлге сөннәтләрен калдыру шушындый гамәлләрдән санала. Әмма шунысы да бар, һәрвакыт бу юл белән барырга ярамый, казалануың мөмкин, шунлыктан бу сөннәтләрне вакыт-вакыт үтәгәндә рәхим-шәфкатькә ирешәсең.

Сөннәт гали әл-кифайә дип, әгәр дә аларны арадан бер кеше башкарса, башкаларның өстеннән дә бурыч төшә торган гамәлләргә әйтәләр. Әйтик, җыелышып, өмә белән, бергәләшеп эшли торган теге яки бу эшкә тотынганда халык арасыннан берәү бисмилласын әйтеп керешә икән, ул вакытта моны һәммәсе дә тәкрарлаган кебек килеп чыга, бу барысына да кагыла, гамәлләре дөрес була.

Мөстәхип

Мөстәхип дип кайсы эшләрне Мөхәммәд пәйгамбәр гомерендә барытик берничә мәртәбә генә эшләгән яки башкаларга моны эшләү кирәклеген белдергән, савабы барлыгын искәрткән гамәлләргә әйтәләр. Мәсәлән, нафилә намазы, нафилә садакасы бирү һ б.

Мөстәхип гамәлләрне үтәгән кешеләргә савап ирешер, ташлаганнарга исә шелтә дә белдерелмәс, газап та ирешмәс, шул ук вакытта андыйлар Аллаһы Тәгаләнең шәфкатеннән дә коры калмас. Әмма дә ләкин үз гомереңдә берничә тапкыр бу гамәлләрне башкару яхшы булыр, моны истән чыгарырга ярамас.

Мөбах

Башкарсаң-башкармасаң да, кылсаң-кылмасаң да гонаһ һәм савап бирми торган эшләр мөбах гамәлләр дип атала. Ягъни боларны кылу тыелмый һәм шулай ук шәригать каршында макталмый да. Утыру, тору, йөрү, йоклау, ашау һ б. гамәлләр шундыйлардан санала. Алар бәндәләрнең тормыш ихтыяҗларыннан мәҗбүри рәвештә килеп туа. Алардан арыну таләп ителми.

Хәрам

Хәрам дип кайсы гамәлләрне Аллаһы Тәгалә шиксез дәлилләр белән тыя, эшләмәскә, сакланырга куша, шуларга әйтәләр.

Хәрам үзе ике төрлегә бүленә. Аның берсе — хәрам ләгыйнә, икенчесе — хәрам ләгыйрә.

Хәрам ләгыйнә булган вакытта, ләгънәтләнә торган эш һәм нәрсәләргә әйтәләр. Ул эшләрнең үзләрендә үк хәрамлыклары күренеп тора. Болар — кеше үтерү, зина кылу-уйнаш, риба һәм ятимнәрнең малын ашау, ялган сүз, гайбәт, көнчелек белән сүз сөйләшү һәм башка шуның кебек эшләр, нәрсәләр. Әгәр дә берәү боларны кыла икән, ул зур гонаһ эшләүче була. Шунлыктан тәүбә итүе тиешле. Әгәр дә тәүбәсез доньядан үтә икән, андыйларның имансыз үлүләре ачык билгеле. Тәүбәсезләрнең иманы дөрес булмый. Әгәр дә инде бу хәрам эшләрне башкарган вакытында бисмилла белән керешсә яки болар хәрам түгел, хәләл дип белдерсә, бу вакытта ул кеше диненнән чыгар, иманы һәм никяхы дөрес булмас. Мондый ирнең хатыны аңа хәрам булыр, бергә йокласалар, эшләре зина саналыр. Шулай ук мондый хатын белән торган ирнең гамәлләре дә хәрам булып, бергә йоклаулары гонаһсыз ирне гонаһлы итәр, зиналы исәпләнер. Шунлыктан хәрам эш эшләгән икән, үкенеп, тәүбә сорасын һәм иманын яңартып, яңадан никях укытсын.

Хәрам ләгыйрә дип теге яки бу эш һәм нәрсә үзе асылда хәрам булмыйча, башкаруы гонаһ саналса, шуңа әйтәләр. Мәсәлән, икмәк үзе хәрам әйбер түгел, әмма аны урлау, кеше өлешен тартып алу кебек эш исә — хәрам, ягъни караклык, кеше хакына кул сузу һ б.

Мәкруһ

Хәрамга яки хәләлгә якын булган эш һәм нәрсәләр мәкруһ гамәлләр дип атала. Мәкруһ үзе ике төрле була. Берсе — хәрамга якын гамәлләр һәм нәрсәләр, икенчесе — хәләлгә якын гамәлләр һәм нәрсәләр. Беренчесе ваҗибне калдыру, үтәмәү аркасында барлыкка килә. Мәсәлән, Ислам динен калдыру, башка дингә күчү. Моның өчен бәндә шәфкатьтән коры кала һәм казага юлыга. Икенчесе сөннәтне калдыру белән бәйле. Мәсәлән, сакал йөртү — сөннәт санала, әмма сакалсыз булу үзе хәләл исәпләнә. Моның өчен бәндәләр шелтәгә тартылмый, казага юлыкмый, әмма да ләкин рәхим-шәфкатьтән коры калулары бик ихтимал.

Мөфәссәд

Һәртөрле изге гамәлләрне бетерә торган эшләрне һәм нәрсәләрне мофәссәд дип йөртәләр. Мәсәлән, намазда дөнья хәлләрен сөйләшү, аятьнең мәгънәсен боза торган рәвештә ялгышып уку, тәһарәт алган вакытта бер-бер җирдән кан агу, ураза вакытында ашау-эчү һ.б.

Бишвакыт намазның тәртипләре

Бишвакыт намаз дип әйткән вакытта бер тәүлек эчендә укыла торган биш намаз күздә тотыла. Бу намазларның һәрберсенең үз вакыты һәм дә тәртипләре бар. Аларны бутарга ярамый. Аның беренчесе иртәнге намаз дип атала, икенчесе өйлә намазы (җомга көннәрдә аның урынына җомга намазы укыла), аннан соң икенде намазы, ахшам намазы, йәсигъ намазы.

Иртәнге намаз

Укыла торган вакыты — таң беленә башлаганнан алып кояш чыкканчыга кадәр укылып тәмам ителергә тиешле.

Иртәнге намаз дүрт рәкәгать башкарыла, ягъни дүрт тапкыр кабатлана. Аның әүвәлге ике рәкәгате — сөннәт мөвәкдә, калган икесе — фарыз.

Кагыйдәләре:

1. Әгәр дә бер кеше иртәнге намазга мәсҗедкә соңга калып җитешсә, инде ул вакытта җәмәгать фарызны үтәүгә керешкәннәр икән, бу очракта:

а) соңарган бәндә: «Әгәр дә сөннәтне укысам, җәмәгать артыннан әттәхияткә җитешермен!» — дип фикерләп намазга керешә икән, акылы белән хөкем кылса, сөннәтне калдырмас, укыр һәм дә җитешергә тырышыр. Бу юлы аңа ашыгу дөрес саналыр, гонаһка кермәс.

б) соңарган бәндә: «Әгәр дә сөннәтне дә укысам, әттәхияткә җитешә алмам!» — дип борчыла икән, ул вакытта сөннәтне калдырып, имамга оеса, яхшырак. Чөнки җәмәгатьнең савабы, алар белән бергә намаз уку сөннәтнең савабыннан артыграк. Сәбәп: соңыннан сөннәт өчен каза тиешле түгел.

2. Әгәр дә бер бәндә иртәнге намазын укырга соңарса, йоклап калса, инде кояш чыгарга өлгерсә, ул очракта каза итеп, төшкелеккә кадәр иртәнге намазын сөннәте белән бергә үтәр, әгәр дә гөштән соңга калдырса, ул очракта фарызын гына каза итәр, сөннәтне каза буларак үтәмәс, калдырыр.

3. Әгәр дә мөселман бәндәсе иртәнге намазга килгәндә җәмәгать мәсҗедтә фарызга кергән икән, ул вакытта соңаручының сафка басып яки артка чыгып сөннәтне укуы мәкруһ була, шунлыктан ул сөннәтне мәсҗеднең сөннәт бүлмәсендә башкарыр, әгәр дә андый бүлмәсе юк икән, ул очракта мәсҗеднең почмагында укысын. Әгәр дә өендә сөннәтне укып килгән булса, ул вакытта кабатлавы кирәк түгел, фарызга кушылыр, сафка керер яки арттан урын алыр.

Өйлә намазы

Укыла торган вакыты — кояш баш түбәсенә җитеп, бераз авышканнан соң гына башкарыла.

Өйлә намазы ун рәкәгатьтә башкарыла. Элек дүрт рәкәгать сөннәт укыла, аннан соң дүрт рәкәгать фарыз башкарыла, ахырдан тагын да ике рәкәгать сөннәт мөвәкдә укыла. Әмма дә өйлә намазының соңгы ике рәкәгате сөннәт мөстәхибә саналып, аны арттырып дүрт рәкәгать кылуның савабы бик күп. Һәр ике рәкәгате бер намаз исәпләнелә. Шунлыктан әүвәлге утырышка утыруы фарыз. Салават һәм догаларны башкарып, аягына басканнан соң «Сөбханәкә»не укуы кирәк. Бисмилла белән башлап китәр. Теләгән тәкъдирендә икешәр рәкәгать итеп укый, ягъни ике рәкәгать укыганнан соң аягына басар алдыннан сәлам бирер, торыр, яңадан ике рәкәгатьне ниятләп, өстән аны башкарыр. Шунысы да бар, көндезге намазларда дүрт рәкәгатькә бер тапкыр, кичкеләрдә исә ике рәкәгатькә бер сәлам бирү мактаулы исәпләнелә.

Кайбер кагыйдәләре:

1. Әгәр дә бер мөэмин өйлә намазына соңарып килсә, ул вакытта җәмәгать фарызга кергән булса, ул вакытта бу бәндә дә имамга оеп, фарызны башкарыр. Әүвәлге дүрт рәкәгать сөннәтне исә фарыздан соң каза итеп үтәве дөрес булыр, аннан соң гына ике рәкәгать ахыргы сөннәтне укыр

Икенде намазы

Укыла торган вакыты — аяк өсте басып торганда күләгәң үзеңнән ике тапкыр озынрак икән, намазга керешергә мөмкин. Кояш батканчыга кадәр уку тиешле.

Икенде намазы сигез рәкәгать белән башкарыла, иң элек дүрт рәкәгать сөннәт мөстәхибә башкарыла, аннан соң дүрт рәкәгать фарыз үтәлә.

Әгәр дә бер кеше мәсҗедкә килгән вакытта мөэминнәр фарызга кереп, камәт итсәләр, ул вакытта соңаручыга фарызга тотынып, сөннәтен калдыру, имамга оюю дөрес күрелер. Сөннәте дә казага калдырылмас.

Әгәр дә соңарган кеше сөннәткә керешүгә мөэминнәр камәт итсәләр, ул вакытта аның өчен ике рәкәгать укып, сәлам биреп, имамга оер, бу дөрес гамәл күрелер. Әгәр дә инде өченче рәкәгатькә торса, аны тәмам кылып, шуннан соң гына фарызга күчәр.

(Дәвамы бар).

Дүшәмбе

4 декабрь

«ТАТАРСТАН»

.00—8.00 «Чулпан» информацион програмасы. 19.15 «Татарстан». 19.45 «Телебуклет». Тапшырулар анонслары. 19.55 «Түгәрәк остел». Реформалар программасы· ул нинди булырга тиеш? 20.25 «Әлли-бәлли-бәү» 20.35 «Татарча сөйләшәбез» 3 нче дәрес. 20.55 «Гашыйклар телеканалы» 21.25 «Сайлауларны каршылап». «Русияне кем төзекләндерер?» 21.35 «Яшел камин янында» Профессор А.Бурганов. 22.30 «Каз өмәсе» 22.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда — музыка» 7.30 «Тамаша залы». 8.00 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 8.15, 11.05 «Юл патруле» Атналык йомгак 8.30, 14.45 «Даруханә». 8.40 «Минә сайла» 9.20, 12.50 «90х60х90» 9.40 «Диск-канал» 10.00 «Чәй клубы». 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти» 11.20 «Атна фаразлары» 11.50 «Валюта бәясе» 12.00 Сериал «Мстители». 13.05 Нәфис фильм· «Случай с Полыниным». 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15.30 Телесериал «Флиппер» 19 нчы һәм 20 нче сериялләр. 16.25 «Минем кино» А.Захарова. 17.05 Нәфис фильм «Сети рэкета» И.Костолевский. 19.20 «Бонус» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.20, 23.40 «Шәһәр» информацион программасы 20.45 «Видеомода». 21.05 Мультфильм· «Принцесса и людоед». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Криминаль хроника тележурналы». 0.05 Телесериал: «Особые подразделения». 2 нче фильм. «Опасные игры»

1 НЧЕ КАНАЛ

.00 Иртә 8.30, 19.05 «Сайлаулар-95» 9.00, 12.00. 15.00, 18.00, 0.00 «Яңалыклар». 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.00 «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» 11 10 Мультфильм. 11.30, 19.35 Телеуен: «Коен таны». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 «По закону джунглей». 1 нче серия. 13.55 Сериал: «Тридцать случаев майора Земана». 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Марафон-15». 16.00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.00 «Джем». 17.30 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 20.00 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.45 Фантастик детектив: «Электронные жучки-9». 22.50 «Көмеш шар». 23.35 Өлкәннәр өчен мультфильм. 0.10 «Визит к минотавру». 1 нче серия.

«РУСИЯ»

